# Казан утлары

ОКТЯБРЬ 1965 № 10

# «СОВЕТ МӘКТӘБЕ» ЖУРНАЛЫНА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМАГЫЗ!

## *ХӨРМӘТЛЕ УКЫТУЧЫ!*

1966 нчы елга «СОВЕТ МӘКТӘБЕ» журналына язылу дәвам итә. Без сине, хөрмәтле укытучы, үзеңнең журналыңны алырга һәм даими рәвештә укып барырга чакырабыз.

Журналда башлангыч, сигезьеллык һәм урта мәктәп укытучылары, класс һәм мәктәп җитәкчеләре, өлкән пионервожатыйлар, тәрбиячеләр, халык мәгарифе бүлекләре мөдирләре, инспекторлары, гомумән, барлык мәгариф работниклары өчен көндәлек эшләрендә ярдәм булырлык материаллар урнаштырыла, алдынгы мәктәпләрнең, укытучыларның, класс җитәкчеләренең һәм тәрбиячеләрнең тәҗрибәсе киң яктыртыла.

«СОВЕТ МӘКТӘБЕ» журналында коммунистик тәрбия, хезмәткә өйрәтү, аерым фәннәрне укыту буенча методик эшкәртмәләр, укыту планнарына һәм программаларына аңлатмалар, татар мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбиятын укыту турында методик мәкаләләр, шулай ук укыту рус телендә алып барыла торган татар мәктәпләренең тәҗрибәсен гомумиләштерүче материаллар басыла.

Журналда «Мәктәп һәм семья», «Врач киңәшләре», «Фән һәм техника яңалыклары», «Планета буйлап» дигән һ. б. бүлекләр дә бар. Бу бүлекләрдә урнаштырылган материаллар укытучыларның белемнәрен киңәйтүдә һәм ата-аналарга бала тәрбияләүдә ярдәм итә. «Консультация» бүлегендә урнаштырылган материалларда укытучыларның күп санлы сорауларына җаваплар бирелә.

Журнал язылучылар санынча гына басыла. Подписчикларыбыздан «СОВЕТ МӘКТӘБЕ»нә ел башыннан тулы бер елга язылулары сорала.

ЯЗЫЛУ БӘЯСЕ:

бер елга — 3 сум,
алты айга — 1 сум 50 тиен.

«СОВЕТ МӘКТӘБЕ» журналы Бөтенсоюз каталогына кертелде. Журналга СССРның барлык элемтә бүлекләрендә һәм «Союзпечать» агентлыкларында теләгән айдан язылырга мөмкин. Урыннарда журналга подписка алмасалар, акчагызны түбәндәге адрес белән җибәрегез:

*Казань, ул. Куйбышева, 17/25, областной отдел „Союзпечати“. Для подписки на журнал „Совет мәктәбе“.*

Теге яки бу сәбәп белән аңлашылмау чыкса, редакциягә белдерегез.

Безнең адрес:

*Казан, почтамт, п/я 53. Редакция журнала „Совет мәктәбе“.*

«СОВЕТ МӘКТӘБЕ» журналы редакциясе.

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*КЫРЫК ДҮРТЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

ОКТЯБРЬ **10**

РЕСПУБЛИКА ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАРЫ НӘШРИЯТЫ
КАЗАН 1965

# Бу санда:

## РОМАН, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР


Ш. Маннур. **Муса. Роман.** Дәвамы . . . . . . . . . . . . . 3


## ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР ТАВЫШЫ


З. Маликов, Р. Мингалимов, М. Садыйков, Ф. Шәрифуллин, Х. Хөснуллин һәм К. Мостафин шигырьләре . . . . 62
М. Шәрифуллин. **Кун алъяпкыч.** Хикәя . . . . . . . . . . 79


## САЛИХ БАТТАЛГА 60 ЯШЬ


С. Баттал. **Чирмешән якларында.** Шигъри роман . . . . . . . 91


## ОЧЕРКЛАР


Ә. Маликов. **Якташларыбыз Лена буенда** . . . . . . . . 100
Ю. Седых. **Кхмерлар илендә** . . . . . . . . . . . . . 113


## ФОТОРЕПОРТАЖ


Ф. Абдуллин. Фоторәсемнәр күргәзмәсе . . . . . . . . . . 123


## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Х. Хәйри. **Бүгенге романнарыбызның жанр үзенчәлекләре** . . . . 125


## ТЕАТР


Р. Мостафин. **«Бертуган Таһировлар»** . . . . . . . . . . 138


## КИТАП КҮЗӘТҮ


М. Шәймөхәммәтов. **Шагыйрь белән очрашу** . . . . . . . . 141


## МУСА ҖӘЛИЛ ЮБИЛЕЕН КАРШЫЛАП


Ф. Лешницер. **«Моабит дәтфәре» безнең өчен дә язылган** . . . 144


## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР


М. Мәһдиев. **Коммунист булу — көрәшче булу** . . . . . . . 146


## УКУЧЫЛАР СҮЗЕ


Х. Шәймөхәммәтов, Р. Вәзиев, Ә. Гайнанов, Ә. Фәтхиев хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151


## САТИРА һӘМ ЮМОР


Н. Фәттах. **Тамак шеште. Тәнкыйтьче.** Хикәяләр . . . . . . . 152
З. Нури. **Зарланалар. Киресенчә теләкләр.** Шигырьләр . . . . . 156
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . . . . . . 158


*Редакциягә килгән кулъязмалар кире кайтарылмый.*


Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана 19, Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 52. Редакция «Казан утлары».*

# МУСА

## Роман[1]

Актабанов янында комиссар белән Арыслан гына калды. Ул тагын аңына килде. Кулын Габидуллинга сузарга теләде. Әмма ул көчсез кул барып җитә алмагач, комиссар аны үзе тотып алды.

— Хуш, дустым,— диде командир.— Алып чык кешеләрне... Илгә тапшыр... Исән кайтсаң... Гөлбасканга бар... Балаларымны үп.— Аннары әз генә елмаеп куйгандай итте: — Кучәңгер тавына мен... Анда... өч каен булыр... Ул минем сөю кирәмәтем... изге урын... Беренче... сөйгән... җирем... Кочакла... үзләрен...— Кан сауган күз кабаклары капланды. Кәгазьдәй ак чырае суынып калды һәм Габидуллин учындагы кул, кургаштай авыраеп, салынып төште... Үзе кешеләрдән һични көтмәүче, әмма һәркем өчен үлеп торучы Арыслан яңадан офтанып куйды:

— Эх, тыңламады шул, бөркетем!..

Габидуллин җавап бирмәде. Аның янган яңагындагы төерләре бертуктаусыз сикергәли иде.

— Шушында гына күмәрбез инде аны, име? — дип сорады Арыслан кинәт икенчегә борылып.

Габидуллин мәетне чокырның уртасына күчерде. Сумкасыннан сөлге чыгарып, йөзенә каплады. Аннары, көрәген чехолыннан алып, эшкә кереште. Арыслан да шуны ук кабатлады. Алар икесе дә тирән хәсрәттә иде. Олы җанлы, шигъри күңелле, яхшы дус һәлак булды. Соңгы сулышта да кешеләргә иреккә ашыгырга боерык бирде. Үзе өчен үкенмәде, тәүбә һәм истигъфар әзләмәде, балаларым дип, таудагы зифа каеннар дип, яшьлек гыйшкының кадерле минутларын сагынып үлде. Нинди кешеләре юк бу дөньяның! Үз гомерендә мәхәббәтнең ачы һәм татлы сагышларын әле кичерергә туры килмәгән Габидуллин өчен бигрәк тә тетрәткеч иде бу...

Бу хәлләр, бу эшләр бөтенесе дә биш-ун минут эчендә булып алды. Немецларның шашынып атуы һаман тукталмады. Ул гына да түгел, хәзер аларның әз генә таң беленә башлау белән куа килүе дә ачык сизелә иде. Комиссар белән Арыслан дуслары калган чокырдан бәгырьләре өзгәләнеп чыктылар да, шул ут гөмбәзләре арасыннан уңга-сулга кыйгачлап, алга йөгерделәр. Батальонны үлем биегән бу иңкелдән тизрәк алып китү Габидуллин өстендә иде хәзер. Күренеп тора, батальонның бик күп, бик күп асыл егетләре бу каһәрле урында ятып калганнар. Бар да тынсыз, тереләре берәү дә очрамый. Менә шуларның салкын, канлы гәүдәләренә поса-поса һәм шул гәүдәләр аркылы атлыйатлый, дошман утыннан ераклашырга, йөрәгең телгәләнсә дә, һични эшли алмыйча, шул газиз дусларыңны ташлап китәргә туры килә. Ни кыласың? Бу очракта бүтән бер генә төрле чарасы да юк шул Габидуллинның. Шулай да үзен юатып куйды ул: исән-сау чыгып кына

[1] Дәвамы. Башы 5, 6, 7, 8, 9 саннарда.

житик. Төнлә килербез дә һәммәсен җыеп күмәрбез... Ут һаман ява торды. Ул һаман сикерде-үрмәләде, артыннан килүче Арысланга да борылып карарга вакыты булмады һәм, ниһаять, зур бер төркемгә килеп кушылды. Рота һәм взвод командирлары аны куе зиреклектә көтәләр һәм Актабановның үлем хәлендә икәнен дә теге солдатлардан ишеткәннәр иде. Каршыларына комиссарның үзе генә килеп басуы кинәт барын да аңлатып бирде. Шулай да Габидуллин күзләрен түбән төбәп, авыр бер тынышта торганнан соң әйтте:

— Юлны дәвам итик, иптәшләр, тизрәк!

Байтак кына кече командирлар да һәлак булган икән. Яңаларны билгеләдә. Арысланга да бер взвод тапшырмакчы булган иде, тик үз тирәсендә аны күрмәде. Туктале, кая китеп өлгерде ул, бергә чыктылар бит? Эндәшеп, чакырып карады, башкалардан эзләтте, ләкин Арыслан табылмады... Габидуллин кайгы һәм ачудан үз-үзен өзгәләрдәй булды. Ник борылып карамады ул? Нинди бәхетсезлеккә тарыды соң сыналган дусты Арыслан батыр! Әмма терсәкне тешләү мөмкин түгел иде. Калганнарны алга әйдәргә кирәк!..

Бу урында берхәтле тын алган солдатлар яңадан алга күчә башлады. Немецларның алгы траншеясыннан күп булса ике-өч метр чамасы җир кителгәндер. Әмма бу инде аждаһа авызыннан ычкыну дигән сүз иде. Монда мылтык-пулемет уты әллә ни куркыныч түгел, тик снарядлар, миналар гына һаман ява тора. Хәер, чәчелеп хәрәкәт иткән солдатка анысы да бик зыян китерә алмый иде хәзер.

Төн караңгысына аксыл томан тагын да күбрәк кушыла башлаган күк булды. Алдагы мәйдан ачык бушлык, кайчандыр иген кыры булган урын иде. Сай гына үзәнчекләр дә, сирәк кенә гөлҗимеш яки зелпе төпләре дә күзгә чалынгалап уза. Менә алдагы шундый төпләрнең берсеннән аерылып, өч күләгәнең арттагы уйсуга сак кына шуышканы беленде. Әле яктылык бик зәгыйфь иде, шулай да, бик кистереп карый торгач, боларның соры шинель аркаларын төсмерләргә мөмкин булды.

— Стой, ребята! Мы свои! — дип кычкырды Габидуллин, тыенкы тавыш белән һәм тагын да җәһәтләбрәк алга ташланды.

Әмма тегеләр, ишетмәделәр ахрысы, кызу-кызу шуышуларыннан туктамадылар.

— Свой!

— Свой! — дигән тавышлар тагын кабатланды.

Кәлтәдәй житез шуышкан күләгәләр уйсуга күмелде. Әмма аннан ары чыгып киткәннәре күренмәде. Батальон солдатлары, һаман «свой!» дип, әкрен кычкыра-кычкыра, як-яктан йөгерешеп уйсуга барып төштеләр. Үзләренең өч автоматын өч якка төзәп, алларына гранаталар куеп яткан өч егетне күрделәр алар.

— Не стреляй, ребята! — дип кычкырды бүлекчә командиры Галләмов дигән егет һәм, кочакларын җәеп, алар каршына йөгерде. — Мы не фашисты, у нас только мундир такой! — дип өстәде ул. Башкалар да аның тирәсенә җыела барды.

Тегеләр аягүрә бастылар. Тагын күп кенә солдатлар килеп житте һәм елау катыш куанышып кочаклашулар башланды. Һәркем үзенекен аңлата иде. Бу өч солдат разведчиклар икән. Төн уртасыннан ук немец позициясендә көчле атыш тавышлары ишетелеп тә, утлары безнекеләр өстенә яумау оборонадагы батальон командирын бик гаҗәпкә калдырган. Һәм бу егетләр дә, озак кына күзәтеп ятсалар да, һични аңлый алмаганнар. Менә хәзер, ичмаса, бар да ачык. Командир янына тагын бер батальон пополнение белән кайтачаклар!..

Бу уйсулыкка батальонның җиде йөз кешесе җыелды. Алжыган, талчыккан чырайлы, көйгән яңаклы комиссар тирән сулап, пошынып куйды:

— Авыр булды бу юл... Без аның буйлап биш йөз кешебезне чәчеп калдырдык. Иң яхшы дусларыбызны югалттык...

Шулар арасында Арыслан да бар иде. Габидуллинның иминлеген саклап, артыннан үрмәләгәндә, аның бот итен зур гына мина китеге умырып алды. Күшәрелеп кан ага башлады. Ул аны берничек тә туктата алмыйча, тәмам хәлсезләнеп аңын җуйды һәм яңадан дошман кулына төште...

## VI

Муса Познаньда озак тормады. Мондагы утызлап кеше арасында мәдәни-агарту эшләренең дә яки астыртын хәрәкәтнең дә әллә ни зур әһәмияте юк иде кебек.

Шулай да Мулланур Гәрәев белән Гани Сәләховның сөйләгәннәре шактый гыйбрәтле булып чыкты.

...Беләгенә свастика бәйләп йөргән татар фабриканты Искәндәр Яушев, завод сакчылыгына «үз кешеләрен» китерү мөмкин булгач, бик сөенгән булган. «Ничә әйтсәң дә үз халкың, үз татарың бит, алардан да ышанычлы сакчы булмас!» дип уйлаган (ул да «үз халкың» ди икән әле!). Дөрес, немецлар да яхшы хезмәт иткәннәр аңа. Әмма бик күп сыйланырга, күп ашарга яратканнар, бик кыйбатка төшкәннәр. Анысына да түзгән булыр иде, тик аларны хәзер фронтка җибәреп бетергәннәр, бары ике генә вахтлейтер калган.

Ләкин Яушев шулай сөенеп каршы алган бу «үз егетләр», монда килгәч төрле төркемнәргә бүленеп, үзләренчә хәрәкәт итә башлыйлар. Гәрәев белән Сәләхов тирәсенә оешкан биш-алты кешелек төркем, бер поляк гаиләсе белән аралашып, совет радиосын тыңлау мөмкинлеге таба. Анда ишеткәннәрен үз иптәшләренә һәм заводтагы поляк эшчеләренә сөйли, совет пропагандасы тарата. Гомумән, поляколарны фашистларга каршы аякландырырга тели. Бу өлешенә Муса бик үк кушылып та җитмәде.

— Монысын поляклар үзләре яхшырак эшли алмаслар идеме? — дигән искәрмә ясады ул.

Шушындый эшләре өчен аларның икесен гестапо эләктереп алган. Әмма Искәндәр Яушев, «үз халкы»на яхшылык күрсәтергә теләптер инде, аларны гестапо кулыннан алган да, үз өенә китереп, әлеге чибәр немкасы алдында сабак укыткан: җиңнәрен сызганып, йөнтәс йодрыгы белән күкрәгенә суга-суга: «Күрдегезме, сабакылар, мин нинди кодрәтле? — дигән.— Мин гестаподан өстен, теләсәм — сезне үзем асам, теләсәм — шәфкать күрсәтәм! — дигән. — Барыгыз, моннан соң да шулай кылансагыз, завод капкасы төбендәге фанар баганасында чайкалырсыз!» дигән. Ә «үз егетләр» туктамаганнар. Көннәрдән бер көнне завод цехындагы ток чыбыкларында «кыска бәйләныш» булып, цехның яртысы янып та киткән. Бу юлы инде эшләр шома башкарылган, әллә ниткән очлы борынлы гестапочылар да иснәнеп ис таба алмаганнар.

— Монысы шәп булган! — дип көлде Муса.

Гыймранов дигән асыл егет җитәкчелегендәге икенче бер төркем заводтагы поляклар оешмасы белән аралаша. Алар бергәләп поляк партизаннары өчен күп кенә корал частьлары чыгаралар, әмма көннәрнең берендә бу эш фаҗига белән тәмам була: Гыймранов будкада вахтман постында торганда, аның янына оешма члены пожарник Пшалуцкий килә дә: «Бүген тимер-томыр чыга, син барында чыкса туктатма», ди. Ә «тимер-томыр» дигәне — пулемет частьлары була. Гыймранов бер-бер артлы ике полякны чыгарып җибәрә. Ләкин шунда иснәнеп йөрүче бәдбәхет җан — «ышанычлы поляк» табыла. Ул вахтлейтер Корфка бара да, «ике кешене чыгарды» дип, Гыймрановны чага. Корф аны кулга ала һәм теге пулемет кисәкләрен эзләү, тентүләр

китә. Гыймранов һичнәрсә әйтми, пулемет частьлары да табылмый, аларны поляклар ерак озатып өлгерәләр. Ләкин теге сатлык кемнәр алып качканын белгән була. Беренчесен кулга алалар, икенчесенең өенә барсалар, ул үз кухнясында газ белән агуланып үлгән була. Ә кулга эләккән поляк белән Гыймрановны асалар. Аның белән генә дә түймыйлар: Гыймранов торган бүлмәдә тагын өч кешене — Низамов, Сабиров, Гайфетдинов дигән егетләрне аталар.

— Эх, әдәм башкаеның хакы! — дип көрсенде Муса. — Чынлап та, акыл җитмәслек болар...

Өченче төркемдә Аникин, Туктамышев, Латыйпов һәм тагын бер егет була. Алар шул ук заводта вахтман булып эшләүче поляк карты Домбровский белән танышалар. Ә бу чуалчык кашлы, салам сакаллы карт төнге серле сукмакларның кайсы кая илткәнен бик яхшы белүче булып чыга. Караңгы төннәрнең берендә бу егетләрне дә поляк партизаннарына озатып җибәрә ул.

— Менә монысы әйбәт икән! — дип куйды Муса. — Бу егетләр дөрес эшләгәннәр. Сезгә дә шул ук киңәшне бирер идем.

— Нигә, безнең эш файдасызмыни? — дип сорады Сәләхов.

— Күңелегезгә авыр алмагыз, — дип елмайды Муса, — мин әллә нәрсәсен күрмим... Үз арагызда әллә ни эш алып барасы юк икән, сөйләвегездән күренеп тора: күпчелек аңлы һәм батыр егетләр. Сезгә Аникиннар юлыннан поляк партизаннарына, аннары үзебезнекеләргә кушылу, минемчә, яхшырак булыр...

Егетләрнең бәхәсләшәсе килде. Монда да шул ук патриотик эш булуын әйттеләр, Яушевның заводын күккә очырсак начармыни? — дигән сорауны да куйдылар. Әмма Муса барыбер килешә алмады. Бердән, ул аларның конспирацияне белмәүләрен ачык күрде. Башта ук икесенең гестапога эләгүе, Гыймрановларның вакытсыз һәлак булу сәбәпләре дә шунда кебек тоелды. Икенчедән, заводтагы поляк эшчеләре арасында пропаганда алып баруны аларның үз яшерен оешмасы яхшырак башкарачак иде. Заводны да, кирәк булса, алар остарак күтәртә белерләр. Андый эш цехлар түрендә, шунда эшләүчеләр кулы белән җентекләп хәзерләнергә тиеш. Ә боларга калган егетләрне дә иңртеп, төркем-төркем качу яхшырак. Шуннан соң Яушев завод охранасын поляклардан җыярга мәҗбүр булыр һәм аларның эшләренә кин юл ачылыр.

Мулланур белән Гани Мусаның бу фикерләренә каршы яңадан сүз катмадылар — эчтән килештеләрме алар, юкмы, Муса өчен билгесез иде. Шуннан соң ул аларны үз янына ук ымлап, бик яшерен бер сүз әйтелгәндәге әкрен тавыш белән сорады:

— Домбровский ниндиерәк кеше? Әгәр ярардай булса, сезнең кайсыгыз аның белән таныштыра ала мине?

Картны Мулланур үзе яхшы белә икән, бер мәртәбә өендә дә булган. Аның белән таныштыруны үз өстенә алды һәм карт белән алдан сөйләшер өчен вахтерлар будкасына юнәлде.

Мулланур кичке уңайда Мусаны Вроцлав тыкрыгына алып китте. Соңга калдырма, яктыда алып кил, дигән Домбровский. Караңгы төшү белән немец патрульләре ыжгырына башлый.

Мондагы шәһәрләрнең, һәрберсенең диярлек, иркенләп карап йөрүне сорый торган бик борынгы тарихи һәйкәлләре бар һәм бик кызыклы үзләре. Борынгы Познань князьлегенең үзәге булган бу кала да үзе бер тарих, архитектура, промышленность музее дип әйтерлек икән югыйсә. Әллә ни хәтле бик борынгы биналар, мәһабәт костеллар, искә ныгытмалар калкып кала. Варта елгасы аша салынган таш һәм челтәрле чуен күперләр, яр буендагы бакчалар үзләренә чакыралар төсле. Тугыз яктан шәһәргә килеп керә торган тимер юлларның җиде вокзалын

карап чыгу да кызык булыр иде. Әмма Мусаның, бу кала аркылы инде берничә тапкыр узып та, иркенләп тукталырга һаман вакыт таба алганы юк. Менә бу юлы да ул төнге поезд белән ук Берлинга ычкынырга тиеш...

Алар, Варта елгасын чыгып, шәһәрнең «кара халык» яши торган өлешенә керделәр. Өч-дүрт катлы, бәләкәй тәрәзәле, архитектурасыз соры таш йортлар, тар һәм кәкре урамнар башланды. Берсен-берсе кысышып утыргандай иске таш йортлардан кирәкле ишекне тапкач, «мебель сатыла» дигән фанер кисәге күрделәр һәм ашалып беткән тар гына таш баскычның басмаларыннан атлап өченче катка менделәр. Киезләре таланып беткән бер ишектә тагын шундый ук язу бар иде. Агач саплы звонокны тарттылар. Сөякләре хәзер үк шылтырап коелырга торгандай бер әлмисак карчыгы ишек ачты. «Мебель» диде егетләр (Аларга шулай кушылган иде). Карчык дәшмәде, куллары белән алга таба, уң якка күрсәтте. Кечкенә генә ярым караңгы прихожины узып, зуррак, яктырак бер бүлмәгә керделәр. Анда сыек кына буяулы ике фанер диван, берничә венски урындык куелган һәм өсләренә хаклары язылган иде. Муса белән Мулланур, хакларын кыйбатсынган булып, товарны ошатмадылар.

— Яратмасагыз, базардан алыгыз,— диде, икенче бүлмәдән чыгып, Зигмонт Домбровский. — Анда черегән усактан ясыйлар,— дип өстәде алучыларга хәтере калган сатучы тавышы белән. Аннары Мулланурга кул биреп күрештедә утырырга кушты. Шәрә өстәлдә яткан газета кәгазе белән тартмадагы яшел тәмәкене тәкъдим итте. Үзе челем кабып, сызгырткалап алды. Муса, үз гомерендә беренче тапкыр күрә торган бу кеше белән ничек сүз башлау, ничек тел ачкычы табу турында уйланып килсә дә, әле һаман андый ачкычны таба алмаган иде. Домбровский текәрәк сүзле, кырт сыман күренә. Уен-көлке беләнрәк сөйләшүне кабул итәрме, әллә үзе шикелле кырт әйтү кирәк булыр микән?..

Ә карт, һич нәрсәгә ашыкмаган, исе китмәгән кешедәй, тын утыра, чытык чырай белән челемен пыскыта. Күрәсең, Мусаның үзенә башларга кирәктер. Каян башларга соң? Шулай да бик турыдан суктыру ярап бетмәстер... •

— Мин шагыйрь кеше, пан Зигмонт, — диде Муса, оялган сыманрак кыяфәттә.— Поэзия белән яшим... Шуңар күрә бер йомшак ягым бар: табигатьне, урман кошларын бик яратам... Шулар янына барасым килә...

— Урман кошларын?.. — дип көлеп куйды Домбровский. — Ә минем оҗмахка кереп, шундагы асыл кошларны тыңлыйсым килә... тик гөнаһларым җибәрми. Бөтен бәла шунда.

— Мин анысын ук өмет итмим, үз җиремә таба юл тапсам, күктә эшем юк...

— Кошлар дигәннән, Гареев, кара әле, син, мөгаен, түбәндәге ишекне ачык калдыргансыңдыр әле, — дип, Мусаның сүзен бүлдерде Домбровский. — Өйалдына кеше тавыклары тулгандыр, буяп бетергәннәрдер баскычларны! Бар әле, друзе, Гареев, караштыр әле, ку әле шуларны...

Мулланур үз эшен тиз аңлап алды һәм көлә-көлә чыгып китте. Муса исә картның хәйләкәр күзләренә карады.

— Тэт-а тэт! — ди бугай французлар. Сез дә шулай телисез, ахры, пан Домбровский?

— Парижда булганым юк, белмим,— диде карт.— Әмма янымда колаклар күбрәк булса, хәтерем чуала, сүземне онытам... Димәк, сез кош аулаучы буласыз?..

— Аулаучы түгел... Шулар янында булырга теләүче. Ә сез урман кошлары юлын беләсез икән...

Карт аңа кырыс күзләре белән карап торды, чөлемен пыскытты. Ул әле ачыктан-ачык сөйләшергә теләми иде төсле.

— Юк, әфәндем, мин берни дә белмим,— дип кырт кисте ул.

— Дусларчарак сөйләшик әле, — диде Муса, көлемсерәргә теләп. — Безне бит ике тату илнең илчеләре дияргә була. Әнә сез безнең дүрт лачынны очырып җибәреп, нинди изгелек эшләгәнсез! Ә шундый кошлар сансыз читлекләр тулы бит. Минем дә аларны сезнең лачыннар янына очырасым килә...

Ул дүрт егет турында да әйтеп биргәч, карт артык киреләнүнең мәгънәсен тапмады. Гареев сөйләгән, күрәсең. Ә пан Зигмонт Мулланурны төпле егет саный иде. Һәм аңа ышанып кына бу кешене кабул итәргә ризалык бирде ул. Димәк, ул сорагач, шикле әдәм түгелдер... Шулай да үз кырыслыгын сакларга тырышты, артык җәелеп китмәде.

— Теш төбемдә корт булдыгыз! — диде карт, ниһаять, әз генә елмайгандай итеп. — Читлекләрегез кайда?

— Радом тирәсендә. Едельня урманы буенда...

— Соң алай булгач, нигә җирдәгене күктән эзлисез? Пан Радзевильнең кайчандыр күзлеге югалган, имеш. Ул аны Берлиннан барып эзләгән. Тапмаган. Ә кайткач, йокларга ятканда караса, хатынының панталон бөрмәсенә эләнеп тора, имеш! Син дә шуның шикелле. Урман буендагы кошларың өчен Познаньга юл эзләп килгәнсең.

— Гаҗәп түгел, — дип көлде Муса. — Колумб Индияне эзләп Америкага барып чыккан. Без дә бит монда океан эчендәге шикеллерәк. Чит ил... Аннары шунысы да бар: әгәр тылсымлы йомгакның очы күренеп ятса, кем барып тотынмас иде аңар?..

— Ярар, — диде карт. — Озак әрепләштек, җитәр. Едельнядан якын гына биш йортлы хутор бар: Сидици. Шунда Пжишко дигән кәтүче булыр. Әгәр исән булса, калганын ул әйтер.

— Ә «догасы» ничек? — дип сорады Муса.

— «Пан Пантелей сәлам әйтте». — «Дзякую». «Саулык теләде». «Дзякую». «Ак карчыга куыш эзли кара төндә». — «Дзякую»... Әгәр шушы өч рәхмәтнең соңгысын әйтмәсә, «булдыра алмыйм» дигән сүзе булыр. Калганын инде үзең карарсың.

— Дзякую, карт бөркет! — диде Муса һәм Домбровскийны кочаклап алды. — Әмма бик кырыс икәнсез!

— Ярамый, — дип башын чайкады карт. — Хәзер урман юлы эзләүчеләр күп. Аларның төрлесе бар: чүпрәкләре дә, уголовниклары да, шпикләре дә. Икәүдән-икәү ничек кенә сөйләшсәң дә куркынычы юк, ул сине гестапога тотып бирә алмый.

Муса канатланды. Аның хәзер үк Пжишко янына очып китәсе килде. Әмма хәзергә сабырлык кирәк, беренче батальон шау-шулары басылганчы Берлинда булу яхшы иде. Ул анда ашыкты.

— Хуш, кадерле дус! — диде ул. — Күрешербезме — юкмы, әмма еракларда адаштырылган бәләкәй шагыйрьне, үз иленә тизрәк кайту юлларын эзләп йөргән коммунист Муса Җәлилне, ничек тә бер искә төшерегез. Иң күңеллесе: җиңү бәйрәмендә янадан кочаклашу булыр иде. Тик... белмим...

— Бел! — диде карт. — Кочаклашырбыз. Сиңа моны коммунист Болеслав Баржик әйтә!

— Амин! — диде Муса көлеп һәм шул чырае белән чыгып китте.

Түбәнге баскычта, чынлап та, берничә тавык белән бер йолкынып беткән әтәч кайнаша иде. Муллануp аларны, нәрсәдер сибеп, «кет-кет» дип әкрен генә чакыра да, тегеләр килеп чүпләнә башлагач кына, пыр туздырып куып төшерә. Шулай итеп үзенә эш тапкан, ә күзләре урамда, алтынчы йорт тирәләрендә иде. Андый-мондый шикле кеше күренмиме, янәсе.

— Синең эш кызыклы икән, — диде Муса.

— Нишлисең бит, өйгә олы кунак килсә, бала-чаганы һәрвакыт шулай урамга куып чыгаралар инде...

— Кайчагында кәнфит тә бирмиләр хәтта, ә!..

Муса төнге поезд белән Берлинга китеп барды.

## СИГЕЗЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

Муса беренче майда иртәнге якта кайтты. Кайту белән Шәфи комитетына барып, аның янына керде. Беренче батальонның язмышы турында тизрәк беләсе килә иде аның. Кайларда икән ул хәзер?..

Дөньяда бер гаме дә булмаган җилбәзәкләрчә авыз ерып, күзләрен хәйләле кысып, тегенең йөзенә карады. Тукта, чыраен сытмасмы? Юк, сытмады. Димәкки, монда әле Шәфи өчен бер күңелсез хәбәр дә юк... Шуннан соң ул үзенең башкарган эшләре һәм бик күңелле сәяхәте турында сөйләп китте.

— Познаньда булдыгыз бит, нишләр кыланып яталар соң анда? — дип сорады Шәфи, кисәк кенә.

Моның мәгънәсен Муса шунда ук төшенеп алды: димәкки, андагы хәлләр монда да килеп ишетелгән... Белмәмешкә салыну шикле булачак иде. Һәм Муса ул хакта кыскача гына сөйләп бирде дә әйтте:

— Әмма мин андагы хәлләргә артык пошынмас идем, Габдрахман әфәнде. Чөнки алар безнең солдат түгел бит. Бездән киткәннәр... Шулай булгач, Яушев әфәнде үз кешеләре өчен үзе кайгырсын! Ә безнең батальоннарда хәлләр тыныч. Солдатлар бик яхшы өйрәнә, беренче батальон юлга чыгарга калды...

— Үзем дә шулай уйлыйм уйлавын,— диде Шәфи.— Әмма ликин теге фабрикант хат язган бит. Әйтерсең, мин гаепле монда!

— Үз кайгыбыз да күп, — дип куйды Муса, — башкалар өчен хафаланмыйк әле!

— Әлбәттә, әлбәттә...

Муса, аның сүзләрендә әйтелеп бетмәгәнлек сизеп, байтак кына көтеп утырды. Төрле сораулар белән кытыклап та карады. Әмма Шәфидән башка хәбәр чыкмады. Күрәсең, әле аңа теге ике мари егете турындагы хәбәр дә килеп җитмәгән. Ул хакта ләм-мим бер сүз кузгатмады. Әгәр Зикендорф хәбәр иткән булса, ничек тә сораштырыр иде бит...

Муса иптәшләре белән очрашырга ашыкмады. Соңыннан. Барысы бергә сөйләшенер. Ә хәзергә көн саен иртә белән Шәфи Алмаз хәзрәтләренең нурлы йөзен укыр өчен йөгерү кирәк. Әмма икенче майда да, өченче майда да ул әле һични укый алмады. Маклерның кыршылып беткән җыерчыклы озын йөзендә, шыксыз чыгып торган бит сөякләрендә, пыяла артына качкан комсыз күзләрендә бертөрле дә үзгәреш күренми иде әле. Ерактагы изге Магдалинасын «ак үрмәкүч» дип, ә янындагы Мага ханымны «оҗмах зөбаные» дип мактый. Бары шул гына. Нигә бик озак соң? Кайларга барып тәрәлделәр икән соң алар?..

Дүртенче майда да Муса иртүк аның кабинетына сугылды. Әмма Шәфи анда юк иде. Муса үз бүлмәсенә чыгышлый Гариф Шабаевтан сорады. Ул аны ОКВга чакыртуларын әйтте.

Менә көндезге уникеләрдә, ишекләрне каты ачып, үз алдына шаулап, көмгәдер тиргәнә-тиргәнә, Шәфи кайтып керде. Аның тыны-көне бетеп ачуы ярсыганы, шул ук вакытта яман куркуга төшкәне Мусага ябык ишек аркылы да беленеп калды. «Башлана башлады, ахрысы!» дип уйлады ул.

Бераздан Шәфи үз кабинетына яраннарын җыйды. Мусаны да чакырып керттеләр. Шәхси сәркатип Гариф Шабаев та шунда иде. Муса

ишектән керү белән үзе укыйсы килгән «китап»ка карады. «Китап» дигәнебезнең чырае киткән, бәбәкләре күзлегенә бәрелердәй булып акайган, күз төпләре, бит җыерчыклары капчыкланып төшкән, аскы ирене салынган һәм маңгае тирләгән иде. Муса өчен барысы да аңлашылды. Ул, куанып, күзләрен читкә чөерде һәм почмакка барып утырды. Башкача бу «китап»ны укып торуның кызыгы калмаган иде инде.

— Нәләт кенә орсын! — дип өстәл сукты Шәфи. — Безнең татармы? Безнең татар башыңны ашар ул! Күпме көч түктем: җыйдым, ирекка чыгардым, үлемнән коткардым! Нихәтле тәрбияләдем! Милләт, азатлык әләмен тоттырдым кулларына! Менә сиңа шуның рәхмәте... Качканнар! Качканнар сасы дуңгызлар! Чәнчелеп беткерләре! Этнең башын салсаң табакка, ул тәгәри тагаракка!..

Беркем бер сүз дәшмәде. Бу яңа хәбәр артык дәрәҗәдә көтелмәгән, зур һәм авыр иде. Муса белән Гарифтан башкаларны, таудан тәгәрәгән тегермән ташыдай, кинәт сытып узды ул. Моңарчы күңел күзләре белән дөньяга карарга куркып йөрүче, фәкать немецның эрзац ипиенә, әсирлек лагереннан чыгаруына канәгать булып, юк-бар хыяллар белән юанып яшәүче кайбер укымышлы егетләрне тетрәтеп җибәрде. «Бу маклер конторында эшләүнең соңы ни белән бетәр?..» дигән сорау туа башлады ул адәмнәрдә.

Шәфинең гаять дәрәҗәләрдә «ачыйгланып» карганулары, елардай булып «заригъ» кылулары тәмам булды. Монда утыручыларның да һәрберен сукырлык күрсәтүдә шелтәләп, әрләп чыкты ул. «Барыгыз да әрәм тамаклар сез!» дип кычкырды. Аннары легионны ныгыту өчен үзенчә бик катгый чаралар билгеләде, таяк дисциплинасы кертүне тәкъдим итте. Батальоннарга яңа һәм бик шәп пропагандистлар җибәрергә булды, газетында милли вәгазьне көчәйтергә кушты.

— Барыгыз, юлга әзерләнегез! — диде ул, иң актыктан. — Һәммәгезне дә шунда куам, ятмагыз монда ипи черетеп!..

Яраннары чыгып киттеләр. Туфли бавы чишелгән кешедәй, юри әбәгәрләнеп, Муса арткарак калды һәм, кеше беткәч, яңадан Шәфи янына әйләнеп килде. Вакыйгане ачыграк беләсе килә иде аның.

— Нәрсә соң, Габдрахман әфәнде, чынлап та, бик күңелсез хәлләр булганмени? — диде ул, борчылган кеше тавышы белән.

— Булмаган кая! Һай, булмаган кая инде ул! — дип өзгәләнде Шәфи. Һәм кинәт Мусага карап катты. Аның яшькелт-соры күзләре, күкне капшаучы төнге прожектор шикелле, Муса карашыннан озак кына итеп шикле нокта эзләде. Моны шунда ук отып алган Муса, бөтен түземлелек көчен җигеп, гадәттәге көлемсәр карашын бер генә секундка да үзгәртмәде, күзләрен дә читкә бормады. Гаеп таба алмаган Шәфи, ниһаять, яшел күзләрен үзе читкә юнәлтте һәм зарлануын дәвам итте. — Сезгә дә сорау бар, Муса әфәнде. Сез бит, анда идегез, нәрсә карадыгыз? Мәдәни агарту эшләрегез йомшак, милли тәрбиягә көч куймыйсыз. Кемнең ничек сулаганын күзәтмисез.

— Бар инде, бар, Габдрахман әфәнде, бездә дә гаеп бар, — диде Муса, йонны уңай якка сыпырып. — Өлгереп буламени, бер үзем ич. Ә солдатларга сүзеңне тыңлатуы шактый кыен. Саботаж, ишетәселәре дә килми. Ләкин мин киткәндә ул батальон юлга чыкмаган иде әле. Мин егерме сигезендә киттем, һични сизелмәде...

— Шулай инде ул безнең татар, тамагы туйдисә киртә сикерә башлый. Аларны кайгыртып йөргән мин җүләр. Кырылсыннар иде шунда көзге чебеш шикелле, ачлык лагерьларында!.. — Шәфи кызганнан-кыза барды. Аның сүзләре күплеге, эчен бушатасы килгәнлеге күренеп тора иде. — Ике йөз немесне турап салганнар бит, ходаем, башың бетәр, башы-ың! — дип сузып куйды ул көрсенүле тавыш белән. — Ә немесләр шуңа җавап итеп ике батальонны тезеп атарга телиләр!..

— Туктагыз әле, Шәфи әфәнде,— диде Муса, сагая төшеп.— Сез әле

һаман вакыйгане ачык кына әйтеп бирмисез. Бергәләп киңәшер идек. Алай гына тезеп ату бөтенләй ерткычлык була түгелме соң?..

— Булсын әйдә, булсын! Бетерсеннәр! Барыбер мине торгызмаслар. Чәнчелсен әйдә! Этләргә калмасын мал! — һәм ул, өстәлдәге беләкләренә йөзен каплап, тиле кешеләр тавышы белән ыхылдый башлады. Муса аны юатырга мәҗбүр булды. Менә бит нинди ахмак хәл.

Шәфи, ниһаять, ыхылдаудан арынып, башын күтәрде. Аның өчен «борчылып», җилкәсенә кулын салган Мусага ниндидер якынлык хисе сыман нәрсәсе уянып китте һәм, ярым елмаеп, батальон турында ишеткәннәрен сөйләргә кереште.

... Немесләрнең берсе исән калган икән. Ул нәләт нәрсә бик хәйләкәр булып чыккан. Беләк итен автомат пуләсе умыртып киту белән җиргә капланган да үлек иптәшләре арасында ята биргән. Үз каны белән бит-күзләрен дә буяп өлгергән. Әмма батальон тиз-тиз урман эченә кереп киткән. Кичке караңгы төшкәч, бу немес үлекләр арасыннан торып, стансага чапкан. Андагы бәләкәй гарнизонга вакыйгане сөйләп караса да, файдасы чыкмаган. «Судагы чуртанны тотып кара син! Бездә андый көч юк», дигәннәр. Немес токтан да легионга кайткан һәм Зикендорфка барын да сөйләп биргән. Зикендорф егылып китә язган. Ләкин тиз айнып өлгергән, чөнки моның өчен үзенә нәрсә булачагын күз алдына китергән, күрәсең. Шуннан соң ул теге яралы немесне ераграк госпитальгә озаттырган да (андый куркыныч шаһитләрнең күз алдында булмавы яхшы!) Берлингә чапкан. Иң элек Шәфи белән Унгляубене күреп киңәшкән. Алар да үзләренең башлары кая тәгәрәячәге турында бик тиз уйлап өлгергәннәр. Тик шуннан соң гына ОКВның Көнчыгыш бүлегенә барып, яңа бер әкият сөйләп биргәннәр: «Витебск юнәлешенә җибәрелгән беренче батальон тулы тәртип белән, һичбер «чепе»сез фронтка килеп җиткәндә бәхетсезлеккә очраган. «Чикләвек күле» дигән пунктны узып, куе урман һәм сазлыклар аша җәяү барган чакта, һич тойдырмастан, көчле белорус партизан полкы килеп чыгып, батальонны чолгап алган. Чигенер урын булмаган. Батальондагы ике йөз немес, батырларча сугышып, кырылып беткән. Легион егетләре дә байтагысы кырылган, әмма калганнары бирелергә мәҗбүр булганнар. Шулай итеп, аларны белорус партизаннары алып киткәннәр...»

Бу әкиятне юриспруденция докторы Унгляубе әфәнде уйлап чыгарган. Моның буенча легион башлыгы Зикендорф та, «Идел-Урал»ның зондерфюрере Унгляубе әфәнде үзе дә, президент буласы Шәфи Алмаз да качкан батальон өчен турыдан-туры гаепле түгел, ә белорус партизаннары гаепле. Чөнки алар кинәт һөҗүм итмәсә, батальон үз пунктына исән-сау барып урнашкан булыр иде бит!.. Әмма шушы йомшартылган вакыйга да немецларны бик нык ярсыткан.

— Шул ике йөз немец урынына ике батальонны тезеп атарга! — дип кычкырган ОКВдагы Көнчыгыш бүлеге башлыгы, Гамбургтагы сәнгать академиясе члены Людерсон әфәнде. — Белорус кырган өчен татар түләсен! Бар да бер этләр!

— Клайнһандлер[1] Альмазны алып ташларга! — дип өстәл төйгән Розенберг әфәнде. — Башка кеше табарга! Акыллыракны!

Зикендорф белән Унгляубегә дә шактый эләгү ихтималы булган. Ләкин, кабат-кабат уйлаша торгач, кызышкан дәртләр беркадәр суына төшкән. Әгәр бу хәбәр фюрергә барып җитсә, уйлап-нитеп тормый торган ефрейтердән үзләренә дә шактый өлеш тиячәген абайлап алганнар. Шуңар күрә бу «чүп»не өй почмагындагы себерке астыннан хәзергә чыгармыйчарак торырга булганнар...

Шәфи шуларның һәммәсен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде дә «уф!» итеп куйды.

[1] Вак сәүдәче.

Муса шунда гына уйлар дөньясыннан уянып китте. Шәфинең мескен йөзенә карады һәм аны, карт шүрәлене кытыклагандай, кытыклыйсы килде. Нинди «уф!» тагын сиңа? Батальон үз бурычын намус белән үтәгән — бик яхшы иткән! Рәхмәт ул лачын егетләргә! — дип кычкыра язды. Гел бу сүзләр дорфа да булсын, үчегү булып яңгырасын, әмма Муса барыбер үзенекен эшләр иде. Нәфрәтнең матур булуы мөмкинме? Дошманның муенына кылыч салганда, аның күлмәге канга буяла дип борчылу көлке булмас идеме?..

— Я, ник дәшмисең? Киңәш сорыйм синнән! — дип көрсенде Шәфи.

Муса күзләре өчен Шәфи нинди дер ераклыкта иде. Чырай чалымнары ачык беленмәгән, гәүдә карачкысы бушлыкка җәелгән билгесез бер шәүлә булып кына күренә иде ул. Мусаның бу үле шәүлә белән бер дә сөйләшәсе килми иде хәзер. Хәтта кабинетның һавасы бетеп киткәндәй тоела башлады. Әллә кайчангы иске көн исләре, суны күп сибүдән чери башлаган гөл кисмәге исләре, әллә кайсы почмактан гына чыгып борынны яра торган күсе бәвеле исләре, һәммәсе бергә буталып, Мусаның башын томалый шикелле тоелды. Ә тәрәзә аша нинди матур яз, нинди кояшлы көн балкый. Мусаның тизрәк-тизрәк шунда чыгып китәсе, бөтен шатлык һәм куанычларын дуслары белән уртаклашасы килде. Ул тәрәзәдәге күзләрен Шәфигә борды: кемнән киңәш сорап утыра бу?..

— Киңәшме? — диде Муса. — Киңәш бар. Мин бик милләтче кеше. Немецларны үч алу, кан коно ниятеннән кайтарырга кирәк. Партизаннарга эләккән батальон өчен калганнар гаепле түгел. Аннары килеп, милли тәрбия эшләрен чынлап торып көчәйтик. Мин дә үз өстемә төшкәнне икеләтә эшләрмен. Менә сәхнә әсәре куясы иде, артистлар да тели, солдатлар да сорыйлар. Ә безнең хатын-кыз ролен уйнаучыбыз юк. Остарбайтерлар арасында берничә татар кызы бар икән. Һәйбәтләр генә үзләре. Менә шуларны артистлар труппасына җибәрәсе иде...

Шәфи Алмаз уч төбе белән ияк очындагы керпесен ышкып куйды.

— Һе, шуның белән легионны ныгытырбызмы инде без? Ә ул кызлар анда «кети-кети» уйнап ятсалар?..

— Юк, — диде Муса. — Әйбәт кызлар алар.

Шунда телефон шалтырады. Шәфи ашыкмый гына трубканы алды. — Алло. Әйе. Остминистериумга? Хәзер...

— Розенберг чакыра, — диде ул. — Тагын ниләр күрәсем бар икән, ходаем? — Тиз-тиз портфеленә кәгазьләр тутырып, эшләпәсен киде.

— Хәерле юл, әфәндем, коелып төшмәгез бик! — дип калды Муса.

## II

Немецларның, чынлап та, күзләре шар хәтле булды. Караңгыда кинәт чоңгылга абынган кешенекедәй, телләре тешләнде, сүз әйтә алмас булдылар. Тикшерүләр, допрослар һәм аңлатма язулар китте. Таудай кәгазьләр өелде. Аларның берсендә дә немец бу күңелсез эштә үзен гаепле итеп күрсәтми иде. Юк, бөтен гаеп ферфлюхте азиатларда! Мәкерле җаннар! Итәк астыннан ут йөрткәннәр. Немец иткән яхшылыкка каршы яманлык белән җавап кайтардылар.

Зикендорф әфәнде бигрәк тә өзгәләнде. Ул беренче батальонны нинди тантаналы итеп озатуын, үзенең нинди дәртле речь сөйләп татарларны мактавын хәтеренә китерде. Алардан да сөйләүче булды бит: «Без үз өстебезгә төшкән изге бурычны намус белән үтәрбез, — диде. — Татар егете кирәк чакта арыслан дай батыр була белә һәм ул үз азатлыгы өчен җанын аямас!» — дип җавап бирде. Һәммәсе дә әшәке ялган булган икән!

Күрәсең, алар озак вакытлар хәзерләнеп килгәннәр. Бу хәл немецларның йоклап калуын күрсәтә түгелме соң?.. Юк, нигә йокласыннар, кирәк булганның барын да эшләделәр. Батальон һәм аерым командалар

саен гестапо бүлекчәләре бар, солдат арасына шымчылар куелган, рота саен пропагандистлар, тәрбиячеләр, муллалар эшли. Шуның өстенә һәр командирның диярлек «ышанычлы кеше»ләре бар. Берлин комитетында да «күз-колак» җитәрлек. Андагы һәр кешенең артында бер күләгә тора. Хәтта Шәфи Алмазның үз артында да Солтан дигән бик өметле «юлдашы» бар. Шулай булгач, немецларны гамьсез диярга мөмкинме соң? Һич юк! Үз кулына эләккәнне ничек тотарга кирәклеген бик яхшы белә немец!

Ә шулай да... Ә шулай да татар батальоны качкан! Һәм ике йөз дойчны кырып киткән. Машинадан аударып ташлаган утын шикелле, юл өсте тутырып, аркылы-торкылы өелеп ятып калган алар. Нинди халык соң бу татар дигәнең? Нинди географик төшенчә?.. Әле шушында, немец кул астында, шулай кыланган алар, ә үз җирләренә барып керсәң, нишләтерләр иде? Башыңны койрыгыңа бәйләп җибәрмәсләр идеме?.. Майданекка, Маутхаузенга тутырырга кирәк аларны!

Шулай итеп, утлы табага баскан немецлар, иң элек солдат кулындагы коралны җыеп алып, складларга бикләделәр. Солдатны унбиш көн буе беркая чыгармадылар. Бөтен казармаларда тентү үткәрелде. Шымчылык тагын да көчәйтелде. Гаеп итәрдәй бер генә кешенең дә, бер генә нәрсәнең дә табылмавы аларны тагын да ярсыта төште, батальон солдатын тезеп атарга бик кыҗырап йөри башладылар. Тик бернәрсә аларга комачау итте: башка халыклардан төзелгән дистәгә якын легионнар да бар бит, аларга нинди тәэсир ясар ул? Алары да баш күтәреп, поляк партизаннарына качмасмы?..

Шуңар күрә алар татар легионын, энә күзеннән үткәргәндәй җентекләп, яңадан ныгытырга тотындылар. ОКВның күп кенә офицерлары, Шәфи комитетының бөтен аппараты, хәтта Шәфи үзе дә, Унгляубе белән фон Менде әфәнделәр дә ун-унбиш көн буена батальоннарда яттылар. Шәфи, әлбәттә, Мусаны да үзеннән калдырмады. Ләкин немецлар хәзер аңардан шактый шикләнәләр иде. Үзенә әүвәлгечә үк елмаючан булсалар да, артыннан гел күз уйнатып тордылар, Шәфигә дә аның һәр адымын ныграк күзәтергә кушылды. Һәрвакыт сизенү һәм эчке киеренкелектә йөргән Мусаның мондый чакларда атлана торган үз тулпары бар иде: ул тәүфикълы гына кыяфәт белән татар музыкасы сәнгате турында лекцияләр укыды. Әшәке пропаганда белән авыз пычратмас өчен бердәнбер чара иде бу.

Немецларның бу яскануы нәтиҗәсендә, шикле күренгән берничә кеше концлагерьга җибәрелде. Бәхеткә каршы, Муса егетләренә җил-яңгыр тимичә калды. Габдулла Баттал тирәсендә әйләнгәләделәр әйләнүен: холкы шау-шулырак, теле тиктормас булганга, «анархише цунге»[1] дип атый иде аны немецлар. Әмма тимәделәр тагы. Күрәсең, бәйләнердәй ачык дәлил таба алмадылар.

Икенче батальондагы искәнүләр тагын да туйдыргычрак булды. Күпме чокчынсалар да теге төнге вакыйганең җеп очын таба алмадылар, солдатны телдән яздыру мөмкин булмады. Шуннан соң, исән калган мари егетләрен төрле урынга урман эшләренә тараттылар.

Батальоннарга хәзер әллә нихәтле яңа вәгазьчеләр, яңа пропагандистлар, яңа муллалар, яңа шымчылар билгеләделәр. Шулар арасында урта буйлы, тыңкыш тавышлы, яньчегрәк борынлы һәм күзлекле Мәмүт Ямалтаев дигән яңа бер егет тә күренә башлады...

Унгляубе әфәнде юридик яктан нык «исбатланган» яңа лекцияләр укыды. «Коммунистлар колхозчының бөтен икмәген кырып-себереп алып бетерә. Сезнең гаиләгез ач-ялангач, анда хәзер үлән ашыйлар, агач кайрысы кимерәләр. Мал-туарлары да фронт өчен алынып беткән. Каршы килгән кешеләр атыла, төрмәгә, Себергә озатыла. Большевиклар үзлә-

[1] Анархист тел.

ренең җиңелгәнен бик яхшы белеп тора, шуның өчен аларга халыкны ачка үтерү, кырып бетерү берни дә түгел. Сез моның шулай икәнен үзегез дә беләсез бит. Колхоз кырыннан бер кесә арыш алып кайтканда тотылсагыз, ун елга төрмәгә китүегез хәтерегездәдер. Хәзер анда тагын да имансызрак кылыналар! Инде авылларда ир заты калмагач, фронтка сезнең хатын-кызларыгызны китереп тутырдылар. Алар сугышалар, ә кып-кызыл битле коммунистлар авылларда, шәһәрләрдә, завод-фабрикларда, НКВД һәм милициядә түрә булып утыралар, халык җилкәсендә майда йөзәләр...»

Аннары килеп, Унгляубе икенче темасында татар, башкорт, мари, мукшы һәм чуваш халыкларының милли хисләренә тукына иде: «Сезнең муеныгызга урыс атланган. Инде ничә йөз ел буена ул сезне чыбыркылап куа. Бөтен хокукларыгызны җиргә таптаган, сезнең илләрегез урыс колониясе. Ә Европада сезнең шикелле кече халыклар иркле яши. Алыгыз Данияне, Финляндияне, Швецияне, Норвегияне, Люксембургны. Аларның үз дәүләтләре, үз хөкүмәтләре бар. Без аларга тагын да киңрәк хокуклар бирәчәкбез. Ә сезнең илләргә барып җиткәч, анда да шундый ук тулы иркле хөкүмәтләр төзеләчәк. Фюрер моның өчен үзенен рыцарьлык вәгъдәсен бирде...»

Муса һәм иптәшләре өчен бик җитди яңа кыенлыклар килеп туды. Дошман белән тешкә-теш килмичә булмый иде. Аның коткысын хәзер үк фаш итәргә, аның агуыннан солдат күңелен саклап калырга. Ниһаять, оешманы бик нык активлаштырып, мөмкин кадәр тизрәк легионны алып китәргә кирәк иде. Әмма бу юлы Муса боларның берсен дә эшли алмады. Һәр җирдә фашист офицерлары, Шәфи Алмаз әдәмнәре кайный иде. Хәтта Карип Ишбулдинга хәтле килгән иде монда. Ул да эшем кәшесе бит! Шуңа күрә Муса теге поляк карты янына да бара алмады. Шәфиләр белән килде һәм шулар белән китәргә мәҗбүр булды. Тик соңгы минутта гына Гайнан Кормашка кечкенә бер хат кисәге төртә алды.

Берлин кешеләре, машиналарга төялеп, китеп баргач, Кормаш «Серле чишмә» янына китте (алар аны шулай атыйлар иде хәзер). Рушатов белән Зиннәт Хәсәнов килде. Мичурин белән Сәйфелмөлекев килде. Кош теледәй кечкенә бу хатны шунда укыды Гайнан. Сәйлән бөртегедәй вак кына хәрефләр белән болай язылган иде:

«Уяулыкны бик нык көчәйтергә. Дошман сүзен сүз белән үтерергә. Һәр солдат белән аерым сөйләшегез. Унгляубе тезисларының ялган икәнлеген көн-төн фаш итегез. Иң куркыныч нәрсә ул! Үзегездә җитмәгән материал бездә табылыр, кеше җибәрегез. Төп ориентация: тиз вакыт эчендә оешкан рәвештә «ПП» белән кушылу. Солдатны шуңа хәзерләгез. Озакламый үзем дә килермен».

Ә Берлинга кайткач, берсе артыннан берсе килеп чыккан яңа вакыйгалар куерып китте. Алар Мусаны хәтта аяктан егып ташладылар...

## III

Моннан берничә көн генә элек, Мусаны сорап, Әлбидә килгән булган. Өйдә юклыгын әйткәч, кайчан кайтуын кат-кат сораган. Ә кайчан кайтачагын Алиш ачык кына әйтә алмаган. Мусаның Әлбидәне күптән күргәне юк иде инде. Теге кайтуында да күрешергә вакыт тимәде, чөнки аны Шәфи үзе белән тиз арада тагын легионга алып китте, унбиш көнләп йөрергә туры килде. Кайткач Алишның бу сүзне әйтүе аны уйга калдырды: ни өчен килгән иде икән? Берәр тәҗел йомышы булды микәнни? Хәер, бәлки сагынып кына килгән булгандыр. Элек тә шулай килеп чыккалый иде бит ул...

Күп уйланып ятты Муса. Инде төн уртасы әллә кайчан узган. Бараклардагы кешеләр бар да йоклый, кайберләренең ыңгырашып куйганы ишетелгәләп китә. Ә Муса, йокы барлыгын да онытып, уйларының очына

чыга алмый изалана. Әлбидәнең шундый хисләрдә булуы аны бик кыен хәлгә куя иде. Үзе әллә ни зур проблема да түгел шикелле. Ләкин уйлаган саен аның яңа үрентеләре үсеп чыга. Яхшы һәм кадерле кешегә булган мөнәсәбәтеңне ачык билгеләргә кирәк. Аның изге хисләренә, йөрәк ярасына ваемсыз һәм дорфа суык кул белән кагылу булмасын. Күрәсең, моның иң кыены — һәрвакыт ихлас күңелле һәм нәзәкатьле була белүдәдер.

Мусаның әле Волхов урманнарында чакта ук күңеленнән яза башлаган бер шигыре бар иде. Бер дә көтмәгәндә Әлбидә дигән кыз белән очрашу, ә ул кызның шундый матур итеп «Сагыну»ны җырлавы бу шигырьнең беренче юлларын тудырган иде шикелле. Андагы фаҗигале язмыш ул шигырьне тәмамларга да, Әлбидәгә укырга да мөмкинлек бирмәде. Менә хәзер ул юллар тагын аның күңелендә кабатлана башлады:

Кызык кына булды бу очрашу,
Син ерактан, мин дә ерактан.
Ә күптәнге, якын танышлар күк,
Кул кысыштык икәү йөрәктән.
Исемемне дә юньләп белмисеңдер,
Үзең шундый сөеп карыйсың.
Йөрәгемнең язгы гөлләр төсле
Саф булуын сиздең, ахрысы...

Шигырь дәвам итүне сорады. Күңеленә берен-бере ияртеп килгән хисләр, алдагы көрешүдә әйтәсе килгән сүзләр һәм ул гүзәл хәсрәт иясен сөендерергә теләү аның тынгысын җуйды. Торып, почмагындагы бәләкәй утын яндырды. Мусача вак сәйлән бөртекләре карандаш очыннан кәгазьгә сибелде. Юк, бертөрле дә иҗат газабы кичермәде ул. Кайчакта бер фикерне әйтер өчен ничә бит кәгазь буйыйсың. Барыбер әйтәсе килгәнең әйтелеп җитмәгән була. Ә бу юлы сүзләр үзләре сайрашып агылдылар, әйтерсең, көтмәгәндә килеп туган шифалы яңгыр!..

Безнең гомер тулы һәр ваклыкка,
Эчпошыргыч ямьсез бушлыкка;
Нәрсә җитә менә шундый матур,
Шундый керсез, кайнар дуслыкка!..

Аны акыл көрчеге дә кыса алмады. Йөрәге кушканны чикләнмичә әйтә бирде:

Нәрсә җитә: синең күзләреңнең
Ялкыныннан шулай кабынып,
Яшәү җирдә гомер ахрынача.
Назлы карашыңны сагынып,
Мин үзем дә белмим, нәрсә безне
Бәйләде соң аера алмаслык?!
Без сөйләшеп түгел, серебезне
Күз карашы белән аңлаштык.

Чынбарлыкта алай ук түгел иде түгелен. Танышулары бик үк гади шартларда булмаса да, тормыштагыча бик гади «Исәнме, саумы, кайсы яклардан» һ. б. шикелле сүзләр белән генә башланып китте бит. Серләрен күз карашлары белән генә аңлашып йөрерлек вакытлары да булмады, камалышта иде бит алар. Әмма нишлисең, шигырь үзенекен итә инде ул... Аның үзенә генә хас серле карашлары, романтик зәңгәр төстәге җилкә җиләннәре һәм башка атрибутлары булмый калмый. Муса да аларны сикереп уза алмады. Шул ук вакытта чын хисләреннән дә тартынмады ул.

Шундый назлы, гади күз карашың
Шагыйрь йөрәгеме аңламас?
Сөяксез тел кайчак алдаса да,
Күз карашы, җаным, алдамас.

Еллар үтеп, тагын бер очрашсак,
Яшерә алмый шатлык яшемне,
Мин кулыңны кысып, чын күңелдән:
— Сердәшем! — дип сиңа дәшермен.

Барын да әйтте шикелле. Кызның яратуын аңлавын да, үз йөрәге тавышын да һәм сердәш итәр дәрәҗәдә дус итүен дә... Энҗеләр сибелүдән туктады. Ул яңадан тапчанына ятты...

Бу аның легионнан кайткач беренче төне иде. Берлин төннәре шактый тынычсыз һәм хәвефле үтә икән хәзер. Бигрәк тә, икенче яртысы. Әле моннан унбиш-егерме көн генә элек самолет гөрелтеләре, зенитка тавышлары, авыр фугасларның җирне урталай ярганда ыңгырашлы тибрәндереп куюлары бу хәтле үк сизелерлек түгел иде. Хәзер ныклабрак тотынганнар икән эшкә...

Муса күп тавышлар арасыннан бер тавышны тыңлап ятты: Берлин өстендәге төнге кошлар арасында безнекеләр дә бармы?.. «Тыңлап ята торгач, Көнчыгышка табамы, ничектер шул яккарак ерагаеп баручы гөрелтеләр дә ишетелгән күк булды. «Безнекеләр, безнекеләр!» дип елмайды ул йомык күзләре белән. Шул очып китүче егетләргә кул болгап калгандай булды. Һәм күңеленә ниндидер тынычлык иңде, ниндидер сабыйларча горурлык тойгысы урнашты. Бу аңа тын гына йоклап китәргә мөмкинлек бирде.

Иртәгесен эштән соң Аккүлгә ашыкты ул.

Май ае, табигатьне яшел хәтфәләр һәм нәзек ефәк чәчәкләр белән киендереп, үзенең язгы тантанасын итә. Аккүл буе аллеяларындагы һәммә яшел үсенте, немец кайчысы белән текмә-тек китереп кыркылган булса да, табигатьнең бу матур бәйрәмен монда да күрү мөмкин иде. Өемөем булып утырган ыктымат кына сиреньнәр җәйге кичнең офыгы төсле ал-күгелҗем канәферләрен кояшка каршы җәйгәннәр. Хәтта клумба гөлләре дә әллә ничә төстәге чуарлыкларын күрсәтә башлаганнар. Тын гына яткан су өсте — төпләрен югары күтәреп үскән юан агачлар сурәте белән аклы-зәңгәрле почкаклар кыстырып бизәлгән ниндидер олы һәм тылсымлы бер келәмне хәтерләтә. Ул кайчакта әз генә тибрәлеп куя һәм синең битләреңә йомшак җил канатлары килеп кагыла.

Табигатькә гомумән гашыйк Муса, мондагы зәгыйфь матурлыкка да сокланып, Әлбидә белән беренче тапкыр очрашкан истәлекле эскәмиядә утыра иде. Күзләре узган-барган кешеләрдә булды аның. Көткән кеше әле һаман күренми иде. Ни өчендер иптәшләре дә күзгә чалынмый. Шул ук немец полицайлары үз юлларында йөреп торсалар да, узган көзгә караганда кешеләрдә җанлылык күбрәк сизелә төсле. Күрәсең, яз үзенең куәтле сулышы белән терелтеп җибәргәндер инде аларны. Әллә башка сәбәпләрнең дә йогынтысы бар микән? Көзен бит өермә Көнчыгышка таба тәгәри иде. Ә хәзер язгы давыл кояш баешына таба ыргыла. Монда каңгырып йөрүчеләр өчен, ихтимал, моның тәэсире зуррактыр...

Ниһаять, Муса теге вакытта танышып калган олы яшьтәге бер хатын күренде. Аның исеме Мәрьям иде бугай әле. Ул туп-туры Муса янына килеп утырды. Төсе әүвәлгечә үк боек, хәсрәт билгеләре йөзендә ярылып ята. Өс-башында да шул ук кыршылган иске-москы нәрсәләр. Әз генә елмайгандай итеп, исәнлек-саулык сорашты. Авыз читендәге ул якты җеп бөртекләре шунда ук сүнде. Озак кына сүзсез торды. Аннары, кайчандыр чәчәкле булган кофтасы эченнән чыгарып, Мусага күксел конверт сузды. Муса конвертны һични уйламастан кулына тоткан килеш әйләндергәләп карады да:

— Хат? — дип сорады, аптыраган кыяфәт белән.

— Әйе, — диде хатын, басынкы гына. — Әлбидәдән...

— Әлбидәдән? Нишләп, үзе килмимени?

Хатын ниндидер телсез хәрәкәтләр ясады: үзен тыеп тотарга тырыштымы, әллә урыны көйсез идеме.

— Юк шул... — диде ул, баягы ук тонык тавыш белән. Иңенә салган иске шәл почмагындагы укмашкан чукларны бөтерде. Ун бармагы да тик тормый иде аның. Ә күзләре, самовар җизе аркылы караган төсле, елтырый да, кайнар да шикелле һәм шул ук вакытта җансыз да иде. — Мин сине өч көннән бирле көтәм инде монда...

Әлбидәнең эзләп килүе келт итеп Мусаның исенә төште. Һәм ул әлеге сүзләр белән шуның бәйләнешен эзли башлады. Нәрсә соң бу? Нинди шомлык?

— Һични аңламыйм,— диде ул, тирән аптырау хәлендә.— Нигә соң Әлбидәкәй үзе килмәде?

Ниһаять, хатын түзә алмады: шәл чуклары тоткан куллары белән ике битен каплап үксеп җибәрде.

— Ул килә алмас инде... Ул юк инде...

— Ә-һ?! — дип, Муса урыныннан сикереп торды. Шул ук сулышта йөрәгенә ниндидер очлы нәрсә кадалган шикелле чәнчеттереп алды, шундук тез буыннары хәлсезләнеп китте. Күптән инде бу хәлнең булганы юк иде. Ул, авып төшкәндәй, янадан эскәмиягә утырды. Һава житмәгән сыман еш-еш сулый башлады. Дөнья кинәт үзенең төсен җуйды. Әле генә сокландырган иркә чәчәкләрен ниндидер зәһәр кырау сугып ташлады. «Ул юк инде...» — Шул өч сүз һаман колак төбендә яңгырады. Әллә соң бу хатын акылдан язганмы, нигә һаман шул сүзләрне кабатлый?.. Юк, ул түгел бугай... Муса уң кулы белән йөрәк өстендәге мускулларын угалады. Ә йөрәге һаман әле чәнчеп-чәнчеп ала иде. Ул бүтән бертөрле сорау да бирмәде. Ерактa калган март төнен, җимерек биналардан очраклы рәвештә калган яшерен базны һәм андагы Толстой кашлы, Толстой сакаллы Бакшановны ничектер үзеннән-үзе хәтерләп алды... Янәшәсендә утырган хатын да, бу вакытта сулкылдавыннан арына төшеп, нидер сөйли иде инде.

...Уңайлы сәгатьне күп көткәннәр. Союзниклар авиациясе бу тирәгә һаман килмәгән. Ә җир астындагы цех-лабораториядә «Фау»ларның иң зурларын сынау башланган. Ахырда Шилов картның боерыгын тапшырган. Комсомольское задание: Фая, Әлбидә, Сания цехка идән себерүче һәм деталь юучы булып керергә тиеш. Урнаштыру чараларын Шилов үзе тапкан, әмма болар янына билгеләнгән ике егетне берничек тә уздыра алмаган. Кызлар егерме көн шунда эшләп, кайда нәрсә барлыгын өйрәнгәннәр. Кызларны тентеп кертәләр, тентеп чыгаралар. Шулай да Әлбидә, ботинкасының олтан кырыена беркетеп, бритва кыйпылчыгы йөртү хәйләсен таба. Калын бетон идән эченә куелган реактив ягулык багыннан юан резин шланг сузыла. Бак тирәсеннән узганда һәм лабораторияне җыештырган чакта, ул көн саен шлангны әз-мәз ышкыштыргалый... Сания белән Фая бакыр чыбык кисәкләре җыеп, станоклар арасындагы күз төшмәс ярыкларда саклап киләләр. Моннан дүрт көн элек, төнге сменада, алар үз эшләрен башкарырга тиеш булалар. Нәкъ шул төнне Аккүл районында да һава тревогасы бирелә. Күршедәге эшче кварталларны, хәтта заводның шул кырыйдагы кайбер цехларын ялкын чорный. Әмма читтә, астарак торган цех-лабораториянең исән калачагы шундук мәгълүм була. Кызлар соңгы карарга киләләр. Убежищегә агылучылар ташкыны белән йөгерешкәндә, башкаларда шик тудырмый гына аерылып, үз эшләренә китәләр. Немец охранасы янгын сүндерә. Фая нечкә чыбыкларны бер-беренә ялгый, Сания тырнаклары белән ток чыбыгының изоляциясен әрчи. Әлбидә исә әлеге бритва белән юан шлангны кисәргә тырыша. Юка корыч кисәге сынгалап бетә, шуннан соң ул идәнгә ятып, шлангны тешләре белән кимерә башлый. Болар һәммәсе дә шашкын тизлек белән эшләнә...

Сүзләр, Муса колагына килеп җиткән саен ниндидер автомат чүкеч шикелле, дөк-дөк бәреп куялар. Һәм ул бәрү нәкъ Муса йөрәгенә туры

килгән төсле була. Энҗедәй матур тешләре белән тупас шлангны кимереп җәфаланучы Әлбидәнең гүзәл сурәте күз алдыннан китми...

Хәсрәт тулы куркыныч сүзләр һаман дөк-дөк бәрелә торалар: ниһаять, әлеге калын шлангтан нечкә генә агым идәнгә сибелә башлаган. Моны күргәч тә Фая ярым подвал тәрәзәсенә йөгерә: ул андагы бер пыяла өлгене тавышсыз гына алып, өчесенә дә юл ачарга тиеш... Ул ара да булмый, әрчелгән ток чыбыгына Сания үз чыбыкларын китереп кушуга вак кына электр очкыннары чәчри һәм әлеге реактив сыекча «гөлт!» итеп кабынып та китә. Сания үзе баскан станок өстеннән идәнгә сикерергә дә өлгерми, итәкләрен ялкын чорнап ала. Әлбидә аны коткарырга ташлана, әмма үзе дә абайламастан, шашкын ялкын белән уралган була. Бик ачы тавыш белән тик бер генә тапкыр кычкырып өлгерәләр:

— Фа-а-ая-а-а!..

Пыяла алганда бармаклары суелып, канап беткән Фая өскә йөгереп менүгә аның битләренә көчле ялкын килеп бәрелә, чәчләре четердәп китә. Биш-алты гына адымда йөзтүбән капланган ике дусының ут кочагында ятуын күрә. Актык көчтән аларга таба ыргылган Фаяны шашып дулаган ялкын кинәт артка бәреп ега. Ул тимер баскыч буйлап түбән тәгәри. Ә Сания белән Әлбидә былбыл...

Сөйләүченең йөзенә карамаска тырыша Муса. Ләкин ниндидер эчке күзләре белән күреп тора: күзләреннән яшь таммаса да җаны елый Мәрьямнең. Муса аны юатырлык бер сүз дә таба алмый. Андый сүз юк икән дөньяда! Бары тик баягыча өзгәләнеп «һә-э-эх-хх...» дип кенә куя. Ә күңелендә сәгатьләр буена сөйләп бетерә алмаслык сагыну һәм зар, сагыш һәм хәсрәт, чәчәктәй ике гомернең шулай үзәк өзгеч кинәт киселүе өчен үзен гаепле санау, үкенү һәм әрнү. Әрнү!..

Сөйләүче, озак кына сүзсез утырганнан соң, урыныннан кузгалды. Әлбидә белән Сания гәүдәсенең янган калдыкларын өченче көн җирләүләрен, ә Фаяның бик авыр хәлдә больницага озатылуын әйтте. Янына кертмиләр, гестапо кешесе каравыллап утыра, диде.

— Ярый, Муса абый, кичке сменага ашыгам, хушыгыз. Безне онытмагыз, — диде ул аннары һәм авыр адымнар белән китеп барды...

Муса җансыз хәрәкәтләр белән генә исәнләшеп калды. Дөнья һаман шулай төссез, эч туңдыргыч суык иде. Һични күрмичә, ниндидер бер үле ноктага караган килеш ул һаман шулай утыра бирде. Аның гәүдәсен кыймылдый алмаслык авыр таш баскан шикелле иде. Бары тик теле генә хәлсез хәрәкәт белән шигырь юлларын кабатлады:

> Кинәт кенә ачы язмыш җиле
> Аера сине якын дусыңнан...
> Соңгы тапкыр үбү һәм күз яше,
> Чыкмый аннан мәңге исеңнән.
> Күпме булды минем якын дуслар,
> Күпме иде сөйгән иптәшем.
> Калдым ялгыз: саклап яңагымда
> Һәркайсының кайнар күз яшен...

Ниһаять, аның күзләре, ничектер әлеге үле ноктадан күчеп, һичбер кызыксынусыз-нисез генә агач яфракларында, күл өсләрендә, аллеядан узган-барганнарда гизә башлады. Бер генә нәрсәгә дә тукталып калмастан, нидер эзләгәндәй итенделәр. Ләкин бу күзләр һични эзләми, һичкемне көтми иде инде... Куптәннән бирле эскәмиядә онытылып яткан әлеге күксел конверт шул адашкан күзләргә килеп эләкте. Муса аны беренче тапкыр күргән нәрсәдәй итеп кулына алды. Шунда гына аңына килеп, калтыравык бармаклары белән конвертның бер башыннан ачуга, Әлбидәнең рәсеме килеп чыкты. Астында кәгазь кисәге дә бар иде. Мусаның адашкан карашы рәсемгә текәлде һәм аның авыру йөзе әз генә яктырып киткәндәй булды. Әлбидәнең бөтен мәһабәтлеге күренде аңа. Күзләренең саф тирәнлеге, йомшак дулкын чәчләре өстенә бер

кырыйдан нечкә генә булып сибелгән көмеш төтене, әз генә бөгелгән тәвәккәл кашлары, авыз почмакларындагы нечкә генә хәсрәт сызыклары. чыраена ниндидер сөйкемле кырыслык биреп, кабатланмас гүзәл итеп күрсәтте аны. Караган саен рәсемгә җан керә баргандай булды. Муса аны үзенең ачы хисләр тулган йөрәге белән, яртысын ярып бирердәй үз җаны белән тергезде. «Ник соң мин сине саклый алмадым, ник элгәрәк башыма килеп, элгәрәк легионга озата алмадым?..» дип, нәкъ беренче тапкыр югалткандагы шикелле үкенечле сүзләрен кабатлый-кабатлый, аның белән сөйләшеп утырды. Шундый кадерле дусны югалту фаҗигасе аны тагын изә башлады. Шул хәленнән арынып өчен хатка тотынды ул, ләкин Әлбидәнең хатын уку тагын да авыррак булып чыкты.

«Сөеклем дип әйтергә хакым булмаган сөеклем! — дип башланган ул. — Бу куркыныч юлга мин үзем теләп басам, әгәр теләгемә ирешә алсам, үз язмышым ни белән бетсә дә, үкенмәячәкмен. Син шундый фидакарьлектә йөргәч, мин дә үз сөйгәнемә тиң буласым килде... Гаеп итмә, Муса абый. Беләм, сине сөяргә хакым юк иде минем. Ике гөнаһсыз җанның бәхетенә кул сузу кебек иде бу, хәтта зур җинаять сыман күренә иде. Әмма нишлим, саф йөрәгемә кереп утырган үзсүзле мәхәббәтне җиңүдә мин көчсез булып калдым. Сөйгәнемнән һәм бу фани дөньядан һични таләп итмичә, сөя бирдем. Шул сөюем белән мин бай идем, бәхетле идем, очар коштай канатлы идем. Әгәр бу юлымны намус белән үтәп, исән калсам, киләчәктә дә шулай булырмын... Минем өчен кайсыдыр шагыйрь болай дигән:

Гомеремдә бер кат сөю килде,
Иң бөектән бөек шул иде...
Хуш, күз нурым. Язмыш көтә мине.
Көрешмәсәк, бәхил бул инде...

Төчерәк тоелса да, минем хәлгә туры килә төсле. Хуш. Кара язмыш безне кая чөерсә дә, онытма, дускай. Кичер мине...»

Мусаның йөрәге күкрәк читлегенә сыя алмый шикелле. Тар анда, кысрык... Нинди олы, гүзәл җан бу Әлбидә, нинди саф күңел! Улмы соң кичерү сорар кеше? Аныңмы соң гаепле булуы мөмкин? Юк! Мең тапкыр юк! Челтерәп аккан чишмә суыдай шундый саф хисләрне, ир егетнең батырыннан батыр булып чыккан шундый гүзәл кызны кирәгенчә бәяли алмаган, вакытында коткарып өлгермәгән өчен Муса үзе гаепле түгелме соң? Аның изге туфрагы алдында тезләнеп, үзе кичерү сорарга тиеш түгелме? Ничек оныта алсын ул аны? Юк, бу хат белән бу рәсемне мәңге саклар ул. Һичкемнән яшермичә, бу минем үлем дәрьяларын бергә кичкән фронт дустым! дип, олы горурлык белән әйтеп бирер. Алай гына да түгел, ул үзенең бөтен талант көчен, бөтен йөрәк ялкыннарын биреп, Әлбидәнең матурлыгын һәм батырлыгын сөйли торган җыр язар. Исән генә кайтсын, татар кызының шушы бөек, саф һәм батыр образын тудыру аның изге бурычы булачак!..

Кояшның кичке нурлары сүрелеп, язгы салкынча сизелә башлаган иде инде. Муса, үзенең ярым җимерек биленә астыртын суык йөгерүен тойса да, һаман шул хәлендә ут йотып утыра иде. Бакчада кешеләр дә сирәгәйде, немецның «сакчы фәрештәсе» дә ике тапкыр сөзеп әйләнде, ул һаман кузгалмады. Аның болай үз-үзен җәзалап утыруы, ихтимал, бик озакка сузылган булыр иде, тик көтмәгәндә булган икенче бер хәл аның уйларын чуалтып ташлады.

«Сания! Сания!» — дип йөрәк зары белән кычкыра-кычкыра, кемдер аллеялар буенча ярым йөгереп узды. Муса аны баштарак күрмичә дә калды. Тик ул кеше, шашкын күзләрен төрле якка айкый-айкый, шулай кычкырып узгач кына, кинәт тетрәп китте. Тукта, нәрсә бу?.. Кем «Сания!» дип кычкыра? Юк, булмас, галлюцинацияләр бу...

Әмма алай булып чыкмады, күлнең аргы башларында тавыш яңадан кабатланды һәм ул кешенең теге ярлардан әйләнә килүе беленде. Бу, чынлап та, Симай микәнни соң? Чынлап та, егет шундый коточкыч хәлгә барып җитте микәнни?.. Я ходай, чынлап та, сугышчы гыйшкымы бу?..

Кабат әйләнеп килүендә Муса аны эндәшеп туктатты.

— Муса абый? Синме бу? Сания кайда? Кайда соң Сания?.. Кичә генә шушында иде бит, канаткаем! — диде ул, урыныннан купкан күзләрен төрле якка йөгертеп. — Кичә генә!..

— Кичә генә?.. — дип аптырап калды Муса. Нәрсә сөйли бу? Зиһене чуалган түгелме соң?

Ул аны култыклап алды һәм, ашыгыч арада телонә килгән очраклы сүзләр белән юатырга тырышып, эскәмиягә утыртты. Дусының мондый аяныч хәле бу минутта аның үз кайгысын ничектер читкә этәргәндәй булды.

— Син тынычлан, Әхмәт, тынычлан, — диде ул салкын кан белән генә сөйләгәндәй итеп.— Үзеңне болай бетермә...

— Эх, Муса абый-й! Син дәме белмисең безнең ничек яратышканны? — диде ул, бөтен йөрәк әрнүе белән һәм эскәмия терәгенә салган беләгенә йөзен каплады. Аның иңбашлары гына сикергәли иде. Муса артык сүз белән борчымады, һәрвакыт сугышчан рухлы, көләч йөзле, уенчыл сүзле яшь дустының аркасыннан сыйпаштырып кына утырды. Беркавым узгач, Симай үзе башын калкытты. Аның күтәрә алмас авыр хәсрәт караңгысы саргайган йөзеннән ниндидер якты бер кыл сызылып узгандай булды.

— Без бит өйләнешмәкче идек... Кечкентәй генә туебыз буласы иде... Ул бит әле унсигез яшьлек кенә былбыл баласы. Туйсыз ничек инде ул? Сине көткән идек... — Симайның күз төпләреннән солдатча эре, кургаш тамчыларыдай авыр яшьләр тәгәрәп төште. — Син инде аеп итмә, йөрәк маем, — диде ул. — Немес үтерә салып пыткалаганда да яшь күрсәткән кеше түгел мин... — Һәм ул күлмәк изүләрен шытырдатып ера-ера, сикереп торды да аллея буенча тагын йөгерде. — Саниям! Саниям!..

Муса аның артыннан ташланды. Куып җитеп, яңадан култыклады.

— Әхмәт, тынычлан, әйдә кайтыйк, ял итик... Алар икесе дә тиңсез геройлар. Без аларны үзебез җыр итеп, халык күңеленә сеңдерербез! — Ул шундый юату сүзләре белән Әхмәтнең чәбәләнә башлаган нерв сапламнарын рәткә китерергә теләде, Симайны ничек тә булса метрога таба әйдәргә тырышты. — Әйдә, дускаем, кайтыйк, караңгы төшә...

— Да, Санияне шушында калдырыпмы?..

Муса ни дип җавап бирергә дә белмәде. Аның үз нервлары да кинәт шартлап өзелер хәлдә киерелгән иде. Шулай да, актык җегәрен Симайга сарыф итеп, аны юмалый-юмалый, көчкә метрога кертеп утыртты. Ниһаять, алып кайтып яткырганнан соң, маңгаена салкын сулы чүпрәк куя-куя, янында утырды. Әхмәт төн буе саташып чыкты. Ярый ла, ярсып, кузгалып китүләре булмады, ыңгыраша-ыңгыраша эчтән көйде ул. Инде ир яшендәге таза һәм сылу егетнең кан уйнап торган йөзенә лимон сарысы чыкты. Бу аның йөрәге һәм бөтен организмының нык какшавы билгесе иде.

Иртүк аның хәлен белергә Алиш, Гариф һәм Фоат килде. Симай аларны танымадымы, әллә хәле хәттән ашкан идеме, авыз ачып сүз әйтмәде, күз керфеген күтәрмәде. Кайгырышу белән генә эш бетми, егетне больницага салу кирәк иде. Шуңар күрә дүртесе дә көн буе төрле ишекләрне кагып, кичкә таба гына Әхмәтне гади бер лазаретка урнаштыра алдылар...

## IV

Әлбидәләр белән булган бу фаҗиганең үзәк өзгеч ачысы әле әз генә дә сүрелә башламаган иде, Муса һаман моңаеп, бу зур һәм үкенечле югалту белән һич кенә дә килешә алмыйча һаман боегып, күңеленнән туктаусыз үзен әрләп йөри иде. Бик күп уйлады ул, әмма күпме генә уйланса да җиңеллек килмәде. Йөрәгенең бу авырттыргыч ярасын вакытлыча гына булса да онытып тору өчен тизрәк батальонга китеп эшкә чуму, солдатны һәм кирәкле командирларны тизрәк хәзерләп житкереп, бу убыр оясыннан тизрәк үзебезнең якка чыгып китү генә бердәнбер чара булып күренде аңа. Ул шунда җыена иде, әмма нәкъ шул чагында аның баш очына килеп кукрәгән икенче бер коточкыч хәбәр Мусаны бөтенләй изеп ташлады.

Кичә аны Шәфи Алмаз үз кабинетына чакыртты. Акыл өйрәтергә җыена торгандыр инде, дип уйлаган иде Муса, тик алай булып чыкмады. Ул кергәндә Шәфи кабинетында шактый ук таланган киемле яшьрәк бер кеше ишеккә аркасы белән утыра иде. Муса аңа артык игътибар итмәгән кук, ул кеше дә шунда ук борылып карамады.

— Менә, — диде Шәфи аптырабрак, — яңа әсир китерделәр. Эсбиҗи, урыс әйтмешли. Әмма кире беткән нәрсә, теле тырнаклы, һич игә китерә торган түгел. Бәлки, сезне тыңлар, Муса әфәнде...

Шунда гына егет ялт борылып Мусага карады һәм, сикереп торып, «Муса аб...» дип кычкырып куйды да кинәт тотлыгып калды. Әйтерсең, аның теле тешләнде. Сикереп торганда ук йөзенә чыккан яктылык кинәт өреп сүндергәндәй булды. Күрешергә сузылган кулы түбән салынып төште. Күрәсең, ул Мусаны мондый шома кыяфәттә һәм бу кеше кабинетында күрермен дип башына да китермәгән булгандыр. Шактый тынып торгач кына кыр сон егет яңадан телгә килде һәм сүрән генә тавыш белән: «Исәнмесез, Муса әфәнде» диде дә урынына утырды.

Мусаның күкрәгенә таш белән китереп суккандай булды, хәтта тулганып та китте бугай әле ул: чөнки аның каршында Әминәнең әнисе ягыннан чыбык очы тиешле бер кардәше, ә Мусаның кече кодасы Мирхәт Лотфуллин дигән егет басып тора иде. Мирхәт, Мәскәү егете булса да, Казанда финанс институты бетергән кеше. Шул яшьлек елларында шигырь белән кызыксынып, матбугат йортындагы җыелышлардан калмыйча, язучылар дөньясы белән дә танышып йөргән иде. Институтны бетерүгә армия сафына алынуы гына аны шигырь зәхмәтеннән арындырды булса кирәк. Әйе, теле тырнаклы шул Мирхәтнең. Үзе дә туры төтенле, принципиаль, хәтта бераз кирерәк сүзле, ләкин керсез күңелле, алдауйолдауны, хәйлә-мәкерне белми торган егет иде ул. Житди кеше дөресен сөйли, дөресен эшли дип ышанучан гадәте бар аның...

Муса кече кодасы белән кул сузып күрешергә, сөйләшергә теләде, хәтта аңа таба омтылыш та ясады шикелле, ләкин горур Мирхәт кабул итмәде. Мусаның бу ниятен сизеп алгач та, аркасы белән борылып утырды. Икеләтә хурлык газабы кичерә иде ул хәзер. Бердән, шундый танылган татар шагыйренең, коммунистның, Мирхәт уенча, шулай дошман курчагы булып йөрүе иң зур кабахәтлек, түбәнлек, хурлык иде. Ничек ул шундый кешене яратып, аңардан поэзия серләре өйрәнеп йөрде икән?.. Икенчедән, ул аңа җизнә тиешле кеше бит әле! Монысы тагын бер хурлык! Синең якыннарың арасында шундый хыянәтче булуы нинди зур оят, кеше күзенә карый алырлык түгел! Җизнәсе шундый бәдбәхет әдәм булуга Мирхәтнең дә киләчәктә җавап тотасы булыр әле. Мәскәүдә чакта ук ишеткән иде бит, әмма ышанып бетәсе килмәгән иде, күңеленең кайсы почмагындадыр шик калган иде, менә хәзер үз күзләре белән күрде инде... Бу аңа үзенең пленга эләгүенә караганда да зуррак бәхетсезлек булып тоелды.

Бу егет Муса белән дә сөйләшергә теләмәгәч, Шәфи шактый вакыт аптырап, башын чайкап утырды.

— Әйттем бит, кире беткән дип. Кызыл шул, хәтта үтә кызыл, — диде ул, кәефе кырылып. — Лагерьларда Лаеш суын туйганчы эчмәгән әле. яңарак кына эләккән, Курск янындагы сугышларда гына... Үз файдасын белми, тиле. Мин аңа нинди яхшы эш кушам: советлар финанс һәм экономикасы шартлау турында китап язарга, шул хакта газетта мәкаләләр биреп барырга. Һәйбәт гонорар түлим, яхшы язса — аерым мәкафәт тә вәгъдә итәм. Ә ул һаман үз киресен сукалый. Хәзер барыбер пленный инде син, энкәш. Тәти күлмәгең барыбер пычранган!..

Егет сикереп торды һәм шулхәтле җирәнү, гөберле бакага кул тидерергә мәҗбүр булган кеше кебек, шулхәтле чиркану төсе белән чыраен сытып, очларында нәфрәт очкыны гына калган күзләрен кысып, башын бер якка чөерде дә әйтә салды:

— Эх сез, әдәм актыклары! Мәкинә сибеп лачын тотмакчы буласыз. Юк, чыпчык кына алдана ул фашист мәкинәсенә! Әнә бит, янығызда тора: бер кызганыч һәм җирәнгеч чыпчык эләккән инде сезгә. Шул җитәр! Ә мине: хыт асыгыз, хыт сугыгыз, хыт алтыннар белән, матур фахишәләр белән күмегез, хыт тагын әллә ниләр вәгъдә итегез — сатылдым юк! Илем дошманы фашистка хезмәт иттем юк! Юк һәм юк!

— Милләтеңә хезмәт итәсең, алла колы! Идел-Урал мәмләкәтенә, — диде Шәфи, кырыс тавыш белән. — Кем фашист монда? Чамалап сөйләш! Укымышлы кеше икән — лагерьда үлмәсен дип кенә тырышуым, җәлтәфит!

— Әллә нинди үлгән сүзләрегез белән мыскыл итмәгез мине бай абзый! — диде егет, һаман кабына барып. — Мин әсир булганым өчен генә сезнең алда кол түгел. Мин — Советлар Союзы гражданины! Каршыгызда күкрәк кагып сөйләшә алам! Төкерәм мин сезнең ярдәмегезгә!

— Чү-чү, энкәш, бик сикермә! Кикригең тиз шиңәр монда!

— Шиңмәс! Куркыту белән генә хыянәтче ясый алмассыз! Сатылучының миллионларга бер генә булуы мөмкин: әнә, презренный мәкинә чыпчыгы Муса Җәлил шикелле!..

— Мирхәт! — дип кычкырды Муса, артык түзә алмыйча. — Уйлабрак кылан!

— Уйлабрак? Син сатлык җан алдындамы? Ха-ха-ха! Ә син соң уйлап сатылдыңмы? Ватаның, хатының, балаң, туганнарың — ничә бакыр тора, әфәндем? Әллә көмеш тә бирделәрме? Һәммәсен дә сугыш давылы себереп узар, күмелеп калыр дип уйлагансыңдыр инде, куркак җан! Әмма бел, кабахәт! Синең фашист ялчысы булуың Мәскәүдә дә, Казанда да билгеле! Моңарчы сине шагыйрь дип, татар халкының намуслы егете дип ышанган кешеләрнең ачулары яман, нәфрәтләре чиксез сиңа! Алар синең ялган җыентыкларыңны себереп утка якканнар, балаларны алдап язган шигырьләреңне дәреслекләрдән чыгарып ташлаганнар, музыкадагы сүзләреңне салдырып ыргытканнар! Ул гынамы соң? Синең аркаңда күпме гөнаһсыз кешеләр җәфа чигә! Күпме кешене бәхетсез иттең син? Әминә апаны Казандагы квартирасыннан куганнар, Мәскәүдәге иске бүлмәгезгә кертмәгәннәр, үзен эшкә алмыйча йөртеп, каядыр Себергә сөргәннәр. Ә Чулпан әбисендә ятим яши. Зәйнәп туганың Колымага озатылган. Хәдичә сеңелең, фронтта радистка булган җиреннән кайтарылып, Түбән Тагил шәһәренә куылган. Алар көн саен, сәгать саен сине каһәрләп, кан-яшь түгәләр! Менә кем син, ялчы койрык! Халык дошманы син, халык дошманы! Эх, автоматым янда булса! Бер генә сиптерер идем мин синең шахшы йөрәгеңә!.. Хәер, шушы кулларым белән дә, — ул, ике кулының ун тарафка тырпайган ун бармагын тау бөркете тырнакларыдай кәкрәйтә төшеп, Мусага таба ыргылган сыман булды, — әйе, шушы кулларым белән дә буып ыргытыр идем мин син хәшәрәтне, син кара җыланны! Тик кул пычратасым килми. Чөнки алар чиста, алар

сатлык акча тотып пычранмаган, хыянәтченең үз туганнарын суйган канга буялмаган! Тукта, йөзеңә төкерим ичмаса мин синең! Аяз көннең яшенедәй күзеңне чыгарсын! Ләгънәт мөһере булып маңгаеңда калсын! — һәм бу зәһәр егет җан ачуы белән «лач» итеп Мусага төкереп тә җибәрде...

Мусаның күз аллары күптән үк караңгыланып, башы әйләнә, каршында әллә нинди вак җеннәр сикерә-сикерә бии, ә дөнья, диңгез штормындагы бәләкәй каек шикелле, һәлакәт хәлендә чайкала иде. Шулай да ул үзендә көч табып, читкә тайпылып өлгерде һәм үзе дә тересәген җәеп, бармакларын тырпайтып, Мирхәт өстенә ташланырга теләде. Тик шул сулышта күзенә Шәфи чалынды да Муса үзен тотып калды. Ә Шәфи Алмаз, кашларын дугаландырып, ниндидер мыскыллы ләззәт белән көлемсерәгән хәлдә, аяк керпесен сыпыргалап утыра иде. Кызык бит! Бакчи бу көзге әтәчне, күпме нәрсә ачып салды! Күпме табыш ясады Шәфи абзагыз! Муса әфәндегезнең койрыгы бозга каткан икән ләбаса! Борылыр җире калмаган. Бик шәп, бик шәп!..

Шәфинең күзләреннән шуны укыды Муса һәм Мирхәткә тагын ныграк ачуы килде. Дошманны сөендерә бит ахмак! Әгәр бу агуларын Мусаның үз өстенә генә түккән булса, бу хәтле авыр да булмас иде. Бәлки, аңлата да алыр иде. Ә монда нишлисең?.. Үзен тотып калу, үз бармагын үзе каерып чыгару шикелле авыр булды аңа. Дошманны көлдермәскә кирәклек кенә тыеп калды аны. Юкса, бу кече коданың олы җизни буларак, яңагыннан ут күчерергә кирәк иде! Шулай да Муса бер сүзсез кала алмады, тагын нидер белергә теләде.

— Кем төяде сиңа бу ялганны? — дип сорады ул.

Егетнең боларны аңа Төхфәт Фазлый сөйләгәнне әйтәсе килмәде. Чөнки Муса аның белән бик үк дус түгел иде бит, шулай булгач, ышанмавы мөмкин. Ә Төхфәт абыйсының дөрес сөйләвендә Мирхәтнең шиге юк. Хәзер генә Көньяк фронттан, сугыштан кайтып төшкән капитан, коммунист һәм шундый җитди кеше, шигырь язучы, ни өчен ялган сөйләсен? Ул бит Муса хакында шундый хәбәр йөрүенә борчылып сөйләде, хәтта кызганулы тавыш белән. Аннары ул аны өенә алып китте, тиң күреп чәй эчертте, «Алтынчәч» афишасын күрсәтте. «Нәҗип Җиһанов операсы» диелгән. Ә «Муса Җәлил либреттосы» дигән сүзләр юк. Аның бер шигыре дә кертелмәгән дәреслек китабын да шунда күрде Мирхәт. Шулай да аның күңелендә актыкка бер өмет сүнеп җитмәгән иде әле. Ул Тәхәүдән чыгу белән Столешников тыкрыгына ашыкты. Әминә бүлмәсен ике-өч тапкыр какса да, җавап булмады. Коридорда бер карчык күренгәч, аннан сорады. «Чулпанчик әбисендә булса кирәк, ә Нинаны белмим...» дип кенә куйды. Карчыкның бу сүзләрендә әйтелмәгән мәгънә ярылып ята иде, Мирхәт аны бик яхшы төшенде, шул утны йотып яңадан фронтка китте һәм менә бу каһәр оясына үзе килеп эләкте. Ичмаса монда китермәгән булсалар, ичмаса Мусаны үзе күрмәгән булса, никадәр җиңел булыр иде аңа! Әмма юк шул, бәхетсезлеккә каршы, күрде һәм күрүе белән үк, хәтта аның аяк атлавыннан ук хыянәтче икәнен һәм бу ишәкнең койрык очын ялап көн итүен аңлап алды. Шулай булгач, аңа нинди ялган турында сорашып тору кирәк? Сатлык җанга барыбер түгелмени? Мирхәт үзенең саф теле белән ул бәндәгә аңлатмалар биреп, вакыт әрәм итсенме? Шулай да тагын бер-ике утлы сөнге белән йөрәгенә кадарга кирәк әле. Ул, җиңүче кыяфәте белән сул күкрәген алгарак чыгарып, төз басты да:

— Мин Иуда түгел, туганнарымны сатмыйм, ялган белән дә сату итмим, ул бит менә синең кебек вак хыянәтчеләр һәм моның кебек карт ишәкләр эше! — дип, мыскыллы тавыш белән көлеп куйды. — Үзем беләм. Синең сатлык булуыңны ишеткәч тә, үзем тикшердем!

— Әй, дуңгыз малае! — дип кычкырды Шәфи. — Чабата телеңне тыя белмәсәң, мин сине!..

— Курыкмыйм, гаспадин! — диде егет. — Теләсәң җәһәннәм тишегенә илтеп тык. Әмма монда кала алмыйм. Һава юк монда, сасы. Бөтенегездән сасы көзән исе, фашист йөзгән кан исе килә. Кеше ашаучылар сез! Мине фашистка көчләп солдат итәргә маташуың өчен ничә тиен бирәләр сиңа, бай хәерче!

Мирхәт хәзер юри усаллана иде. Монда калмас өчен ни генә күрсә дә риза иде ул, күрәсең. Һәм бу хәл Шәфинең тәмам җенен кузгатып җиткерде. Әле бер генә татар әсиренең дә бу кадәр кискен һәм ачы сүзләр белән каршылык күрсәткәне юк иде аңа.

— Тукта, дуңгыз!..

Ул, калтыранган куллары белән трубканы алып, гестапога шалтыратты.

Озак көттермәделәр. Автоматларын тотып, ике кара козгын килеп тә керде. Шәфи башын гына селкеде һәм тегеләр Мирхәтне уртага алдылар. Егет горурлыгын югалтмады, ишеккә барышлый, башын борды да:

— Менә, Муса әфәнде, сезнең кабахәт хыянәтнең тагын бер шаһите кимеде, куаныгыз! — дип кычкырды. — Нәфрәт сезгә! Ләгънәт!..

Аны төрткәли-төрткәли алып чыгып киттеләр. Ә Муса, чыннан да көчсез, чарасыз һәм кызганыч бер чыпчыктай, корыга тимтенеп, өзгәләнеп калды. Нинди алтын егет үзенең җүләр акылы белән үз башына җитте... «Бу минем кодам, бу һәйбәт егет, тимәгез!» — дип каршы төшеп тә, сугыш ачып та булмый бит, булмый!..

Ул, сөяге сөяккә, ите иткә аерып ташлангандай таркау гәүдәсен көч-хәл белән сөйрәп, үз бүлмәсенә чыкты да диванга ауды һәм дөнья, каядыр ашкынып чапкан поезд тәрәзәсеннән күренгән шикелле, күз алдыннан тиз-тиз генә чагылып узды да кинәт өзелеп бөтенләй югалып калды...

## V

Ул күпме шулай яткандыр, ансын һичкем белми, тик аның бүлмәсенә кичке якта беренче булып Гариф Шабаев килеп кергән дә, Муса йоклый икән, дип уйлаган. Әмма кул-аякларының бөтенләй таралып ятуы, авызы ачык булса да тын алганы ишетелмәве аны өркетеп җибәргән. Ашык-пошык эзләгәндә тамыр тибешен дә табалмый аптыраган ул. Кинәт куркуга төшеп, Шәфи кабинетына йөгереп кергән дә: «Муса үлә!» — дип кычкырган.

— Хи-хай! — дигән Шәфи. — Нәрсә булган? Әллә теге малай сүзләре бәреп екканмы?..

Шулай да, Гариф бик үтенгәч, врач чакырткан. Килгән врач авыруны кимендә бер тәүлек кузгатмаска кушкан, йөрәк пристубы дигән. Кризис узганнан соң саклык белән генә ятакка күчерү мөмкинлеген белдергән. Кич һәм төне буе Гариф, Фоат, Алиш өчәүләшеп кизү торганнан соң иртәгесен Мусаны үз ятагына китереп салганнар. Шунда гына Муса күзен ачты...

Ә күзен ачкач, каршында басып торган өч дусын күрде ул. Өчесенең дә йөзе борчулы, кәефләре боек иде. Иң элек Шабаев үзенең озын буе, ягымлы күзләре белән аның баш очына иелде.

— Куркыттың, кордаш, һай куркыттың, — дип елмайды ул сөенечен яшерә алмыйча. — Бөтенләй пошаманга төшердең бит! Шаяртма әле син алай...

Алиш белән Фоатның да куанычтан авызлары ерылган иде. Муса да үзенең якын дуслары алдында тере һәм нык рухлы булып күренергә тырышты, элеккечә гамьсез көләргә теләде, ләкин барып чыкмады. Патефон пластинкасындагы инәнең читкә сикереп, ялгыш авазлар чыгаруы шикелле генә булды ул.

— Ярый, без сине борчымыйк, — диде Алиш, — сиңа хәзер тынычлык кирәк. Ял ит.

— Ә кичкә тагын килербез, — диде Фоат. Һәм алар китеп бардылар.

Муса ялгыз калгач кына үз-үзен барлый башлады: чигәләреннән тимер кыршау белән кыскандай булып башы авырта, үзе туктаусыз чыңлый икән! Ә колак эчләрендә меңләгән чикерткә «чалгы кайрый». Әйтерсең, ул баш ямщик дугасына тартылган олы бер кыңгырау! Йөрәгенең итен умырып алырдай итеп нәрсәдер өзлексез талап тора, күңеленең ниндидер бик кирәкле бер кылы өзелгән һәм дөньясының бик кадерле бер почмагы җимерелеп төшкән, шулар өчен җаны өзлексез сыкранып, боектырып тора иде. Күз алды ниндидер соры томан. Сөяк һәм буыннарның кыймылдар хәлләре дә юк. Йөрәкне талый торган нәрсәнең, кысланыкы кебек, чуен җепләре бардыр, ахры: күкрәгеп тырнап югары күтәрелә дә шул җепләре белән богызлавын кыса, сулышын бумакчы була. Әле мондый авыруны Мусаның бер генә тапкыр да кичергәне юк иде. Йөрәк чыгымчылавы дигән нәрсә энә нинди икән ул!

Кинәт теге өзелгән кыл Мусаның бәгырен тырный башлады. Калганнары да өзелердәй булып күңеле нечкәрде. Үксеп-үксеп елыйсы килде, күз төпләре кызды, әмма инә күзедәй яшь тамчысы да чыкмады. «Балакаем, ялгыз карлыгачым, кан бөртегем... — дип өзгәләнергә тотынды ул. — Син шулай итеп кеше кулларында ике канатсыз ятим булып калдыңмыни соң? Әниең дә юкмыни инде?.. Минем аркада шундый авыр газаплар чигәсезмени сез?.. Әминәкәй! Хәдичәкәй! Зәйнәп акыллым! Кичерегез мине, бер гөнаһым да юк сезнең алда!..»

Аннары, горур лачындай басып торучы Мирхәт күз алдына килде аның. Каян уйлап чыгарган ул шундый тузга язмаган ялаларны? Хәер, Мирхәт үзе уйлап чыгармас, ул андый мәкерле малай түгел. Күрәсең, нәрсә дә булса бар. Күрәсең, агулы җилләр агулы хәбәр тараткан анда... Чынлап та, аларны дошман саныйлар микәнни соң? Саныйлар инде, күрәсең. Юкса, Мирхәт алай һөҗүм итмәс иде, Муса җизнә тиешле дә кеше бит әле аңа, үз якыны. Хәер, үз якыны хаин булуына икеләтә әрнеп, икеләтә хурланып һөҗүм иткәндер ул. Әйе, очрашу форсатыннан оста файдаланды егет, дөрес эшләде. Аның урынында Муса да шулай итәр иде. Хыянәтчене атып үтер, ата алмасаң, буып үтер, буа алмасаң, телең белән үтер. Ул да мөмкин булмаса, йөзенә төкер!..

Муса уң битен мендәренә ышкып куйды. Ярый әле тимәде. Юкса, гомер буена битендә янып торыр иде. Хыянәтче булмаса да, оныта алмас иде аны Муса! Үз гомерендә берәү дә аның битенә төкергәне юк һәм андый ихтималның булуы да мөмкин түгел, чөнки кешеләрне шул дәрәҗәдә каты рәнҗетерлек бер генә начарлык та эшләгәне юк аның... Моңарчы юк иде дә бит, ә менә хәзер бар дип уйлыйлар икән. Йөзенә дә төкерделәр... Шагыйрь йөзенә... Күктәге йолдызлар сафлыгын күңелендә саклап йөрткән шагыйрь йөзенә! Ә йөзеңә төкерсәләр — син нинди шагыйрь инде?.. Мөкатдәс җиренең бер уч туфрагын тизрәк кайтып үбүне һәм дошман утларын кичкәндә юлында егылса, шул изге туфракны күкрәк ярасына басып үлүне үзе өчен иң бөек бәхет санаган бер татар җырчысын хаин ясаганнар! Кемнәр икән ул, нинди кешеләр икән? Нинди дәлилләр бар икән алар кулында?.. Илгә чыгып киткән батальон кешеләренең ичмаса берәрсе, Мәскәү яки Казанга житеп, алар хакында бер генә авыз сүз дә әйтмәс микәнни? Арыслан кая икән соң, минем җан дустым Арыслан! Ичмаса, Бакшанов җибәргән кешеләр дә әйләнеп кайтмады, хәбәр дә килмәде. Күрәсең, бикерактыр, бик кыендыр, бик әйләнечтер туган җиргә житү юллары!.. Ул, очар коштай, шул юлларга омтыла, ә аны анда хаин диләр икән...

Кинәт Чулпан белән Әминәнең, Хәдичә белән Зәйнәпнең, бөтен туганнары, таныш-белеш, дус-иштәренең, татар язучыларының һәм хәтта бөтен дөньяның шикле карашы аның йөзенә текәлгән шикелле, җавап сорый шикелле булып күренде... «Юк, туганнарым, мин хаин түгел! Ялган андый сүзләр, ялган! Күтәрә алмаслык яла, коточкыч яла!..» дип кайнар пышылдый-пышылдый, ихтыярсыздан акланырга тотынды ул.

Булмаган гөнаһ өчен бу аклану тагын да авыррак иде. Аның йөрәге тагын хәлсезләнде, тамырларында кан бөялеп калган төсле булды...

Мусаның көннәре, төннәре шундый уй җәһәннәме эчендә алҗып узды. Тәүлекләр буена йоклый алмады, башы чатнау һәм чыңлаудан туктамады, тамагына ашауны онытты, эчендәге ниндидер яна торган җирен сүндерергә теләгәндәй, су эчте. Йөрәге һаман калтыранып, таланып торганга, җегәре кайтмады, йөзе саргаеп, кибеп калды.

Үлсә дә барыбер шикелле тоела башлады аңа. Чөнки үкенерлек һичнәрсә калмады... Нәрсә калсын соң? Күкрәк сөтен имезеп үстергән анан төсле туган илең дә сине хыянәтче итеп санагач, бу аяусыз дөньяда мөкатдәс булган нәрсә калсын?..

Иптәшләре, аның хәле чамадан тыш начар һәм куркыныч булуын күреп, Шәфи Алмаз каршына гозер белән керделәр һәм, күп ялына торгач, ун көнгә Узедомга озата алдылар.

## VI

Балтик дулкыннары, сөзәк кенә уймалы-бормалы ярларга сыек-сары алтын комнар түши-түши, ялкау гына тәгәрәшеп йөриләр. Шундый дулкыннар ясаган бәләкәй генә, матур гына ярым атауларның берсендә җәйчә, җиңелчә генә салынган берничә вилла бар. Аларны «Узедом ял йорты» дип йөртәләр. Ул «Идел-Урал» комитеты карамагына бирелгән. Анда президент әфәндене миллли хадимнәре, хезмәтендә яхшы үрнәк күрсәткән легион командирлары, хәтта шундыйрак солдатлары да ял итүе мөмкин. Шуның өстенә әлеге комитетка баглы немец әфәнделәр дә, теләсә кайвакытта гаиләләре белән монда килеп, бик рәхәтләнеп ял итеп китәләр...

Һаман шул эчтән яну, эчтән өзгәләнү белән изаланып, тышкы дөньядан бөтенләй бизгән кешенекедәй канатлары сынып төшкән Мусаны монда китергәч тә, атна буе үзгәреш кермәде. Ул, биш көн һичкая күзгалмыйча, шул меланхолик хәлендә калды, табигать гашыйгы булуын да исеннән чыгаргандай, дөньяга күз да салмыйча, урынында ятты. Ниндидер ярым омтылыш хәлендәге саташулар, каядыр ашыгулар, кемгәдер яшерен пышылдаулар, кемнеңдер усал һөҗүменнән , сакланулар интектереп бетерде аны. Ниһаять, алтынчы иртәдә күзләрен ачып, үзенең кайда ятканын абайларга тырышты: нинди бүлмә соң бу?.. Маңгаен җыерып озак уйланганнан соң — исенә төште: ә, әйе, Узедомга дигәннәр иде бугай...

Кинәт аның бөтен тәненә көйдергеч ток йөгергәндәй булды: туктале, нишләп ята ул монда?.. Аңа бит легионга ашыгу кирәк, поляк карты янына... Урман кошларының эзен табарга... Җәй. Урман кочагы. Солдатларны тизрәк шунда алып китәсе иде бит ул! Юк, моннан тизрәк качу кирәк, бүген үк!.. Көтәләр бит аны, көтәләр!.. Ни җаның белән түзеп ятмак кирәк монда?

Хәтта шул минутта ук сикереп торырга теләде ул. Ниндидер житез хәрәкәтләр белән койкасына утырды, аягүрә төшеп басты, әмма шул авыкта... аның күз алдында янә Мирхәт пәйда булды. Үзенең бөтен дәһшәтле тавышы белән:

— Хыянәтче син! Чулпаның, Эминәң кан-яшь түгә!.. — дип кычкыра иде ул. Мусаның яшен суккандай сыгылып төшкән җансыз гәүдәсе яңадан койкага ауды. Әле генә кабынган якты ялкын кинәт сүнеп, аның бөтен аң дөньясында олы бер уйсызлык, тубалдай олы бушлык хасил булды. Сәгатьләр буена сузылган шул олы бушлык аның кайда ятуын гына түгел, хәтта дөньяда яшәвен дә оныттырган кебек тоелды. Тик телендә, акыл ирекеннән тыш, ниндидер мәгънәсез сүз өзекләре генә кабатлана иде: бетте хәзер барыбер... Кем ышансын барыбер... Яңгыры бер — кары бер... Карасы бер — агы бер... Ачысы бер — балы бер... Ба-

рыбер... Шул гамьсез ритмик тезмәләр аның колак төбендә тукмак суккандай биеп торалар. Бу аяусыз тукмаклар аның рухын гына түгел, хәтта тәнен дә тукмаклап үтерәләр кебек.

Әмма кеше алай гына үлми икән. Һәм бар дөньясыннан йөз чөереп, җирдәге тумрандай хәрәкәтсез генә ята да алмый икән. Муса да, шушы авыр кризисны бик авыр кичергәннән соң, әкренләп урыныннан кузгала, тәрәзәгә килә, тыштагы агач яфракларының селкенүе белән әз генә булса да кызыксына башлады. Сигезенче көнне Муса һавага чыгып, яр буена таба атлады. Аны гына көткәндәй йөгерешеп, куанычлы эһәң белән куыша-куыша каршына килгән дулкыннар, кояш нурында уйнаган көмеш яллары белән күзләрен камаштырып, аны яңадан гашыйк иттеләр. Соргылт-зәңгәр сулы бу Төньяк диңгезенең кырыс көләчлеге аның йөзенә дә килеп ятты һәм Муса күп көннәрдән бирле беренче тапкыр сүлпән генә көлемсерәп куйды. Тез буыннарының, йөрәгенең һәм бөтен гәүдәсенең әле һаман җегәре юк иде. Яр буендагы терәкле яшел эскәмиягә утырды да шаян дулкыннарның тәгәрәп уйнауларына карап онытылды. Балтик өстеннән искән әкрен җил белән нинди дер йод исе катыш тозлы һәм диңгез йоннары аралашкан һава килеп, үзенең татлы җиңеллеге, сәрхуш иткеч рәхәтлеге белән аны йокымсыратып җибәрде. Бөтен тәнен рәхәт бер оюю сарды. Күпме тәүлекләрдән бирле йокы күрмәгән Муса тиз генә бүлмәсенә юнәлде: изрәп бер йокларга теләгән иде ул, ләкин, кереп урынына чуму белән, йокы дигәне тагын качты: күз кабакларына яңадан шырпы терәткәндәй булды...

Әдәм баласы ни өчен яши җирдә?.. Мәңгелек сөаль... Ә шулай да — ни өчен? Хыянәтче! — дигән исем күтәрер өченме?! Кая синең туган илең, Чулпаның, Әминәң моннан сең? Кая синең йөрәгеңнән сыгып алган җырларың? Хәтта монда да, дошманнан кача-поса язып, яшереп, саклап йөрткән булдың — кем өчен? Кемгә кирәк алар? Кем басып чыгарсын аларны? Ә йөрәк каның белән язылган шул җырларың дөнья күрмәгәч, яшәүнең нинди мәгънәсе бар?!

Береннән-бере аяусыз булган мондый сораулар Мусаның бәгырен кисүдән һаман туктамыйлар. Ә төн килсә, хәрефләре нинди дер куркыныч ут белән язылган «хәянәтче!» дигән сүз, кинәт өстенә ыргылып, гөлт! итеп кабыныр да, Мусаны бер секундта яндырып көл итәр кебек тоела...

Бу каһәрле төннең әшәке саташуларын көч-хәл белән уздырып, иртәнге яктыга күзләрен ачканда: «Юк, ышанма!.. Син ышанма Әминәкәй! Син ышанма, Чулпан!..» — дип пышылдый иде ул. Көндез үзен тагын диңгез ярына чыгарга мәҗбүр итеп, җылы ком өстендә аксыл-зәңгәр күккә карап яткан килеш тагын шул ук уйларын кабатлады: «Син ышанма, бәгырем... хәбәр китерсәләр... Хыянәтче булган дисәләр... Һай юк, юк, юк! Ул сүзне хәтта телгә алуы да әҗәл!..»

Ерак күк йөзе аеруча матурланып, күзне кисми торган йомшак зәңгәр төскә төренгәндәй булды. Әллә нинди тылсымлы яктылар уйнап күңелен кузгатып җибәрде, нинди дер җиңеллек иңгәндәй тоелды. Нәрсә бу? Әллә, чыннан да, күкнең сихри серле яшерен капусы булып, шул ачылдымы? Юк бу илаһи матурлык — кешенең үз эченнән күккә күтәрелүче илһам көче иде. Ничәмә көн һәм төннәр буена интектергән эчке газапларның, әрнү һәм өзгәләнүләрнең, йөрәк һәм тән талануларның беренче авазы булып яңгырыйсы шигырьнең беренче юллары туа башлавы иде бу. Муса түшенә әйләнеп ятты да бер коры чыбык очы белән ком өстенә нинди дер бизәкләр чигәргә тотынды. Әгәр аның артында икенче бер кеше басып торса, ул, һичшиксез, бу чигешләрдән мондый сүзләрне укыр иде.

Синә миннән хәбәр китерсәләр,
«Алмаштырган илен» дисәләр,
Син ышанма, бәгырем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, мине сөйсәләр...

Моңарчы аны авырлыгы белән басып һәм изеп килгән бушлык каядыр чигенгәндәй булды. Колак төбендә өзлексез чеңләгән миллион чикерткәләр дә үлән төпләренә качтылар шикелле. Дөнья тынып калды һәм ниндидер якты хисләр, язгы гөрләвектәй уйлар агыла башлавы сизелде. Мусага кәгазь һәм каләм кирәк булды. Ул бүлмәсенә йөгерде, өстәл тартмасыннан очраклы бер кәгазь кисәге табып, ач кеше кабалана-кабалана ашка ташлангандай, язарга тотынды:

Байрагыма каным белән язган
Антым чакыра алга барырга,
Хакым бармы минем абынырга,
Хакым бармы арып калырга?..

Әмма бу газаплы ләззәт эчендә озак онытылу аңа насыйп булмады. Бары тик шигырь күбәләкләре генә очып йөргән тын һәм җыйнак бүлмәнең ишеген кинәт киереп ачып җибәрделәр. Бусагада курортча олы чәчәкле чуар киемнәрдән Мага ханым белән аның кияүгә Шәфи Алмаз күренде. Алар артында җирән Унгляубе һәм элеп киптергән профессор Менде белән фрауләры басып тора иде. Болар гына да түгел, акварель белән ясап куйгандай сыек зәңгәр күзле, арыш саламы чәчле фрейлейн Матильда да, үтүкләгән керфекләрен түбән сирпеп, чак кына елмая иде әле анда. Һай, кирәкле кишер яфраклары! Һәммәсе дә борчылу күрсәтеп, кәҗүнни йомшаклык белән генә Мусаның хәлен сораштылар, тизрәк савыгу теләделәр һәм үзләренең монда президент сайлау өчен референдум уздыру шикелле мөһим эш белән килүләрен, Мусаның да бик кирәк булачагын әйттеләр. Ярый әле, озак тормадылар. Шулай да Мусаның бүлмәсе яман тынчуланып калгандай булды. Ул, алар чыгып киткәч, ишеген әлде дә, диңгезгә караган тәрәзәсен киң итеп ачып җибәрде. Диңгезнең сагышлы да, кодрәтле дә тирән сулышы ишетелде. Муса яңадан эшкә утырды. Ләкин әле генә хөкем сөргән рәхәт тынычлыгы, кул белән бәреп төшергән фарфор уенчыктай челпәрәмә килде, әле генә сабыйларча кеткелдәшеп агылган якты гөрләвекләр дә, баш очында уйнаган матур ак күбәләкләр дә кинәт кенә юкка чыктылар. Ул яңадан ыңгырашып урынына капланды...

Иртәгесен Узедомда атлаган саен яңа кешеләр күренә башлады. Легионның Польша белән Германиядәге бүлекчәләреннән генә түгел, хәтта Бельгия, Голландия шикелле ерак җирләрдән дә гаскәри вәкилләр бар иде монда. Муса үзенең күп кенә таныш командирларын, пропагандистларын һәм врачларын очратты алар арасында. Кичкә таба легионнан тулы составы белән музыкаль капелла, артистлар труппасы һәм пропагандистлар взводы килеп төште. Шәфи Алмаз нәрсәдер маташтырмакчы була, күрәсең. Әйдә, кылана бирсен, әмма Мусага үзенең дуслары белән күтмәгәндә күрешү зур куаныч китерде. Бик сагынган икән үзләрен! Кормашнымы, Рушатовнымы — кайсын гына кочакласа да үз иде, якын иде. Алар да сагынышканнар икән, диңгез комында Мусаны түгәрәк эченә алып яттылар да пешкәкли башладылар: «Кая югалдың син? Нәрсә булды сиңа? Ник тизрәк килмисең? Бу нинди курорт? Ник кызган тимерне суытабыз? Урман чакыра, туган ил кулын суза — ә без?..»

Муса тирләп чыкты. Үзенең бөтен фаҗигасен әйтеп бирә алмавына үкенде. Әмма шулай да рәхәт булып китте аңа. Җилкәсен басып торган авыр таш өемнәре җимерелеп төшкәндәй тоелды, үзендә җиңеллек сизә башлавын аңлады ул. Төшке аштан соң ялга яту белән, бу хәле аның алдына яңа сорау куйды: нишләргә соң, нишләргә?! Элек шул хәтле дәрт белән янып-көеп алып барган эшеңне хәзер дә дәвам итүнең мәгънәсе бармы?.. Эшләгән эшең ап-ачык ярылып ятса да — сиңа ышанмасалар? Сине барыбер хыянәтче санасалар?.. Хыянәтче... Хатының, балаң, туганнарың...

Мусаның, муенына тыгыз бау кидергән кебек, тагын тыны кысылды. Мендәрдә яткан башына урын тапмагандай, әле бер якка, әле икенче якка ташланды. Ахыр түземен җуеп, торып утырды. Тәрәзә каршына килеп, аны ачып җибәрде. Шунда ук аның тар бүлмәсенә диңгез шавы, дулкыннар җыры тулды. Акчарлак канатлары да җитмәс ерак киңлекләрдән ниндидер мәһабәт көчләр килеп кергән шикелле булды. Аның күңеле әллә кайларга китеп барды. О, иректә стихия! Сиңа кемнәр генә сокланмаган да, кемнәр генә гашыйк түгел! Лорд Байрон да үзенең бунтарь йөрәге белән гомере буе сине җырлаган. Ак төннәр каласы Петербургта туган гарәп орлыгы Александр Пушкин да, Кырым кыяларыннан карый-карый, сиңа гашыйк булган. Ул бөек затларның чикләнмәс хисләренә синең иксез-чиксез киңлекләрең, ихтимал, бик тәңгәл килгәндер. Әмма гади кешеләр дә синең гүзәл мәһабәтлегенә табына беләләр. Менә, татарның тыйнак бер шагыйре, бәләкәй генә Муса да синең каршында басып тора, ул да сиңа гашыйк. Ул да синең мәңге туктамас җырларыңа, чиге булмаган еракларга, ирекә чакыруыңа канатлы коштай ияреп очарга тора! Аның да ирек сөя торган тынгысыз йөрәге бар. Ә хәзер ул йөрәкнең бәләкәй иясенә шундый авыр, шундый кыен, ул үзен кая куярга, кайсы кыя башыннан кай чоңгылга ыргытырга белми... Аны хыянәтче дип атаганнар, илен саткан кеше дип. Шул мәһабәт диңгезләрен, шул матур урман-кырларын дошман кулына биргән бәндә дип йөртәләр икән... Моңа ничек түзмәк кирәк? О, ирекле стихия, моңа ничек түзмәк кирәк?! Көмеш тузанындай вак кына тамчылары җилләр белән битләренә килеп бәрелсә, Чулпанының күз яшьләредер кебек тоела. Синең мәңге тынмас сулышың ярларга килеп сугылганда, Әминәсенең һәм кыз туганнарының аһ-зары булып ишетелә. Авыр! Бер генә почмакта да инә күзедәй якты бер нокта күренмәгән таш караңгылык баскан кебек, авыр аңа. О, ирекле стихия, моңа ничек түзмәк кирәк? Киңәш бир син аңа, киңәш бир!

Ул шулай озак басып торды. Диңгез һаман сагышлы да, көчле дә итеп сулавыннан туктамады, шаян дулкыннар һаман уйный-уйный йөгерешеп ярларга килделәр дә, озын ак ефәк итәкләрен ком өстенә сузып, кире чигенделәр. Көлештеләр, чупылдаштылар, үбештеләр. Ниһаять, мең колачлы стихия үзенең иң куәтле бер дулкынын сөзәк ком өстенә, Мусага таба якын ук тәгәрәтеп китерде дә телгә килгәндәй булды:

— Чык дөньяга! — дип кычкырды шикелле ул. — Ияр дулкыннарга! Әнә шул ак ялларына ябышып чап! Юлыңны дәвам ит!.. Диңгезне, океанны боз каплый алмый! Нинди генә кургаш болытлар, калын томаннар күкне сармасын — кояш барыбер чыгып, диңгезгә карый!.. Алтын тутыкмый!.. Йөрәкнең чын ялкынын һичбер боз суы сүндерә алмый!..

Муса сискәнеп куйды. Каян килә бу? Әллә үз уйларына шулай тавыш кермә соң?.. Чыннан да, тукталып калу мөмкинме? Гел аның үз язмышы киләчәктә шуның фаҗига белән, шундый кара тамга белән чикләнсен, гел ул әллә нинди җәзалар да күрсен, әмма ничәмә мең кешенең язмышы бар бит әле! Алар шушында дошман коралы булып калсынмы? Алар да шул «хыянәтче» дигән кара исемгә дучар булсынмы?.. Юк, мөмкин түгел!.. «Тугры эш туксан елдан соң да югалмас!» дигән мәкаль булырга тиеш халык телендә!..

Каршындагы мәһабәт стихия белән бергә кушылган күңел түреннән шундый җавап килде Мусага. Ул, иңбашларын киереп, тирән һәм рәхәт бер сулыш алды. Аңа хәзер дусларының йөзенә туры карау баягыча кыен булмаячак иде. Аның хәзер йөрәге дә, рухы да яңадан сәвыгып җитте шикелле, ул хәзер иртәгесен үк солдат янына китәргә тиеш!..

## VIII

Референдум буласы көнне Познаньнан Һадиев белән Акъегетов та килде. Һадиев, иң беренче эше итеп, Шәфи Алмазны күрергә ашыкты һәм үзенең бик кыен хәлдә калуын әйтте.

— Нинди кыен хәл тагы? — дип гаҗәпләнде Шәфи.

— Сезне яклап тавыш бирүе кыен, — диде Һадиев, аяк өстендә таптанып.

— Алайса син каршы?

— Юк, каршы да түгел түгелен... Сез яхшы кеше... Ләкин уңайсыз бит... Гаеп итәрләр... Кайчандыр фирка кешесе булган Һадиев Шәфине яклый, дип уйлар Муса... Бу бик куркыныч хәл...

Шәфи кычкырып көлеп җибәрде. Шомарган табанлы чана шикелле як-якка салулый-салулый көлде.

— И, куян, куркак куян, чулак куян! — дип такмаклады ул.— Ә беләсеңме нәрсә?.. — Шәфи берничә секундка тукталып калды: «Тукта, аяктан егыйм әле бу тинтәкне!» — дип уйлады ул. Һәм бик мөһим тавыш белән әйтеп салды: — Беләсең килсә, Муса әфәнде үзе дә миңа тавыш бирә! Һәм ачыктан-ачык!..

— Кит аннан! — дип кычкырды Һадиев һәм, чынлап та, төсләре агарынып, баскан җирендә чайкалып китте. — Ышануы кыен. Берәр хәйләсе бардыр... Шулай да мин... рөхсәт итсәгез... репутация бит...

— Үләт син! — дип мыскыл итте аны Шәфи. — Белмисең Муса әфәндене! Ярар, бар, ычкын! Синең тавыш кына мине батырмас та, калкытмас та! — Һәм сулагай кулын ишеккә таба селтәде...

Берлинда калган комитет хадимнәре белән редакция кешеләре дә килеп төште. Муса бүлмәсенә, шау-гөр көлешеп, Абдулла Алиш, Гариф Шабаев, Фоат Булатов һәм Әхмәт Симай килеп керде. Муса аларны кул чәбәкләп каршы алды. Кочак җәеп сагынулы күрешүләр, шаян сүзләр китте.

— Абау, егетләр, сез, ахры, бөтен оягыз белән купкансыз, бөтен тавык-чебешләрегез белән! — диде Муса. — Әллә Берлинга десант төшерделәрме?

— Озакламый ул көн дә житәр, алла бирсә! — диде Әхмәт Симай,— ходайдан көн-төн сорыйбыз, тик аның карт җәбраиле Черчилль хәзрәтләре генә ашыкмый.

— Фәрештәләре парашут ямый, имеш,— дип өстәде Фоат, житди төс белән. — Житми ди. Шул ямау беткәч тә, десант төшәчәк, ди.

— Черчилль ашыкмас ул, — дип кул селтәде Гариф. — «Чау-чау» эте шикелле, мамык мендәр өстендә генә премьерлык итә ул...

— Я, Әхмәт дус, синең хәлләр ничек соң, исән-сау терелдеңме? — дип сорады Муса.

— Шөкер. Ярый берчәк.— Әхмәтнең йөзе артык ачылмады.— Үзегез ничек?

Муса дингез җилләрен мактады. Бүлмәсендә йоклый алмый интексә, дингез ярына чыгып, йөзен җилгә каршы куеп утыруын һәм, уңмаган балыкчы шикелле, тиз арада израп китүен сөйләп көлдерде. Аннары житди сүзгә тотындылар. Бүген референдум буласы барына да мәгълүм иде. Егетләр нинди позиция тоту мәсьәләсен үзләре үк күтәрделәр. Ә Муса туп-туры җавап бирде:

— Шәфине яклап тавыш бирәбез, егетләр.

Бу сүз иң элек Симайны бәреп екты:

— Атакаем, ах! — дип кычкырды ул, күкрәген тотып.

— Шул аракы мичкәсенме?

— Шул апсатар маклерныммы?

— Шул әрекмән колаклы ишәкнеме? — дип, башкалар да шаккатты.

— Әйе, дусларым, — диде Муса көлемсерәп. — Нәкъ шул шәп сыйфатлары өчен!

Егетләр аптырашта калдылар. Барысының да сораулы карашы Мусага төбәлгән иде.

— Ничегрәк аңлатырга икән сезгә?.. Шулай да үзегез уйлап карагыз әле, — диде ул.

Иптәшләре тагын тын калдылар. Алар барсы да Шәфигә каршы һәм Мусаның да шул фикердә икәнен беләләр иде. Шулай булгач, җае килгәндә ул ахмакны очырырга кирәк лабаса! Ә шуннан соң?.. Димәк, Гаяз Исхакыйны куярга? Юк, ул да ярый торган бәндә түгел. Ә соң кемне?.. Алай булгач, Мусаны? Алишны? Фоатны яки Гариф Шабаевны? Ә ничек итеп коммунистлар немец куйган президент була ала?.. Яхшы, Муса булды ди. Ә нишли ул анда? Нәрсә ул комитет? Нәрсә ул «президент»? Фикция түгелме соң алар?.. Курчак уены?..

Беренче булып Алиш сүз ачты.

— Акбай белән Сарбай проблемасы икән бу, бер уйласаң, — диде ул. — Ике чабата — бер кием, икесенә — бер тиен.

Әмма егетләрнең бик тиз килешәсе килмәде. Шәфине яклап тавыш бирү дигән сүз үзе генә дә коточкыч әшәке яңгырый иде. Ничек кулың күтәрелсен шул пычрак эшкә? Әхмәт Симаев аеруча нык каршы торды. Ул Шәфинең гырылдавыгын тартып өзәргә кирәклекне әйтте, хәтта Мусадан шикләнә башлавын белдерде. Монда озак ятып, сыйнфый сизгерлеге томалана башламаганмы, янәсе.

— Алай булса, әйтегез әле, егетләр, — диде Муса, кыза төшеп. — Сез шул «Идел-Урал» штатларының хәзерге Татарстан һәм Башкортстан җирләренә, гомумән, Идел буена барып утыруына ышанасызмы, юкмы?

Иптәшләренең хәтере калды. Бигрәк малайсыта инде. Ләкин эчләренә йоттылар. Авыру кеше бит...

— Юк, әлбәттә! — диде Фоат, — андый хәлгә төшмәдек әле.

— Андый хәлгә төшсәк, бик аяныч булыр идек,— дип өстәде Шабаев.— Егыл да үл аннары.

— Мин дә ышанмыйм, — диде Муса, яңадан көлемсерәп. — Дөрес, моннан ярты ел элек куркынырга да урын бар иде. Әмма хәзер инде немецның яңадан Иделгә әйләнеп чыгуы, Татарстан җиренә таба атлавы — тузга язмаган әкият кенә. Уйдан сызылган ул хәл! Димәкки, ул җирләрдә әлеге «штатлар»ның булуы да мөмкин түгел. Ә инде немец кәгазендә яшисе «мәмләкәт»нең агач президенты кем булса да — барыбер түгелмени? Ләкин Шәфи безнең өчен зыянсызрак. Чөнки сукыррак ул. Безнең эш майлаган күк тәгәрәсен өчен түрәнең нәкъ әнә шундый күзле букәне кирәк. Алай да әле бу эш ныклы маскировка сорый. Ә Гаяз Исхакый — әдип кенә түгел, минем аңлавымча, бик озын сәяси фахишә дә ул. Теләсә кайда борынын тыга башлар... Аңлаштыкмы, дуслар?

— Аңлаштык, аңлаштык, — диде Алиш көлеп. — Мәсьәлә ачык.

— Ә мәсьәлә ачык булса, хәзер үк үзебезнең егетләр арасына таралыгыз да Шәфине якларга кушыгыз. Аңлатыгыз, аңа тавыш бирсеннәр.

— Стало быть, Шәфи агентлары белән бер үк позициядә агитлыйбыз? — диде Симаев, әле һаман риза булып бетмичә. Ничек соң бу большевиклар Думада патшаны яклап чыкмадылар икән? Алар өчен маскировка тагын да ныграк кирәк булган бит...

— О-о, — дип куйды Муса, — ерактан каерасың! Әмма пәри башка, җен башка, дустым. Россия Думасындагы большевиклар үз илләрендә көрәш алып барганнар. Ә без — чит илдә, фәкать үз әсирләребез арасында гына! Хәер, юкка бәхәсләшмик, Әхмәт дус, аңлаштык бит инде...

Егетләр чыгып киттеләр. Һәр кайсы үзенең таныш-белешләренә юнәлде. Тик Симай гына ашыкмады. Ул диңгез ярына таба атлады, ялгыз уйланып йөрде. Болар һәммәсе дә вак нәрсә булып күренде аңа. Чын

мәгънәсендәге олы һәм куркынычлы эшләр белән мәшгуль булмавына пошынды ул. Колач җәярлек, десантчы йөрәге канәгатьләнерлек эш юк! Дөресен генә әйткәндә, Гитлерны үтерү планы аның башында әле һаман уйнаклап йөри иде. Менә ичмаса эш! Кызыклы да, куркыныч та, масштаблы да. Бөтен дөнья шаулаячак. Саниянең эше дә үзенең куркынычлыгы белән матур һәм мавыктыргыч булып күренде аңа. Тик менә ахыры болай булып бетәсен генә уйлап җиткерә алмады шул. Хәер, уйлап җиткерсә дә, Санияне барыбер тотып калмаган булыр иде. Әхмәтнең чын күңелдән сөйгән кызы шундый бөек эшкә бара икән — бу бит искиткеч горурлык! Әхмәт моның өчен аңа үзе канат бирер иде! Һәм шулай итте дә. Ул аңа ак юл теләп, бәхет теләп, уңышлык һәм батырлык теләп озатып калды. Тик үзе генә ияреп бара алмады, чөнки завод цехына үтү ана мөмкин түгел иде. Эх, үзе дә шунда булса ул, батыр Саниясенә җил дә тидертмәс иде! Хыялларның биегенә, саф мәрмәренә генә баса торган ак бөркет, пакъ бөркет, яшь бөркет иде аның сөйгәне! Яз кояшыннан килгән ялкын иде ул, җәй болыннарыннан килгән ягымлы җылы иде ул, гөлләр бакчасыннан килгән сайрар былбыл иде ул! Сания үз юлын шундый зур һәм матур эш белән тәмамлады. Аның Әхмәткәенә дә шундый ук колач җәя торган, Саниясенә лаеклы була торган эш кирәк!..

## IX

Тавыш салу үзенчә бик «ирекле» эшләнде. Анда Шәфи дә, немецлар да катнашмады, тик Унгляубе әфәнде ачып кына җибәрде. Немецларның бик киң демократия яклы булуы турында бер кырык минут нотык сөйләгәч, ул да чыгып китте. Залда аның яңа әтүтәне Солтан дигән егет кенә калды. Бу әдәм кайчандыр Совет вузы бетергән, немецчаны бик яхшы белгән һәм үз тирәсен караңгы билгесезлек белән ураган бер шәхес иде. Дуслары да, ачык дошманы да юк кебек. Башта Шәфидә йөрсә, хәзер Унгляубе әтүтәне булып китте, аңа бик тырышып хезмәт итүен күрсәтте. Чөнки Шәфи урынына үзе утырасы килә, имеш, аның. Шушы кеше бюллетень биреп, исемлеккә билге ясап утырды. Кәгазьләр ак һәм зәңгәр төстә иде. Агы Шәфине яклый, зәңгәре — каршы килә. Һәркем шул ике кәгазьне ала да, алгы башка корылган плюш чаршау артына керә. Анда ике әрҗә. Әрҗәләр янына, сакчы булып, мылтыклы Хәнәфин баскан, тәртип саклый, янәсе. Әмма бу әдәм дә Шәфинең бик тырыш ялчысы булганга күрә, монда нәрсә өчен куелуы һәркемгә билгеле иде.

Бик күпләр, зәңгәреннән бөтенләй баш тартып, акны гына алалар да көлә-көлә әрҗәгә төшерәләр. Бер кырыйда, концерт залының зур тәрәзәсенә каршы басып, Рәфикъ Гыйльфан тора. Аның прожекторлы фотоаппараты муенына эленгән. Һәм ул үзенә кирәкле кадрларны «челт-челт» сугып кына бара. Муса белән Алиш та, Фоат белән Гариф та, өстәл янына дүртәве бергә килеп, ак бюллетень генә алдылар. Фоат гадәтенчә уен-көлке сүзгә бирелде.

— Мәңгәрләрнең йорты зәңгәр, ничек зәңгәрләгәннәр. Күпме кәгазь әрәм була, ничек җәлләмәгәннәр икән? — дигән булды. Алар, ак кәгазьләрен һәркемгә күрсәтергә теләгәндәй өстә тотып, әрҗәгә таба атладылар. Моны күреп торган Рәфикъ шаккатып, тетрәнеп китте һәм тиз генә аппаратын «гөлт» яндырып, челтләтеп алды. Аның белән генә канәгатьләнмичә, җәһәт кенә каршыларына чыкты да тагын бер «гөлт» иттерде.

— Менә бәхет, — диде Фоат, шул ук шаян тавыш белән, — мәңгелеккә дә кереп калдык! Безне хәзер тарих битләреннән чыра пычагы белән дә кырып ташлый алмыйлар инде!

— Иртән көлгән бала кичен илау сала, дигәннәр. Ашыкма, — диде Рәфикъ, — күп көлеп авызың кыйшаймасын!

— Кыек авыз — туры сүз, сукыр булса мескен күз... — дип, Фоат тагын нәрсәдер кыстырмакчы булган иде, тик Муса тып-тын гына аның

җиңеннән тартты. Һәм алар, кәгазьләрне әрҗәгә төшерделәр дә, залдан чыгып киттеләр. Алар артыннан ук Әхмәт Симай сикереп торды да «Барысы да күрсен!» дигәндәй, зәңгәр кәгазь алып өскә күтәрде дә чаршауга таба юнәлде. Рәфикъ аны да ике тапкыр төшереп алды. Әмма аның аппараты төсле фото бирә алмый иде. Тегеләрдән ничек аерырга соң моны? Ул шуның өчен борчылып куйды. Әхмәт чаршау артыннан чыккач, аппаратын аңа кидерде дә ничек турыларга һәм ничек челтләтергә өйрәтте. Аннары үзе дә, зәңгәр кәгазь алып, рәсемгә төште һәм әрҗәгә илтеп салды. Алар икәүләшеп чыгып киттеләр. Залда булганнарның кайберләре елмаеп калды. Карип тә, блокнотына нәрсәдер тøрткәләп, шунда утыра иде. Аның исе китте. Ничек инде бу? Симай гел тегеләр белән иде, аерылды микәнни? Рәфикъ белән яңа союз төзеде микәнни? Шәп бу, бик шәп. Араларына тагын да зуррак чөй сугарга, ә бу икесе белән бик нык дусланып алырга кирәк!..

«Президент сайлау» уены озакламый тәмам булды. Кичке сигездә концерт башланырга тиеш иде, халык шунда җыелгач, аның нәтиҗәсен дә игълан иттеләр. Бары тик ике генә тавыш каршы булып, калганнар бөтенесе дә Шәфине яклаганнар булып чыкты. Бу кыска утырышны тагын да Унгляубе әфәнде алып барды. Калган немецлар да, Шәфи үзе дә шунда иде. Ул үзенә беравыздан тавыш биргән кешеләргә бик күп рәхмәтләр укыды. Инде легион җәмәгатьчелеге болай олуглагач, карт булса да бирешмичә, барлык көчен сарыф итеп эшләячәген әйтте. Аның очлы кабаксыманрак башы, чыннан да, күккә тигән иде. Чөнки моңарчы әле ул немецлар билгеләгән бер шәхес кенә булса, хәзер инде солдат сайлап куйган президент! Легионның төрле бүлекчәләреннән килгән вәкилләр аны яклап тавыш бирделәр, бу инде бөтенләй икенче төрле кәттәфи! Монда хәзер аяк терәп сөйләшергә була! Шәфинең күңеле бик түгәрәк, дәртләре бик почмакланган иде бу минутта. Симай белән Рәфикъның каршы тавыш бирүен аңа җиткергән булсалар да, аларга да кырын караш ташламады. Һәркемгә, һәр тарафка дустанә елмаерга тырышты, концерт караганнан соң «милли чәй» булачагын әйтеп, һәркемне шунда чакырды.

Музыкаль капелланың репертуарында булган бөтен нәрсәләрне башкарырга һәм яңаларны да өстәргә кушылган иде. Концерт бай һәм катлаулы булып барды. Фәхри Димски үзенең хәтфә баритон тавышы белән «Кара урманны», «Иршат белән Гөлшат»ны һәм Муса язып биргән маршларны җырлады. Тыңлаучылар ташкындай алкышлар белән аны кат-кат чыгарып, тирләтеп, карлыктырып бетерә яздылар. Нигәдер әсәренгән яки гаҗәпләнгән кыяфәтле, көләч күзле, шактый озын муенлы бу егет һәммә кешедә дуслык тойгысы тудыра, үзен яраттыра иде. Ул кат-кат гафу үтенеп, озын муенын алга суза төшеп, бармагы белән бугаз төерен күрсәткәч кенә, тагын бер шаулашып көлделәр дә чакырудан туктадылар. Иң ахырдан Кылычбай чыкты. Аны да исертеп бетерделәр. Ул бүген башкортча яңа бер җыр башкарып, залдагыларны бөтенләй шаштырды. Кул чабу гына түгел, аяк дөбердәтеп, кабатлауны сорадылар. Бәләкәй генә Киекбаев үзенең бүрәнкә авызыннан чыккан олы бас тавыш белән тагын җырлап җибәрде:

Һай элмәклек, элмәклек,
Элмәле дә тундарзы
Бит без кимәнек.
Әллә яшьлек, әллә исәрлек,
Узган гомерзәрзе лә
Бит без һизмәнек.
Ат дагаһыз йөрәмәй,
Һуза көмеш эремәй.
Йәнием, мин йөгереп сыккан,
Нисек йәнең эремәй?

Аппак икән, йомшак икән
Әнием дән кулдары.
Салауат күпере кеүек
Һуга барган юлдары!..

Нәкъ шушы вакытта Муса бүлмәсендә оешманың киңәйтелгән утырышы бара иде. Монда, Берлиндагы биш кеше белән бергә, икенче батальоннан Харис Уразаев белән Бикмулла «хәзрәт» Җиһаншин, өченче батальоннан Кормаш белән Рушатов катнашалар, өстәлгә самавыр белән чәй китерелгән һәм кызыл эчемлекләр дә куелган иде.

Иң элек алар Әхмәт Симайны пешкәкләп алдылар. Аның Шәфигә каршы шундый «гайрәтле» чыгышыннан бик каты көлделәр, вак партизанчылык дип атадылар. Бу юлы Фоат тик кенә утырды, ләкин Гариф Шабаевның бик ачуы килгән иде.

— Малайлык бит бу, дустым,— диде ул, олыларча салмак тавыш белән.— Ник кеше көлдерергә? Син бер үзең тәрәзә ватып, башкаларны шаккатырмакчы булдың инде, янәсе. Ә нәтиҗәдә нәрсә? — Ике каршы! Сиңа алдан ук әйтелде бит: булмаган патшалыкның башында эт утырса да, бет утырса да барыбер диелде. Алайса син ул патшалыкның булуына ышанасың? Алайса син Идел-Урал буйларына немецләр килеп, Шәфине патша итеп куя, дип уйлыйсың? Алайса сине оешмадан шуытырга кирәк?..

— Уйламыйм, берсен дә уйламыйм,— диде Әхмәт, сикереп торып.— Нигә алайга борасың? Минем йөрәгем түзми, күңел ярсый. Менә шуңа чыдый алмыйча, каршы тавыш биргән булдым. Эш бирегез миңа, кыенрак эш!..

Барысы да Симайга үзенең ризасызлыгын белдерде. Муса да арага мондый башбаштаклык кертүне яратмады. Симайның үзенә тапшырылган эшне бәләкәйсенмичә эшләвен таләп итте.

— Озакламый рота командиры булырсың, менә шуңа колач җәярсең, — диде ул. — Шуңа хәзерлән! — Аннары Муса иптәшләренә карады.— Бу юлга Симай мәсьәләсенә шушында тыныш куймыйкмы?— дип сорады.— Ул аңлар безне...

Каршы килүче булмады. Симайның борчулы йөзе кинәт яктырып китте. Мөлдерәмә елтыраган күзләре белән бөтенесен бер әйләнеп чыкты.

— Канаткайларым! — дип куйды ул. Аның үзенә дә читен иде. Акыл кушканга гына сыя алмый шул аның холкы, ничек тә үзенчә кыланып ташлый. Соңыннан үкенергә туры килә, тик эш узган була. Бу юлы да шул дошманга нәфрәтен генә белдерергә теләде бит ул, яклаучы булып кулы күтәрелмәде. Әмма әнә нәрсә килеп чыкты...

Моннан соң Уразаев белән Кормаш батальоннарындагы хәл турында сөйләделәр. Беренче батальон вакыйгасыннан соң немецлар винтовка һәм пулеметларны җыеп бикләгәч, солдатны агач мылтык белән өйрәтә башлаганнар. Бик нык күзәтүләр киткән, батальоннардагы гестапо козгыннарының тыз-быз чабуы, төн буе йөренүләре көчәйгән. Листовкалар ябыштыру бик кыенлашкан. Өченче батальондагы гестапочы фельдфебель Блокк, күптән түгел үз читлегенә Рушатовны чакырып, бер кәгазь ертыгы күрсәткән. Рушатов иелебрәк караса, ул үзләре ябыштыра торган листовканың яртыга якын бер кисәге булып чыккан.

— Нәрсә соң бу? — дип гаҗәпләнгән Рушатов.

— Мин дә шуны сорамакчы идем,— дигән Блокк.— Сезнеңчә язылган бугай, белмисезме?..

— Аллам сакласын! — дип кычкырган Рушатов, тиз генә хәйләгә керешеп. — Мин каян белим андый чүп-чар кәгазьләрне?— дип, үзеннән кулы белән сыдырып җибәргән.— Мин гарәпчә генә укый беләм!

Шулай да Блокк кәгазьне яңадан тикшертергә булып, өстәл астына салып куйган...

Уразаев легион солдатлары арасында астыртын агымның һаман көчәя баруын, беренче батальон вакыйгасы нык тәэсир ясавын, дүртбиш кешелек вак-вак төркемнәрнең юкка чыккалавын, корал җыеп алу — солдатны гарьләндерүен әйтте. Бигрәк тә, эшелон озатырга баручы вагон сакчылары еш кына кайтмый калалар икән.

— Хәзер солдатның чүпрәсе тәмам күпергән чагы,— дип тәмамлады сүзен Уразаев.— Шуның өстенә урман кочагында үлән белән дә туенырга мөмкин. Шулай булгач, без вакытны кулдан ычкындырмыйбызмы? Тизрәк кузгаласы иде, иптәшләр!..

Утырыш үзара гөжләп алды. Бу фикерне бик якладылар, ләкин ничек тормышка ашыру мәсьәләсендә генә аптыраш иде: коры кул белән кая барасың? Мылтыклар складта. Корал каян табарга? Нинди юл белән?.. Шул хакта озак бәхәс барды. Төрле вариантлар тәкъдим ителде, ләкин берсен дә ансат кына гамәлгә ашыру юлы күренмәде.

Муса, бәхәснең эчендә булса да, сүз катыштырмыйча, озак уйланып утырды. Үзенең һич кирәкмәгәндә шулай каты авырып китүе өчен үзен әрләде. Бу авыр атнада аны изгән икеләнүләр, эчке шөбһәләр, әлеге кара тамга тудырган әрнүләр, яңгырдан соңгы болганчык ташудай, хәзер инде чигенгән, бәгырь кисеп, юл каплап торуы җимерелгән, ул инде янадан көрәш комарлыгына ташланган кеше иде. Эшнең төрле ягын уйлаганнан соң үз фикерләрен иптәшләре карамагына куя башлады.

— Дөрес әйтәсез,— диде ул,— солдат күңелен суытырга һич ярамый. Бу иң хәтәр нәрсә! Корыч кебек, горнада кыздырып кына булмый аны. Мин вакытсыз тинтерәп китүем өчен гафу үтенәм... Тиз арада поляклар белән элемтәгә керәсе бар, аны эшләрбез һәм хәбәр итәрбез... Кораллану өчен складларны кулга алмыйча булмый. Аларны басар өчен немец часовойларын юк итәргә туры киләчәк. Юк итү өчен тагын корал кирәк. Ичмаса биш винтовка яки биш автомат... Мин, монда эшсез ятудан файдаланып, «Шүрәле» дигән бер музыкаль комедия сымак әйбер яздым. Кыскача гына болай: «Тукайча матур бер урманда шүрәлеләр пәйда була. Карасаң — алар партизаннар, имеш! Легион солдатлары аларны эзәрлекли. Сәхнәдә мылтык белән коралланган бер отделение солдат күренә. Бу коралны уен өчен дип алырга була... Менә шул мылтыкларны өченче батальондагы корал складын басарга файдалану мөмкин булыр иде... Ә сездә нишлибез, Уразаев? Сез бит бөтенләй икенче урында. Ә складлар бер үк вакытта басылырга, батальоннар бер үк вакытта күтәрелергә тиеш!

Харис Уразаев мондагыларның барына да күз йөртеп чыкты. Хәтта үзе өчен дә бик яшерен сыман тоелган серен чишәсе килмәү бар иде аның карашында. Биредә утыручыларның байтагысын якынтын белми дә бит ул. Ничек булыр икән?.. Әмма бу кешеләрнең күзләрендә шик эзе сизелмәде, пышылдап кына әйтергә мәҗбүр булды ул:

— Өч автомат табабыз... Майлап, төреп, күмеп куелган...

— Әз,— диде Муса.— Тагын өчне яки дүртне таба алмыйсызмы?..— Үзе Познаньдагы Домбровскийны уйлап алды: ул булышмас иде микән?..

— Белмим шул,— дип башын кашыды Харис.— Бу бик кыен эш...

— Шулай да, моны эшләү сезнең өстә, — диде Муса. Теге төнге эшеннән соң ул аны кодрәтле кеше, чаралы һәм запаслы кеше саный иде. Табар, әллә нинди хәйләләре бардыр әле Уразайның. — Ничек, иптәшләр, оешма шулай әмер итәме?

— Башка чара юк! — диде егетләр.— Мөмкин кадәр тизрәк шул әйтелгәнне табарга!..

Сүзләре шунда бүленеп калды. Ишек артында кемдер барлыгы ишетелде. Шундук ишек тә кактылар. Алиш тиз генә шешәләргә үрелде, өстәл астына олактырмакчы иде. Фоат исә рюмкаларга сузылды.

Лэкин Муса кул гына селтәде һәм, калганнарга ым кагып, үз рюмкасын күтәрде: куркыр эш юк, әйдә, чәкәшик, ди иде, янәсе.

— Рәхим итегез! — дип кычкырды ул.

Ишекне ачу белән үк, гаҗәпләнгән күзләрен табынга кадап, Рәфикъ Гыйльфанов килеп керде.

— О! — диде ул,— мәҗлесләр күркәм булсын! Монда инде Шәфи туе башланып та киткән икән!..

— Әйдүк,— дип көлде Фоат,— уртасында бул! Сине бер Алабай белән эзләткән идек, тапмый килде!

Рәфикъ аңа күзләрен әйләндереп карады.

— Ул Алабай син үзең түгел идең микән? — дип җавап кайтарды. Алар һәрвакыт шулай үзара төртешеп торалар иде. Аннары Рәфикъның күзе почмакта бөкшәебрәк утырган Әхмәт Симайга төште.— Ә-ә, син дә монда икәнсең әле! Син, кәбәм, үзең молодец, ә? Каршы тавыш та биргән булдың, әмма сыеннан да коры каласың килмәгән!

Әхмәт Симай аны күрү белән үк кызара башлаган иде инде, ә хәзер, колакларына хәтле бурлаттай янып, үз почмагында бөтенләй бөрешеп калган төсле булды. Лэкин шул хәлендә озак югалып калмады ул. Урыныннан сикереп торды да бик җитди генә тавыш белән әйтә куйды:

— Утыр, Рәфикъ,— төкерек чәүмә. Бу шешәләрне Гариф белән мин Берлиннан үзебез алып килдек. Мусага күчтәнәч итеп. Шәфинеке булса, авызыма да капмас идем!

— Нигә акланып торасың, Симай дус? — дип бүлдерде аны Муса, кашларын җыерып.— Безнең акланырлык пычрак эшебез юк. Ә син, Рәфикъ дус, телеңне тыя төш. Мыскыллама минем кунакларымны... Гомумән, бала-чага шикелле йөрүдән туктау яхшы булыр, акыл керер вакыт җиткән!

— Ә мин синең акылыңа мохтаҗ түгел, Муса әфәнде! — дип, кылдай каты чәчләрен җилпеп куйды Рафикъ.— Моңарчы әле әзме-күпме ихтирамым бар иде. Әмма бүген бар да кырылды! Күрсәттең кем икәнеңне! Мин җүләр күпме вакыт синең буш күкәй кабыгы икәнеңне белмичә йөргәнмен! Ярый әле, иң кирәк моментта абайлап өлгердем: менә монда хәзер сезнең ни кыланганнар! — Ул уң янтыгындагы фотоаппаратка шапылдатып куйды.— Ә калганын илгә кайткач, хәрби трибунал алдында сөйләшербез!.. Аннары ул кинәт кенә бик җитез, бик матур жест белән аппаратын боларга төбәде дә, шул ук минутта утын да гөлтләтеп, төшереп тә алды.— Тагын бер доказательство! — Һәм ишеккә борылды.

Фикерләре Муса белән аерылышканнан соң Рәфикъ озак вакытлар редакциядә эшләп йөрде. Алиш аның Казанда чактагы ук иптәше, сүз килешә торган кешесе иде. Рәфикъ аның ярдәме белән фотокор булып китте, ә фотокор булгач һәм яз-җәйләр җиткәч, аның элекке өметләре тагын уянып, еракларга, ireккә чакыра башлады. Ул инде хәзер тәмам бер фикергә килеп җиткән иде һәм мондагы кәмитләрнең соңгыларын күрүче, соңгы тапкыр фотодокумент итеп теркәүче сыйфатында йөри иде. Мусаның Шәфигә тавыш бирүен күргәч, ул бөтенләй буылды; бөтен дөньяны әшәкелек баскан, пычрак! Ярый әле, бер ул бар. Һәм ничектер Симай бар икән. Хәтта Алиштан да кул селтәде, аерылганда битенә төкермәкче булды. Менә хәзер нәкъ шуны эшләмәкче иде ул. Лэкин... өлгермәде.

Моңарчы тып-тын утырган Алиш, башкалар абайлап өлгергәнче, яшен тизлегендә урыныннан ыргылып, бер үрелүдә Рәфикъның арт якасыннан эләктереп алды да ишектән болайга таба тартты. Иптәшләре арасында һәрвакыт юашлыгы, түземлеге, йомшак күңелле һәм туганчыллыгы белән танылган Абдулланың төпкә утырган кара күзләре бу минутта ярсыган юлбарысныкы шикелле очкын чәчеп яна, җыерыл-

ган кашлары сикерә, ә сакал төгеннән күгәреп торган яңакларында ниндидер тимгелләр бии — аның мәһабәт булып кабарган ачуы куркындыргыч иде.

— Тукта, дустым, ашыкма,— диде ул, көчләп тыелган калтыравык тавыш белән.— Ник син безне мыскыл итәсең? — һәм баягыча ук көтелмәгән тизлек белән тегене уңлы-суллы яңаклый да башлады.— Син үзең нәрсә кырдың соң? Такташны сүгеп йөрүдән башка нинди эшең булды?.. — Ул арада булмады, Абдулла аның аппаратын каешыннан тартып өзде дә җан ачуы белән идәнгә бәрде, аннары үзен бөтереп алып, шулай ук идәнгә екты һәм арт ягына типкәли башлады. Шаккатып калган бүлмәдәгеләр һәммәсе дә аягүрә баскан, сүз әйтергә дә, араларга да белмичә, аптырап торалар иде. Ә Алиш, һаман такмаклый-такмаклый, дәвам итте: — Син бит үзең редактор булырга йөрдең. Тик Шәфи белән генә нәрсәдер килешә алмадыгыз...

— Йөрсәм, гәзитне үземчә әйләндермәкче идем! — дип кычкырды Рәфикъ.

Алиш кычкырмый, сүзләре чыжылдап кына чыга, ләкин алар камчы чыжылдавы шикелле тоела иде. Рәфикъ урыныннан тормакчы булуга, ул аны тагын идәнгә салды.

— Әйләндерерсең, пычагым! Йә кеше бул, йә эт бул — икенең берсе. Ә болай кеше башы ашаучы подлец булып йөрмә. Безнең гәүдәләрдән үзеңә күпер салу барып чыкмас.— Алишның ачуы чыгып бетте булса кирәк, яңакларында баягы төерләр сикерми башлады, күзләрендәге куркыныч очкын сүрелә төште, тавышы да йомшарды.— Инде тор, дустым,— диде ул, гади генә итеп.— Өс-башыңны кагын. Теге уенчыгыңны ал да һәм минә табынга утыр. Мә, тот бер рюмка. Әмма, берәр профессорга барып, баш дигән әйбереңне карат. Ул тартмаң начар эшли башлаган хәзер синең...

Рәфикъ барысын да диярлек ул әйткәнчә эшләде. Хәтта Алиш белән чәкәшеп эчте дә. Бүлмәдәгеләрнең һәммәсенә дә оятлы күзләрен түбәнтен генә йөгертеп чыкты, аннары, кинәт өянәге килгән кешедәй, ярсып елап җибәрде һәм, беләге белән йөзен каплап, берәү белән дә исәнләшмичә чыгып китте. Аның баскычтан төшкән авыр аяк тавышлары сүнеп калды... Шуны гына көткәндәй, Булатов шаркылдап көлеп җибәрде.

— Ай, Алиш, җаным! — диде ул.— Үләрем исемдә иде, әмма син изгелек фәрештәсенең шушы хәлгә килү мөмкинлеген һич кенә дә уйлаганым юк иде!

Башка һичкем көлмәде һәм эндәшмәде.

## XII

...Легион частьлары өстенә салынган айлык сәяси һәм дисциплинар карантин мөтдәте тулып узган иде инде. ОКВның Көнчыгыш легионнар бүлегендәге Людерсон әфәнде белән Шәфи үзе барып сөйләшкәч, ниһаять, Мусага рөхсәт бирделәр. Хәзер аларга Мусаның һәр адымын күзәтеп, ниләр кыланып йөргәнен ачыграк белеп торырга кирәк иде. Бу хакта батальоннардагы гестапо бүлекчәләренә алдан ук хәбәр ителде. Һәркайда «күз» һәм «колак»лар куелды. Аның бөтен адымы, почмак саен куелган күзгеләр арасыннан узган шикелле, ерактан ук күренеп торырга һәм кайда нәрсә сөйләгәне дә көне-сәгате белән ишетелә барырга тиеш иде. Шәфигә бу хакта берни дә белдермәделәр. Комод өстенә куелган матур курчак шикелле президент әфәндене мондый вак-төяк нәрсәләр белән борчуның нигә кирәге бар? Ә Муса үзенең шундый күзгеләр арасыннан йөрисен, ниндидер алтынчы тойгысы белән дигәндәй, үзе үк сизеп алды. Шулай да бу аны бик үк өркетмәде, сагайтты гына. Ул һәрвакыт үзе белән йөртә торган кечкенә чемоданына сөлге-сабын,

бер көнлек паек шикелле кирәк-ярактан тыш әле генә язып бетергән «Шүрәле» комедиясен салды да юлга чыкты. Иң элек Познаньга туктады. Анда Мулланур Гәрәевне күреп сөйләшкәннән соң, Домбровский белән күрешү җаен да тапты. Поляк карты ачулы иде. Аның бер каравыннан ук: «Син, егет, эшлексез, ахры!» дигән шелтә аңлашылды. Тик Муса соңгы вакытта үзен тоткарлаган бөтен вакыйгаларны сөйләп биргәч кенә, бер хәтле йомшара төште. Теге авылдагы көтүче картның исән булуын, ә парольнең үзгәргәнлеген әйтте. Гадәттәгечә исән-саулык сорашкач, «Ат югалды араннан, эзли чыктым каладан» диясе. «Ишетмәдем, күрмәдем» дияр. «Тоягында дагасы, колагында тамгасы. Табучыга йөз алтын!» диясе. Ә шуннан соң көтүче синнән йомышыңны сорашыр... Муса, боларның һәммәсен дә кат-кат кабатлап отып алгач, икенче үтенечен әйтте:

— Өч кенә автомат кирәк, папаша...

— Бик әз икән! — дип кашларын җыерды карт.— Без монда андый нәрсәне винтиклап ташыйбыз. Беткәнмени урман юлында автоматлы фриц? Сезнең солдатлар шул якларда яши бит.

— Керпене ялан кул тотып булмый шул, каната, шау-шуы күп була,— дип көлде Муса һәм үз гозеренең төп сәбәбен сөйләп бирде.— Крушинодагы иптәшләр өчен...

Поляк карты башта үз телендә нәрсәдер сөйләнде, сораучыны әрләде кебек тоелды. Аннары гына игә килеп, шул ук станциядәге юл караучы Ян Прохазканың адресын бирде һәм пароль өйрәтте. Муса аны кочаклап үпте.

— Әйбәт кеше син, атакаем! — диде. Сугыш беткәч тә Казанга кунакка чакырабыз без сине. Эх, шунда булыр куаныч!..

...Муса шул кичне үк легионга килеп төште. Әлбәттә, иң элек немец түрәләргә сәлам бирде ул. Зикендорф белән батальон командиры янында булды, хәл-әхвәл сорашты, Шәфи Алмазның сәламнәрен тапшырды, мәдәни-агарту эшләренең торышы һәм капелла белән кызыксынды. Тәрбия пропагандасын көчәйтү кирәклеге турында бик дәртләнеп сөйләде, Рәфикъ Гыйльфановның качып китү вакыйгасын да искә төшереп алды. Кыскасы, хуҗаларның күзенә төтенне житәрлек кадәр җибәрергә тырышты. Ләкин легион шефының чырае сизелер дәрәҗәдә сүрән иде, ул элекке дустанә хисләрен бик үк күрсәтеп бетермәде. Бу хәл Мусаны сагайта төште. Шуңар күрә, ул туп-туры үз дуслары янына китмичә, яңа бер кешенең ишеген какты. Зикендорфның ярдәмчесе Алмаев дигән бер подполковник бар иде, Муса шуңа кагылды. Бу кеше, кайчандыр Совет армиясенең кадр командирларыннан булса да, монда килеп эләккәч, бер эшкә дә катнашмау ягыннан һадиевка бик охшый иде. Мусаның ышанычлы вәкиле оешмага тартырга теләп караса да, битарафлык саклап калды. Немец кушкан хезмәтне башкаруын мәҗбүрлектән генә итеп күрсәтте. Яхшы киемнәрдән генә тегермәнгә төшкән һәм он тузаны кунудан куркып, һаман кагынгалап торган тәти егетне хәтерләтә иде ул. Муса аның белән үзе сөйләшеп карамакчы булды: батальонны житәкләргә тәҗрибәле командир кирәк бит... Ләкин бу кешенең әсирләр язмышы белән бөтенләй кызыксынмавы, аларның нәрсә теләвен белмәве бик тиз мәгълүм булды. Әмма бу кешенең дә бер «секретный» шатлыгы бар икән, ул аны ни өчендер Мусадан яшермәде. Планшетыннан карта чыгарып, инә очы белән генә төрткән, гади күзгә хәтта күренмәслек тә булган зәңгәр нокталар күрсәтте. Муса аңламамышка салынды.

— Бу бит хәзер безнекеләр занимать итә торган позиция,— диде ул, пышылдап кына.— Күрәсезме, һаман болай киләләр. Стал-быть, берәр елдан безне дә коткарачаклар! Тиздән илгә, яңадан Тбилисигә!..

Муса шаккатты, ләкин һични сиздермәде.

— Шунда хезмәт иттегезмени? Нинди частьта идегез? — дип кенә сорады.

— Да, да, шунда, брат. Полк белән командовать иттем. Эшләр шәп иде минем. Закавказиянең винограды үзе генә дә ни тора!

— Әйе-е...— диде Муса.— Виноград тәмле нәрсә инде ул...— Һәм бу бүлмәдән чыгып та китте. «Подлец!» — дип сүгенде ул клубка барышлый.— Виноград сагынган! Коткаруны күтәп ята торган полк командиры!..» Аның авызы тәмсезләнеп китте, кат-кат төкеренеп куйды.

Шулай дөньясын каргап атлаганда, шаккаткыч бер хәл булып алды:

— Тукта, бәләкәчем! — дип кычкырды аның артыннан кемдер.

Борылып карауга ис-акыллары китте Мусаның. Аның каршына, уң аягы белән әз генә титаклап, Арыслан ашыга иде. Күргән күзләренә һич кенә дә ышанасы килмичә, катып калды ул.

Арыслан исә килгән уңайга ук олы гәүдәсе белән аны кочаклап алды да:

— Әй, бәләкәчем, туганкаем! — дип, мөлдерәмә тулып, елап та җибәрде.— Менә бит... менә бит... анасын эт ялагыры...— дип такмаклый иде ул.

— Тукта, олыкаем, бу нинди хәл? — диде Муса, һаман гаҗәпләнүендә дәвам итеп.— Юк, син үзең түгелдер бу, өрәгең генәдер, җеннәрдер, пәриендер!

Арыслан аның саен өзгәләнеп елый бирде. Моңарчы нинди генә авыр кайгыларны да зарсыз күтәреп, елмаеп уздырган бу нык кешенең болай йомшап китүенә Муса хафаланып куйды, аны тиз генә юатырга тырышты.

— Тукта, сабыр ит әле, Арыслан баһадирым, былтыргы кар шикелле, үзеңнән-үзең эреп төшмә әле,— дип көлгән булды.— Мәйдан уртасы бит, ярап бетмәс, әйдә, бүлмәгә керик.— Һәм ул аны, сабый баладай җитәкләп, кунак йорттагы үз бүлмәсенә алып китте.

Бөтенләй ис-осында юк чакта кинәт кенә Арыслан белән очрашу Муса өчен гаять дәрәҗәдә кызыклы һәм мөһим иде. Шуңа күрә ул аңа йөз төрле сорау яудырып, беренче батальон хикәясен сөйләтергә кереште.

— Һәй, бәләкәче-ем, бәхет юк шул минем, фарт юк, авызын корт чаккырысы-ы! — дип, үзеннән башлады Арыслан. Аннары, Актабановны мактый-мактый, батальонның авыр һәм данлы юлын, корбаннар биреп булса да, үзебезнең якка исән-сау чыгып җитүен сөйләп бирде. Инде тәмам котылдык дигәндә генә Онисим Гуриичне җирләргә туры килүен һәм шул чакта үзе дә яраланып, яңадан бу якта калырга мәҗбүр булуын әйтте. Ләкин Шпигельне ничек итеп җәһәннәмгә озатуын сөйләмәде ул. Актабанов шикелле шундый кадерле кешенең һәлак булуы һәм батальонның шундый олы сәфәре белән чагыштырганда, Шпигель хакында тел пычратып, сөйләп тә торасы юк иде!..

— Менә шулай яраланып кына хәрап булдым шул, бәләкәчем! — диде ул, тагын көрсенеп.— «Ник качтыгыз, ничек качтыгыз?» — дип допрослый-допрослый җелекне суырдылар. Без картраклар обозда идек, мылтык белән алып киттеләр, кая куалар — шунда барырга мәҗбүр булдык, дип бардым. Тәки бернәрсә белә алмадылар. Шулай итеп ай ярымлап лазаретта допроста яткач, янә шушында, өченче батальонга китереп тыктылар. Өстеңдә лигиун мөндире булгач, тамгалы сарык шикелле инде, һаман бер абзарга китереп ябалар икән... Хуҗалык командасында ат тизәге тазартам — эшем бик зурдан, чукынып киткере... Әле син килгәнне ишетеп, абзардан чыгып йөгердем. Нәрәт бирсә бирер нимес, күрим әле, мәйтәм.

Муса да аның хәле өчен кайгырышып алды. Әмма шулай да Арыслан белән очрашуына ул бик шат иде. Батальонның бөтен героик эпопеясе аның күз алдында хәзер. Алдагы хәрәкәтләр өчен юл сызганда зур гына сабак булачак...

— Син ул хәтле бетеренмә әле, Алып бабайның олы малае,— дип юатты ул аны.— Урман сукмакларында әле һаман да кошлар сайрый. Кәкүкләр безгә озын гомер вәгъдә итә, кыр казлары матур сәфәр юллары күрсәтеп тора... Калганын үзең бел. Май кап. Үзеңә юлдашлар әзерли тор... Сөйләшеп атларга күңелле булыр...

Арыслан да елмайган булды. Ләкин аның күңеле сынык иде әле. Үзе өчен уңышсыз чыккан юлны яңадан кабатларга өмете җитеп бетми иде аның.

— Белмим, бәләкәчем,ниләр генә булыр инде...— дип, авыр адымнар белән чыгып китте ул.

Клубта Мусаны артистлар труппасы көтә иде. Инде Узедомда очрашканнарына бик күп вакыт узганлыктан, бары да сагынышып каршыладылар. Муса өстәлгә «Шүрәле» комедиясен чыгарып салды.

— Менә, дуслар, сезгә яңа әсәр,— диде ул.— Укып карыйк. Әгәр яратсагыз, сәхнәгә куярсыз.

Бар да пьесага ябырылды.

Мусача җиңел агыш белән көлке итеп язылган әсәр, әлбәттә, егетләрне бик тиз яулап алды. Урманның һәр почмагында диярлек пәйда булган яшел тиреле шүрәлеләрнең немец солдатын кытыклап җанын алуы, ә соңыннан аларның партизаннар булып чыгуы бигрәк тә кызык язылган иде. Артистлар шау-гөр килеп алдылар. Укып бетерү белән үк рольләр бүленде һәм өйрәнүләр дә башланып китте. Режиссер Кормаш булса да, баштагы көннәрдә Муса үзе дә булышырга сүз бирде.

Егетләр һәр почмак саен парлап-парлап роль кучерә калдылар, Муса, Рушатов белән Кормашны ияртеп, һавага чыкты. Июльнең эссе киче иде, тынчу иде, тирләтә иде, нииндидер киң бер елгадамы, күлдәме рәхәтләнеп су коенасы килә иде. Су керүнең чиксез рәхәтлеген бөтен җан-тәне белән татырга өйрәнгән Муса колач җитмәс киң Иделне, Казан якынындагы Займище күлләрен сагынып алды. Монда да шундый урын юкмы соң дигәндәй, тирә-ягына каранды.

— Әйдәгез, ичмаса, чишмәгә барып юыныйк! — диде ул.

— Анда хәзер часовой куелган,— диде Кормаш.— Шикле урын...

Кинәт дөнья тарайган сыман булып, Мусаның тыны кысылды... Алар кечкенә һәм сай гына Едлино инешенә атлап, яр буендагы яшел чирәмле күләгәгә утырдылар. Яшеренү кирәкми иде әле. Чөнки Кормаш та, Рушатов та сәнгать эшләре башлыгы буларак Мусага буйсыналар. Ул алар белән теләсә кайда сөйләшә ала, су коенырга килү дә гаеп түгел.

— Эх,— дип куйды Муса,— бер генә чумарга иде!..— Аннары, тирәякны күзәтеп, тирле битләрен сөртеп алды.— Сөйләгез.

Гайнан Кормашев, кулына өзеп алган ак әрем сабагын бөтергәләп, аның Мари республикасындагы Бәрәңге районында да, Актүбә далаларында да, монда да шулкадәр әрсез үсүенә гаҗәпләнеп утыра иде. Шулай да бу үләннең үзенчә тәмле бер исе бар. Авырсырак булса да, ничектер ландыш чәчәген һәм юкә алмасы исен хәтерләтә ул.

Гайнанның һаман шулай нәрсәдер уйланып утыруы, Рушатовның да эндәшмәве Мусаны кабат әйтергә мәҗбүр итте:

— Ник авызыгызга су каптыгыз, егетләр, нәрсә бар?

— Ә? — дип куйды Кормаш, йокысыннан уятылган кешедәй.— Нәрсә дип... кыен мәсьәлә — шул инде... Рушатов белән дә күпме уйлаштык, Алмаевның да кылын яңадан тартып караган идек... Юк, батальон командирлыгына кулай кеше таба алмыйбыз.

— Ә роталар өчен ничек?

— Роталарга Мичуринны, Сәйфелмөлековны, Фәритовны, Габдулла Батталны, Габбас Шәриповны, Рушатовны күздә тотабыз. Взводларның күбесендә шул ук унтер офицерлар, ефрейторлар кала. Алар безнең яклы. Бик үк ышанып бетмәстәйләренә яңа рядовой солдатлар билгеләнде. Инде килеп, хәрби припаслар складының сагын юк итүче оператив группа эшен, әгәр риза булсагыз, мин үз кулыма алмакчы булам. Склад тирәләрен, аның каравыл составын ныклап өйрәнеп йөрим. Каравыл зур түгел, эшне төгәлләү артык кыен булмастыр кебек тоела...

Муса уйланып утырды. Гайнан әйткәннәргә каршы да төшмәде, уңай җавап та бирмәде хәзергә. Һәр якны үлчәп эш итәргә кирәк иде.

— Ә Зиннәт Хәсәневкә бер эш тә юкмыни? — дип сорады ул.

Бу юлы басынкы табигатьле Рушатов җавап бирде:

— Без батальонны менә аңа тапшырмакчы булыбрак тора идек. Яшь ягыннан да кече түгел, үзе өлкән лейтенант, ротамы, батарей командирымы булган, бик энергияле, тимер егет...

Муса бу юлы да каршы килмәде, тик бер бармагы белән генә башын кашып куйды.

— Әйе, ныклап уйлашасы булыр,— диде ул.— Монда әле Берлиндагы иптәшләр дә килер ул вакытка. Гариф Шабаевны сезнең батальонның комиссары итеп билгеләсәк, ничек булыр? Мин үзем Крушинодагы батальонга беркетелмәкче булам...

Егетләр дәшмичәрәк тордылар. Байтактан соң гына, ашыкмас сүзле Рушатов әйтеп куйды.

— Киресенчә эшләгәндә ничек булыр икән, Муса иптәш? Безнең батальонның командиры Зиннәт булса, аның янына көчлерәк комиссар — сез үзегез яхшырак булыр идегез. Ә тегендә — Уразаев, райком секретаре булган кеше, үзе дә көчледер. Аңа ярдәмгә сездән башка кеше дә кулай булыр иде...

— Мин дә шул фикердә, Муса абый,— дип кушылды Кормаш.— Сез үзегез ярдәм итмәсәгез, Зиннәткә авыргарак туры килер...

Түбән баштан кемнендер яр буенча салмак кына атлап килгәне күренде. Рушатов та, Гайнан да, муеннарын сузып, шул якка карады. Килүченең күзлек пыяласы кичке кояшта әз генә елтырап киткәли иде. Ул ниндидер уйлы кеше шикелле, аяк йөзенә карап, гамьсез генә атлый бирә...

— Ә-ә, куркыныч юк,— диде Гайнан,— Ямалтаев бугай бу. Минем якташ егет...

— Сызыйк тизрәк урман эченә, егетләр,— дип, урыныннан кузгала башлады Рушатов.— Күрмәсен!

— Нигә? — дип гаҗәпләнде Муса.— Кормашның якташы ич!

— Шикләнәм,— диде Рушатов.— Астыртын кеше күренә...

— Алай булгач, качмыйбыз инде. Качсак — без дә шикле кешеләр булып чыгабыз, — дип җавап бирде Муса һәм өстендәге күлмәкләрен сала башлады.— Чишенегез. Чумдык суга!

Кыргызстан һәм Актүбә далаларында яшәп, су керүне әллә кайчан онытккан егетләр, тиз-тиз чишенеп, инешкә сикерергә мәҗбүр булдылар. Тик инешнең чумар җире дә, йөзәр урыны да табылмады: чыпчык тезеннән генә иде шул аның суы!..

Ямалтаев килеп җитте. Гайнан аны да үз яннарына кыстады. Һәм Ямалтаев, бик теләп, бик чөкердәп сөйләшә-сөйләшә, алар белән су керә башлады...

## ТУГЫЗЫНЧЫ БАШЛАМ

### I

Кем дә кем безнең сәләтне күрә белсә һәм аны мактап бер-ике җылы сүз дә әйтсә, без ул кешегә эрибез дә китәбез. Һәм моның гаебе дә юк. Чөнки бу — Әтәч белән Күке макташуы түгел. Чынлап та, әгәр бер тәҗрибәлерәк кеше икенче бер яшь кешенең сәләте барлыгын күреп, шуны үзенә дә аңлатып бирсә, аңарда ышаныч уятса, моның нинди гаебе булуы мөмкин?

Муса да шулай итте. Киекбаевның нинди тавышлы булуын һәм ничек җырлавын күптәнге бер репетициядә ук сизеп алгач, Кылычбай белән аерым сөйләшеп,ниләр җырларга һәм тавышны ничегрәк тотарга киңәшләр бирде. Егетнең моңа бик күңеле булды. Шуннан соң алар һаман дуслаша, якыная бардылар. Легионга килгән саен Муса аңардан «Азамат»ны җырлатмыйча калмый иде. Әмма Кылычбай аның белән генә канәгатьләнмичә, үз сәләтен ихтирам итә торган Муса абыйсына башкортның бик матур, бик кызыклы шаян җырларын да әйтеп бирә башлады. Бу җырлар башкорт халкының нихәтле бай күңелле, нинди җор телле, шаян сүзле булуын, җырда гына түгел, тормышында да ни дәрәҗәдә бәйсез, иркен яшәргә теләвен күрсәтә иде. Ә инде Кылычбай Узедомда «Элмәле»не җырлагач, ул бөтенләй тәгәрәп китәрдәй булды. «Салават күпере кебек суга барган юллары!» Димәкки, кызларның чишмә сукмагы — салават күпередәй матур дугаланып һәм җиде төрле нур балкытып тора. Шәп, бик шәп! Шундый колачлы һәм бай образны Мусаның татар җырында очратканы юк иде әле!

Узедомда алар тагын да якынаешып киттеләр. Кылычбай буш вакытларында Муса бүлмәсенә керә һәм үзенең балачак хикәяләрен сөйләп, аны көлдерә торган булып китте. Аннары ул үзенең төрле телдә җырлый беләсе килүен, хәтта сөйләшергә дә бик кызыгуын әйтеп утырды. Ул хәзер башкортча, татарча, чувашча, русча җырлый һәм сөйли белә, немецча да әз-мәз сукалый башлаган. Тик тел шомартыр кеше генә юк. Немец үзенчә эндәшсән, сөйләшмәгән була, эт борчасы! Үтнәкә Кылычбай аны барыбер өйрәнәчәк. Ә хәзер аны поляк теле бик кызыктыра башлаган. «Дзинькую...» нинди йомшак әйтелә бит. Әллә кайсы төшендә генә бер музыкасы бар шикелле...

Муса гаҗәпләнеп куйды.

— Ә поляклар белән ничек аралаштың соң? — дип сорады ул.— Алар легионга килеп йөрмиләр ич.

Кылычбай тиз генә җавап бирмәде, хәтта кызарып киткәндәй булды. Әмма Мусаның белергә теләве күренә иде. Шуннан соң гына, күзгатуы авыр булган серен ачып салды. Ул бер атналык чагында ук анасыз калган икән. Күрше хатыны һәр көнне бер бәләкәй чокыр белән кәҗә сөте кертә торган булган. Шуны җылы су белән кушып, Кылычбайга имезгәннәр... Әллә шул кәҗәкәй сөтенә гыйшкы төшкәнгә, әллә шул сөткә дә туймый үскәнгә, Кылычбай әле дә сөт ярата икән. Менә шул тыйнаксыз нәфсесе аны якын тирәдәге поляк авылларына өстерәгән. Һәм шунда ук поляк теленә дә гыйшык тота башлаган.

Кылычбай моны да бер көлке итеп кенә сөйләгән иде, ә Муса елап җибәрә язды. Бер теле ачылгач, Киекбаев шунысын да әйтеп салды: ул анда кайбер өйләрдә җырлап та биргәләгән. «Азамат»ны да, «Катюша»ны да поляклар шаккатып тыңлаганнар, кызлары аулак өйләргә чакыра башлаган, шулай итеп ул анда «үз кеше» булып бара икән хәзер...

Муса шуларны уйлый-уйлый авыл юлыннан бара. Аның белән янәшә Кылычбай атлый. Ул аны Зикендорф әфәнденең үзеннән сорап алды: Киекбаев хәзер башкорт, татар, чуваш, рус һәм немец көйләрен

башкара белә. Полякча да берәр көй өйрәнергә тели. Аңа аларның «Зазюленька» дигән көйләре бик ошаган, шуны отып аласы килә, диде. Шулай итеп алар көй отарга киттеләр. Мусаның Узедомда биргән киңәше буенча Кылычбай Седици хуторында берничә тапкыр булган һәм пан Пжышко белән дә болай гына танышып өлгергән иде инде. Шуның өчен аларның юлы кыен булмады. Авылга җитәрәк сулга сугылып, вак урманлыкка керделәр дә кәҗә сукмагы белән Пжышконың мал көткән җиренә үк килеп чыктылар. Танышу Зигмонт өйрәткәнчә булып чыкмады. Кылычбай, полякча бер-ике сүз кыстырып, карт белән исәнләште дә:

— Менә сезгә бик әйбәт кунак алып килдем,— диде.— Аш сорамый, ит сорамый, бөмбер сорамый, фәкать «Зазюленька»ны җырлап бирүегезне генә сорый. Җыр сөюче кеше.— Аннары колагына пышылдады: — Шагыйрь!

Карт, кояш ундырган аксыл керфекләрен күтәреп, Мусага карап алды. Аның эчтәнрәк карый торган шикчән күзләрендә һәм нык йомылган калын иреннәрендә: «Күреп карыйк, кемдер бит әле»,— дигән төслерәк мәгънә ята иде. Аннары ул үзе ясаган гади генә чөлемен авызына капты, суырып карады, төтене чыкмагач, яңадан авызыннан алды. Ул арада яшел үләнгә, үзе туган җирендәге шикелле, иркен сузылып яткан Кылычбай «Зазюленька»ны суза да башлады. Егетнең олы тавышына сокланып ияргән сыман, карт та әкрен генә кушылып китте. Поляк һәм белорус халкының яратып җырлый торган «Кәкүк» көе иде бу. Көйнең матурлыгына, аваз һәм интонацияләр байлыгына Муса сокланып утырды. Кайчандыр Солтан Габәши язган, ә Газиз Әлмөхәммәтев бик оста итеп башкарган татар һәм башкорт «Кәкүге» исенә төште. Алар арасында моң һәм матурлык ягыннан, кошлар тулы туган урманнарны сагындыру ягыннан нindидер уртаклык бар кебек иде. Муса тыңлап кына калмады, янында махсус нота кәгазе булмаса да, чемоданыннан сызыклы дәфтәр чыгарып, шунда нота билгеләре дә төшерә утырды. Тагын бер кат җырлатканда тулысынча язып булачак. Картның тавышы әллә ни көчле түгел, ләкин үз халкының милли аһәңен кирәгенчә әйтеп бирә ала, ә Кылычбай аның бормаларына ияреп, өйрәнеп бара иде.

Ниһаять, җыр тәмам булды, Муса, «Дзинькую» дип, картның кулын кысты. Аннары Кылычбайдан сорады:

— Ә син пан Пжышкога үзебезнең «Кәкүк»не җырлап күрсәткәнең бармы?

— Юк бит, әй! — диде егет аптырап.

— Нигә, белмисең мәллә?

— Беләм. Хәтта Газиз агаем ерлаганын да ишеткәнем бар, күптән үк инде. Ә менә картка ерлап бирергә хәтергә дә инмәгән, һәй, исәр!— Шуннан соң ул аягүрә басты һәм күп итеп тын алды да, тавышына дала киңлеген, урман тирәнлеге шыңгыравын җыеп, Газиз агаена охшатырга тырышкан дугайлы бормалар белән җырлап җибәрде. Бер сүзен дә аңламаса да, көйнең төп моңы карт күңеленә бик тиз барып җитте. Ул җанланып, күз читләренә чаткылар тезеп, елмаеп утырды.

— Менә бусы безнең «Зазюленька»,— диде Кылычбай, җырлап бетергәч.— Шәпме, пан?..

Танышуының болай гади башланып китүе Муса өчен уңайлы булып чыкты. Шушы көйләр тирәсендә теге-бу сүз йөртә торгач, алар шактый үзләшеп киттеләр, һәрбер хәрәкәт үзенең табигый эзенә төште. Шуннан файдаланып, ул төп максатына күчәргә теләде, әмма картның өченче бер кеше алдында сөйләшәсе килерме?

Муса Кылычбайга ым какты: әйләнгәләп кил, янәсе. Егетнең зирәклеге бар икән, тиз аңлады, хуторга барып килергә рөхсәт сораган

булды. Анда, пани Һаннаның кар базында, бик салкын, бик тәмле сөт көтә икән ләбаса аны!

Кылычбай ерагая төшкәч, карт белән яңадан исәнләшкән булып, Муса үзенең паролен әйтте. Сәер генә килеп чыккан бу ретуалга ышанырга теләмәгәндәй, карт үзенең шөбһәле һәм сынаучан күзләре белән Мусага шактый озак карап торды. Сүзләрне яңадан кабатлатты. Тик шуннан соң гына, әле һаман нидер булуын көтә торган кеше кыяфәте белән, сорап куйды:

— Ни кирәк соң сезгә, көйләр язып алучы шагыйрь әфәнде? — Аның бу сүзләрендәге киная усал сарказм булып яңгырады. Хәтта «гестапо кошы» дип тә аңларга була иде аны. Әмма мондыйларга инде күнегеп өлгергән Муса сүзләрнең яңгырашы мәгънәгә нинди юнәлеш биргәнен тикшереп тора алмады. Бу кытыклы сорауга бик гади итеп, кытыксыз гына җавап бирде:

— Миңа сезнең «урман егетләре» штабыннан бер вәкил белән очрашырга кирәк,— диде.— Бик мөһим эш бар.

Карт ике кулы белән берьюлы селтәнә башлады: гүяки, аны умарта кортлары сарып алган һәм хәзер ябырылып чага башлаячаклар!

— Әйтмәгез дә, тыңламыйм да! — диде.

Муса ашыкмады. Моңарчы җитди күренеп тә «партизан» дигәнне ишетүгә кинәт тигезлеген югалткан картның хәлен аңлый иде ул. Шуңа күрә аңа суынырга мөмкинлек бирде. Аннары гына үзләренең төп планын пан Домбровский яхшы белгәнен аңлатты.

— Күршегездәге дүрт-биш мең кешене күрәсезме?..— диде.— Неужели сез безгә туганнарча булышмассыз?.. Без коралллы таяныч эзлибез...

Карт тирән сулап куйды, житен чәченә кар сибелгән башын кашыды, шикчән күзләре белән тагын Мусаны сөзде.

— Бу сүзләрнең чынлыгына ничек ышанабыз соң? — диде ул.

Чынлап та, ничек һәм нәрсә белән ышандырырга соң? Бу эштә шаһитлар, дәлилләр китереп, документлар күрсәтеп буламыни?

— Бик кыен сорау бирдегез, пан Пжышко,— диде Муса елмаебрак.— Сезне ышандыру — җиңел эш түгел. Тик бер шау-шуны, бәлки, үзегез дә хәтерлисездер әле: моннан байтак элек, шушы легионның бер батальоны фронтка җибәрелгәч, үз ягына чыгып китте. Аларның коралы бар иде... Шуннан соң легион солдатының мылтыгын алып складка бикләделәр, фронтка җибәрмәс булдылар... Аңлашылдымы?

— Соң, чыксыннар да китсеннәр, урманда табышырлар шунда...

— Мөмкин түгел. Әйтәм бит: солдат кулында корал юк. Аңа коралллы поддержка кирәк, аңлыйсызмы?

Карт тагын бер сулап куйды.

— Аңлыйм да бугай шикелле сыман,— диде ул, тагын кинаяләп.— Тик... ни бит... Ак та, кара да дип әйтеп булмый хәзергә. Ни... иртәгә минем янга Колча [1] сугылып китсен. Үзегез күренмәгез. Сез монда ят кош.

Шуның белән сүз өзелде. Һәм Муса карт белән сүлпәнрәк исәнләште дә, Кылычбай кайтканны да көтмичә, китеп барды. «Һай бу поляк картлары! — дип уйлады ул.— Бөтеркәләнеп беткән карама төбе шикелле. Чөй сугардай җайлы җеген һичбер табалмассың!.. Шундый сак кыланалар...»

Хәзер аңа Крушинодагы батальонга китәргә кирәк иде. Легионга кереп тормады, хутордан бер чакрымдагы станциягә чыкты да шунда юнәлде. Ике сәгатьтән соң ул инде әлеге юл караучыны табып, тагын Домбровский өйрәткән пароль сүзләрен кабатлап утыра иде. Бәхетенә каршы, бу тимер юлчы бик алай кире булып чыкмады. Мусаны баштанаяк күзләре белән бораулап алды да:

[1] Кылычбай.

— Беләм,— диде.— Җил шундыйрак бер көй сызгырып узган иде... Иртәгә әзер булыр...

Муса аның кулын кысты һәм үзе урынына чалмалы-чапанлы мулла җибәрәчәген, маскировка өчен яхшырак булачагын әйтте.

Июль эссесендә күп йөрүдән кибегеп, тәмам әлсерәп батальонга барып кергән Муса Уразаев белән Бикмулла хәзрәтнең чәй эчеп утырган чагына тап булды һәм ябырылып чәйгә ташланды. Хәзрәт кешегә калай чәйнекне берничә тапкыр кайнатырга туры килде. Уразаев аңа батальондагы хәлләрне сөйләде. Солдат тормышында яңалык бар икән: немецлар, легиончыларның унбиш-егерме кешелек төркемнәрен үз солдатлары белән кушып, төрле участокларда тимер юл сакларга җибәрә башлаганнар. Һава һөҗүмнәре вакытында урман кырыена йөгергән легион солдатларының күбесе кире әйләнеп чыкмыйча яки башка юллар табып, һаман кача баралар икән.

— Бу хәлгә ничек карыйсың, Муса? — дип сорады Уразаев.

— Бик начар карыйм! — диде Муса.— Димәкки, солдатның сабыр савыты тулган, безне көтеп тора алмый, ышанычы сына башлаган! Ашыгырга, ашыгырга кирәк безгә!..

Аннары ул шушы бер-ике көндә поляк партизаннары белән сөйләшәчәген һәм мәсьәләнең тәмам чишеләчәген әйтте. Әзер булып торырга кушты, көне-сәгате хәбәр ителер, диде. Хәзрәт кешегә иртәгә кайда барып, кемне күрергә һәм нәрсә алып кайтырга кирәклеген аңлатты. Чәй туйганчы эчелгәч, ишек алдына чыктылар. Уразаев үзенең командирлары әзер булуын һәм кузгалышны ничек башлап җибәрәчәкләрен сөйләп бирде. Муса аңа җитди, тәҗрибәле кеше итеп карый һәм ышана иде. Шуңа күрә бу батальонның язмышы өчен артык борчылмый да иде ул. Тик менә Седельце белән Демблин лагерьларындагы әсирләрне нишләтәсе? Аларда легионга хәзерлек бүлекчәләре яши, төркемләп-төркемләп бу батальоннарга җибәрелеп торалар. Ничек аларны да кузгатып алып чыгасы? Дөрес, оешманың анда да үз кешеләре бар хәзер һәм эшлиләр дә. Ләкин ул урыннарның Едлино яки Крушиногa ерак булуы бик комачау итә. Поляк партизаннарын һәр лагерь яки һәр батальон тирәсенә китереп булмый бит, алар ниндидер бер урта ноктага гына якыная алалар...

Муса шул хакта күп уйланса да, мәсьәләнең хәзергә чишелешен таба алмады.

— Ярый, дуслар,— диде ул.— Минем бит әле рәсми эшләр дә бар, командованиегә күреним. Сез монда Иблис хәзрәтләренең (Геббельсны үзара шулай дип йөртәләр иде) безне кайгыртучан пропаганда боерыкларын онытып җибәрмәдегез микән?..

Көлешеп кул бирештеләр дә Муса батальон штабына таба китеп барды. «Мәдәни эшләр тикшерү»не ике-өч сәгатькә сузгач, аннары батальон командиры белән очрашып, үзешчәннәр группасы төзү кирәклеге турында яңадан бик нык бәхәсләшкәч, кичке поезд китәр вакыт җитте, һәм Муса, майор белән бик дусларча саубуллашып, станциягә юнәлде.

Легионга кайткач ул, чемоданын кунак йорты бүлмәсендә калдырды да, культвзвод барагына керде. Аның бер башында пропагандистлар тора иде. Ишектән кергәндә үк Димскинең шаян җырлар башкарганы, ә тыңлаучыларның бик рәхәтләнеп көлгәне ишетелде. Ул егет үзенең йомшак баритоны белән бик җитди итеп җырласа да, озынча йөзе, озын борыны, озын муены, кыйгач кашлары һәм юка иреннәре үзалдына әсәренеп торгандай күренгәнгә, көлмичә мөмкин түгел иде. Егетләр барысы да Муса белән күрешеп чыктылар.

— Менә Фәхрине кич утырырга чакырдым әле,— диде Мичурин.— Артист халкы кадерле бит ул. Безнең ише сүз боткасы белән туйдыручыларны берәү дә чакырмый.

— Дөрес,— диде Муса,— күп такылдаганны берәү дә яратмый. Әйдә, дәвам ит, Фәхри дус, бик матур жырлый идең.

Егет ялындырмады, уена килгән җырны әйтеп бирде:

Әнкәй мине биләгән,
Тар бишектә тирбәгән.
Күп теләкләр теләгән,
Плен төшмә, димәгән...

Көлке дә түгел кебек үзе, ләкин барыбер көлештеләр.

— Ай, әнә шунысы шул: плен төшмә! дип теләргә онытканқ— диде берсе.

— Сугыш буласын әйтмәгәннәрдер аңа,— диде икенчесе.

Ишектән йөреп торалар иде. Шулар арасында Мусага су ярында очраган егет килеп керде. Аның сизелерлек бүлтәйгән пыялалы, ак никель тирәле күзлеге ничектер калай сымак ялтырап күренүе белән кешенең игътибарын үзенә җәлеп итә иде. Ул, барысына да дусларча тавыш белән уртак эндәшеп, үз койкасына таба узды да кулындагы китап-дәфтәрләрен тумбочка өстенә куйды. Бу баракта үзен өлкәнрәкме, хуҗаракмы дигәндәй сизгән Мичурин, аңа таба атлап, нәрсәдер пышылдагач, Муса янына алып килде.

— Бу безнең яңа пропагандистларның берсе, таныш булыгыз: Мәмүт Ямалтаев,— диде.

— Һа! — дип көлде Муса.— Без инде күптән таныш. Хәтта бер инештә су кергәнебез дә бар!..

Аның каршында торган тәбәнәгрәк буйлы, җиңел гәүдәле, сыек кара чәчле һәм яньчегрәк борынлы Ямалтаев теге кичтә ничек очрашуларын Мичуринга аңлатып бирде. Алар сөйләшеп киттеләр.

— Гайнанга якташлыгым шуннан: мин Кустанай өлкәсенеке, шул якта туып үскән, армиядә кырыгынчы елдан ук, кадрда идем мин, кадрда! — дип тезеп китте егет. Аның тавышында һәр сорауга «шартлатып» җавап бирергә теләүме, ясалма бер шатлыкмы, ничектер шуларга охшашлы билгеләр бар кебек иде. Сүз дәвамында егетнең армиядә комсомолец булуы, сугышның өченче аенда ук пленга эләгүе, хезмәткә кадәр җиде класс бетереп, авыл сельпосында эшләп йөрүләре аңлашылды. Егет бу мәгълүматларны да бик теләп сөйләгәндәй итте, пропагандист булу өчен үзенең белеме азрак икәнлегенә борчылып та алды, үз кеше сыман да күренде. Тик аңкавындамы, борын эчендәме ниндидер куыш булганга, ахры, тавышының тыңкыш чыгуы һәм бая күрешкәндә уч төбенең суык юешлеге генә Мусада тулысынча яхшы тәэсир калдырып бетермәде. Хәер, Муса шундук үзен хөкем итеп тә алды: кешенең физик кимчелекләре аның мораль сыйфатын түбәнәйтә торган мисал була аламыни? Без әле һаман шул мишчәнчә фикер йөртергә яратабыз! — дип тиргәде ул үзен.

Барак стенасына эленгән немец сәгате, чиркәү тавышы чыгарып, тугызны сукты. Фәхринең җыр тавышына җыелган яшьләр тарала башладылар. Гармунчы белән җырчы үзе дә чыгып китте. Муса да урыннан кузгалды. Мичурин аны озата чыкты. Кичке караңгы белән тышта әз генә салкынчалык төшкән иде.

— Аерым таныштыруым шуның өчен иде,— дип аңлатты Мичурин, әкрен тавыш белән,— бу егет батальонда яңарак кеше һәм бик күпне беләсе килә. «Нигә без немец пропагандасыннан башка үз сүзебезне дә әйтмибез солдатка?» — ди. «Нигә безнең бер патриотлыгыбыз да юк, бер оешмабыз да юк?» — ди. Бик кыю эшләр башкарасы килгән кешедәй сөйләнә. Башкаларны да шундый сүзләр белән аптырата икән.

— Ә сынийсызмы соң сез аны? — дип сорады Муса.

— Әлбәттә. Ләкин хәзергә бер начар ягын да күргән юк. Төннәрен генә тынычлык бирми. Бер-ике көндә бер теш сызлавы кузгала. Бер

куыш теше бар, үзем карадым, шул сызлый дип акыра башлый. Аптырагач, медпунктка ыштанчан чыгып чаба, ләкин аннан кайткач та икеөч сәгать буена илаулый, безгә дә йокы бирми. Тик таң алдыннан гына гырлап китә.

— Сәер икән,— диде Муса.— Нигә соң ул аны суыртмый?

— Монда теш суыручы врач юк. Ә Радомга барып, немецтан суыртырга курка, имеш. Я авызыңны каерып ташлар, ди.

Муса көлеп куйды. Кайчандыр Оренбурда чакта үзенең дә шулай теш суыртырга куркып йөрүе исенә төште. Һәм шунда ук: сары чәчле, шаян күңелле рус кызы Ольганың аны кочаклап торып тешен суырттыруы күз алдына килеп басты. Нинди матур чаклар булган, һәм нинди еракта калган алар, әйтерсең, йөз ел узып киткән!..

— Шулай да ачыклагыз, өйрәнегез,— диде Муса.— Тел яздырырга йөрүче булмасын.

Мичурин аны кунак йортка кадәр озата килде. Кул бирештеләр.

— Мин дә шулай уйлыйм,— диде.— Кай төшендәдер бер билгесез төене бар кебек тоела...

II

Иртәгесен төш турыларында Кылычбай аны клубтан эзләп тапты. Муса янында Кормаш кына иде. Ләкин Кылычбай ул барында сер ачарга теләмәде.

— Муса агаем, сыгың әле был якка,— дип, аны сәхнә артына чакырды. Әллә ничәгә бөкләп бармак арасына кыстырылган бәләкәй генә кәгазь кисәген Мусага тоттырды. Ул кәгазьдә кәкре-бөкре латин хәрефләре белән нindидер фамилияме, адресмы язылган иде.

— Хәзер үк Радомга,— дип пышылдады Кылычбай.— Пан кушты. Шушы кәгазь буенча дип әйтте.— Һәм ул чыгып та китте. Сәгать бердән баракта кизү торасы бар икән. Муса әлеге кәгазь кисәген Кормашка күрсәтте дә, репетиция үзенә генә кала инде дип, Едлино станциясенә ашыкты. Ул килеп җиткәндә поезд яңа гына кузгалган иде, йөгерә торгач, көч-хәл белән генә соңгы вагонның арт баскычына эләгеп калды. Казан һәм аның дача юллары исенә төште. Займище поездына яки Түбән Ослан пароходына күпме тапкырлар шулай актык секундта гына өлгерергә, ә кайчакларда җан-фәрманга чабып килсә дә, борын сузып калырга туры килә иде аңар. Һәммәсе шулар бик зур пошыныч булып, мәшәкать булып күренгәннәр!

Едлино белән Радом арасын поезд егерме минутлап кына йөри иде. Муса вагоннан төште дә билгеләнгән адресны эзләп китте. Польшага котырып һөҗүм иткәндә, немецлар бу шәһәр йортларының һәм промышленностеның яртысын җимереп бетергән, исән калган завод-фабрикларын сүтеп үзләренә ташыган булганлыктан, хәзер монда тормыш ярым үлек хәлендә иде. Комендатура белән бер кечерәк гарнизон һәм берничә госпиталь генә бар. Төрле халык әсирләреннән төзелгән легионнар һәм лагерьлар да шәһәрдән читтәрәк яши, поляк партизаннары яки авиация һөҗүме дә ишетелми. Шыңгырап торган буш урамнардан Муса шәһәрнең үз кешесе кебек атлап барды. Тик Радомка елгасының уң култыгы булган кечкенә инештәге күпер төбендә генә шлагбаум бар икән, аны шунда туктатып, документларын тикшерделәр. Әмма аның кәгазендәге зур ерткыч кошлы ОКВ пичәтен күргәч, немец фельдфебеле үрә катып, честь биреп калды. Күперне үткәч, җимерек биналар тагын да күбәйде. Кайбер чатларда урам исемен күрсәтерлек стеналар да калмаганлыктан, «Стефан урамы» яки «Грабарь тыкрыгы» дигән сүзләр казык башына сугылган фанер такталарга язылган иде. Муса шулай бара торгач, кечерәк кенә бер костелга җитте. Күңеленнән ятлап барган адресның номеры шушы костел стенасында күренде. Ул аптырабрак

карангалады да алга узып китте. Андагы йортларда башка саннар булгач, тагын гаҗәпләнеп, кире борылды. Аргы чатта кинәт бер күләгә күзенә чалынды һәм шунда ук почмакка тайпылды... «Алай икән...» дип уйлады Муса. Һәм үзе дә җәһәт кенә каршыдагы тыкрыкка кереп китте. Әллә ничә урамнардан уратып, җимерек биналар арасыннан туры кистереп, теге күләгәнең үз артында юклыгына ышангач кына, әлеге костелның ишек алдына килеп керде. Яртылаш җиргә сеңгән калын стеналы бу изге йортның ишек-тәрәзәләре дә бәләкәй булып, борынгы тимерчуен белән төренгән иде. Ишек алды түрендә бер кечкенә флигель сыман нәрсә бар икән, Муса шунда атлады, аның каршына яшь кенә сап-сары бер кыз чыкты һәм: «Пан ксендз костелда, шунда кирәгез»,— диде. Әле һаман берни аңламаган һәм бары тик үзенә кирәкле йортны яхшылабрак сорамакчы гына булган Муса, кире борылып, костелга кереп китте. Бик борынгы бина булса кирәк, тәбәнәк ишекләрдән иелеп эчкә узганда, стеналарның аршын ярым чамасы калынлыкта булуын, идәннәренә чуен плитәләр җәелүен, буяу сылардай һәр урында бик күп изге рәсемнәр барлыгын күрә барды ул. Тар, озын һәм караңгы коридорны узганнан соң әз генә яктырылып китте. Түрдәге бер генә тәрәзә яктысында түшәмнәрнең югары күтәрелеп китүен һәм гөмбәзләрендә һәртөрле канатлы фирештәләрнең күп булуын күрде. Муса туктальп калды. Бу ярым караңгы бушлыкта әдәм заты һаман күренми иде әле. Шулай байтак торгач, тамак кырып алды. Биек гөмбәздә шыр бушлык яңгырап китте дә тагын таш тынлык басты. Мусаның көләсе килде: ялгыш керде, ахры, бу ташландык чиркәүгә. Чыгарга дип кире борылды. Шунда гына артыннан тавыш килде:

— Сезгә кем кирәк иде? — Бу сүзләр ярым поляк акценты белән русча әйтелде. Муса сискәнеп киткәндәй булды. Әле моннан бер секунд кына элек үле бушлык иде бит, каян чыкты соң бу тавыш? Ул яңадан борылуга, каршысында кап-кара озын киемле, түшендә олы ак тәреле, пеләш башлы, кырык биш-илле яшьләрдәге бер ксендз тора иде.

— Борчуым өчен гафу итегез,— диде Муса.— Мин 29 нчы йортны эзли идем, ул сан сезнең костел почмагында күренә, урамда сорар кеше булмагач, аптырап кергән идем.

— Эзләгән йортыгыз шушы, пан Муса,— диде ксендз.

Мусаның күзләре шар булды. Беравык ни әйтергә дә белмичә торды. Каршында торган руханины тагын бер кат җентекләп караганнан соң гына:

— Сез?.. Пан Лебедь?..— дип сорый алды ул.

— Әйе,— диде ксендз әкрен тавыш белән генә.— Гаҗәпләнмәгез, пан Пжышко үзе килеп, сезнең теләкне генә түгел, хәтта «Р»ны сөер әйтүегезгә кадәр тасвирлап чыкты. Шунлыктан мин сезне күрү белән танып алдым. Йөрегез.— Һәм кулы белән алга узарга димләде. Үзе янәшә атлап, костел түренә таба узгач, рухани стенадагы ниндидер бер кара шайтан турысында тукталды. Шайтан, бер дә көтмәгәндә, әкрен генә күздән югала башлады. Биш-алты секунд узмагандыр, аның урынында кап-кара бушлык кына калды.— Кирәгез,— диде пан Лебедь.

Аптырап калган Муса, сукыр кеше төсле кармаланып һәм ышанычсыз гына хәрәкәтләр белән, шул бушлыкка атлады. Пан аның артыннан керде. Ниндидер тар гына юлдан бер-ике чат борылгач, алда зәгыйфь кенә ут яктысы күренде. Өч-дүрт баскыч түбәнрәк төштеләр һәм алда, бер калын чаршауны узу белән, шактый иркен бүлмә ачылып китте. Түгәрәк өстәл, диван, ике урындык куелган һәм һәркайда келәмнәр җәелгән, тик тәрәзә барлыгы гына күренми иде. Патер диваннан урын күрсәтте дә шул ук баскычтан өскә менеп китте.

— Мин анда булыйм әле, мәхәллә кешеләре гыйбадәткә килә башлар,— диде ул.

Бу бүлмәдә тагын да салкынчарак шикелле иде. Ни өчендер патер-

ның шәрә башы Мусаның күз алдына килде һәм ул баш монда гел туңадыр кебек тоелды. Борынгы таш бинаның салкынлыгы Мусага да үзенең рәхәт тәэсирен ясап, аны йокымсырата башлады. Һәм ул, сөйләшүләрне пан Лебедь үзенең гыйбадәт эшләрен бетергәч алып барыр, күрәсең, дип, диванга сузылып алырга да уйлаган иде, ләкин алай булып чыкмады. Аның баш очыннан гына полякчалатып: «Исәнмесез» дигән яңа тавыш ишетелде. Муса артына борылып караса: өлкән буйлы, пәһлеванча киң күкрәкле, олы куллы бер кеше басып тора иде. Каян гына пәйда булды соң тагын бусы?.. Ул аңа каршы аягүрә басты һәм: «Гаҗәеп бу кешеләр, үз эшләрен әллә нинди серләр, билгесезлекләр белән төрмәсәләр, әллә нинди техник хәйләләр кулланмасалар, күңелләре булмый, ахры»,— дип уйлап алды.

— Мин — сез сораган кеше булам,— диде әлеге пәһлеван, бик чатак рус теле белән.— Гаҗәпләнмәгез, озакка сузылган оккупация чоры көрәшендә дөньяның мондый әкәмәтләре дә кирәк була икән... Рәхим итегез, утырыйк, сөйләшик,— дип өстәде.

Югарыда орган уйнаган тавыш ишетелде. Озакламый аңа кушылып хор белән җырлый башладылар. Шул чакта почмактан тагын бер кеше пәйда булды. Бу юлы инде Муса күреп калды: почмак тавыш-тынсыз гына икегә аерылып китә дә, шуннан килеп чыгалар, ә ябылгач, җек билгесе һичбер сизелми икән.

— Качышлы уйнар өчен шәп икән бу,— дип көлемсерәде Муса.— Хәйләкәр эшләнгән...

Пәйда булган кешеләр икесе дә гади гражданнар киемендә иде. Ләкин таныша торгач, пәһлеван буйлысы партизан отрядының комиссары, Варшава коммунисты Маршалковский икәнлеге, майор чинында булуы, икенчесе — пленнан качып поляк партизаннарына кушылган совет офицеры капитан Баруздаев икәнлеге билгеле булды. Алар үзләренең вәкаләтләрен белдерә торган кәгазьләр дә күрсәттеләр. Мусаның андый кәгазьләре юк иде һәм булуы да мөмкин түгел иде. Чөнки «Дүртенче комитет»ның башкалар белән рәсми мөнәсәбәткә керә торган аппараты юк һәм кирәк тә түгел иде. Муса шуларны аңлатып, гафу үтенде.

— Зарар юк, эш кәгазьдә түгел, безгә Домбровский белән пан Пҗышко аша кайбер нәрсәләр билгеле, — диде Маршалковский яртылаш полякчалатып. Баруздаев аны тәрҗемә итте. — Аннары сезнең легионнан качкан кайбер егетләр дә бар бездә. Алар да әзрәк беләләр. Димәк, сөйләшер җирлек бар...

Муса үз планнарын әйтеп бирде. Аның мөмкин кадәр күбрәк кешене алып чыгасы килә иде. Шуңа күрә Едлино белән Крушинодан тыш, Демблин һәм Седельце лагерьларын да атады. Маршалковский костюмының кайдагыдыр арка кесәсеннән чыгарып, бик юка бүзгә төшерелгән кечкенә бер карта җәеп салды. Муса әйткән пунктларны карап, байтак кына уйланып утырды.

— Седельце төшеп кала, — диде ул. — Ерак, Висланың теге ягында. Мөмкин түгел. Башка вакытка калдырыйк. Ә менә бу өч пункт — ярый. Әмма ничек аларны бер ноктага җыябыз?

— Мәсьәләнең кыен ягы да шунда, — диде Муса. — Сез бу тирәләрнең җәгърафиясен, әлбәттә, миңа караганда күп яхшы беләсез. Шушы өч ноктага бер үк чама ераклыкта булган урман массивы табып, шунда уртак пункт билгеләсәк, ничек булыр?..

Өчесе дә бүз карта өстенә иелеп, яшел тапларның зуррагын эзләргә керештеләр.

— Менә Кшерка урманы, — диде комиссар. — Аңа кечкенәрәк массивлар тоташа бара һәм безнең төп базаларга таба илтә...

— Димәкки, төп җыелу ноктасын шунда билгелибез? — дип сорады Муса. Тегеләр каршы килмәделәр. — Алайса, икенче мәсьәләгә күчик:

Демблиннән Крушино һәм Едлинога киләсе пополнение батальоннар кутәреләсе көнне юлга чыга. Әмма алар поезд белән киләләр. Аралары ике сәгатьлек кенә. Монда иң мөһиме: юлдагы авария белән поездны туктату, шул чакта немец охранасын засададан чүпләү. Ә эшелондагы солдатларны, шул моменттан файдаланып, безнең кешеләр урманга алып кереп китәчәкләр. Кызганычка каршы, алар коралсыз булачак...

Маршалковский белән Баруздаев тагын уйланып утырдылар. Акбүз картага төшкән пәрәвез җепләредәй кара юл сызыгының уңайлы нокталарын эзләп карадылар.

— Менә монда «Бүре чокыры» дигән бер тирән елга бар, коры булса кирәк, эчендә — куе зиреклек,— диде Маршалковский. — Линия бәләкәй агач күпер өстеннән уза... Ничек уйлыйсың, Баруздай, шунда күперне бозып, засада утыртсак?..

Баруздаев картага яңадан иелде. Әһә, чокыр икенче якта да дәвам итә. Усаклык, ары таба сазлык. Да...

— Минемчә, шуннан да уңайлы урын күренми, — диде ул. — Диверсия һәм засада! Иптәш комиссар, сез анда егерме кешелек автоматчы группа белән мине җибәрегез. С честью выполню!

— Не зарывайся! — диде майор. — Ансы соңыннан.

— Инде өченче мәсьәлә, — дип дәвам итте Муса. — Едлино һәм Крушинодагы батальоннар бер үк көнне, бер үк сәгатьтә күтәрелергә тиеш. Әмма көне дә, сәгате дә хәзергә расланмаган. Чөнки ул мәсьәлә сезнең ярдәмче отряд килеп җитеп, безгә булыша алырдай якын позициягә урнашуга бәйләнгән. Шунсыз мөмкин түгел, ни өчен дисәң — батальондагы солдатларның кулында шулай ук корал юк. Беренче батальон чыгып киткәннән соң мылтык һәм пулеметларны складларга җыеп бикләгәннәр. Димәкки, һәр батальондагы күтәрелеш иң элек склад сакчылыгын юк итү һәм коралга ташланудан башланачак. Эш башлау өчен безнең бары бишәр генә автомат яки винтовкабыз булачак. Дөрес, склад сакчылыгын юк итү өчен бу да җитәр кебек, чөнки алар күп түгел, әмма көтелмәгән тоткарлык килеп чыкса, нишлибез? Шуның өчен бу ике батальон тирәсенә, ичмаса, егермешәр кешелек автоматчылар группасы кирәк. Булышлык дикме, каплавыч дикме?.. Батальоннар икесе дә урманга орынып тора диярлек.

— Да-а, — дип куйды Маршалковский көлемсерәп. — Бирәсез сез безгә задание, генерал әфәнде!..

— Юк, — диде Муса да көлеп, — генерал ук түгел, өлкән политрук кына. Эшнең үкенечле булып түгел, уңышлы булып бетүен телисе килә иде. Киресенчә булып чыкса, бик каты еларга туры киләчәк безгә. Асылган гәүдәләр өчен агач ботаклары җитмәве ихтимал...

— Андый ук ямьсезен уйламый тор, шагыйрь дус, — диде Маршалковский. — Мин, җүләр, шагыйрьләрне оҗмах кошы дип, ә поэзиянең хәрби стратегия-тактика белән алыш-биреше юк дип уйлап йөри идем. Болай да була икән ул, ә?..

Шуннан соң алар тагын байтак сөйләшеп утырдылар. Югарыда орган тавышы әле һаман яңгырый иде.

Ниһаять, алар бер фикергә килеп, уртак карар кабул иттеләр: батальоннар тирәсенә унбишәр кешелек ике группа, «Бүре чокыры»на саперлар белән 20 кешелек бер группа; төп җыелу пункты Кшерка урманына 20 кешелек бер группа билгеләргә. Барлыгы 70 кеше. Ләкин бу партизаннар, билгеләнгән урыннарына гади кешеләр киемендә, коралларын бик нык яшергән хәлдә, берәмләп җыелырга тиеш. Төп база ерак булганлыктан, башкача мөмкинлек юк. Шуңа күрә аларның җыелып җитүе өчен байтак вакыт кирәк булачак. Шулардан чыгып, батальоннардагы күтәрелешне 14 нче августның төнге 10 сәгатенә билгеләргә. Бөтен төркемнәр белән җитәкчелек итү Маршалковскийга тапшырыла. Батальоннар белән җитәкчелектә Муса Җәлилов һәм Уразаев

җаваплы. Һәр ике тарафтан көтелмәгән үзгәрешләр килеп чыга калса, пан Пжышко аша алдан элемтәгә керергә. Бөтен эш — катган яшерен!

Дөрес, Мусаны срок мәсьәләсе бик үк канәгатьләндерми иде. 14 август бик ерак тоелды аңа. Ул күп кенә бәхәсләшеп тә карады. Ләкин Маршалковский үзенекендә торды, шуннан да иртә мөмкин түгел, диде.

Шуннан соң кул бирештеләр, вәгъдә анты куешкан шикелле, ирләрчә җитди генә кочаклашып алдылар һәм, башка һич сүз кузгатмыйча, пәһлеван комиссар белән капитан Баруздаев үз почмакларына атладылар да юкка чыктылар. Муса алар артыннан барып, стена почмагына карап торды һәм көлеп җибәрде. «Гаҗәп, хәйләгә бик сәләтле икән бу поляклар», — дип куйды ул. Югарыда орган тавышы әкренләп тынды. Озакламый пан Лебедь тә баскычта күренде.

— Сез инде ачыгып беткәнсез, — диде ул. — Өйгә алып керәсе иде дә бит...

— Аңлыйм, — дип елмайды Муса. — Ансы инде башка вакытта. Әйтик, матур язлар килгәч!..

— Әйе, язлар килгәч, — дип кабатлады ксендз.

Муса баскычтан күтәрелде, ләкин баягы юлыннан атларга өлгермәде, пан Лебедь аны сулга борды:

— Моннан юл кыскарак, — диде ул.

Кап-караңгы тар коридорның алгы ягында тоныкк кына яктылык күренде һәм Муса баягы залга түгел, ә туп-туры тышка, җимерек йортлар арасына килеп чыкты. Тар гына сукмак белән урамга атлады. Ул да баягы түгел, икенче урам иде. «Адашып бетәрсең монда, — дип уйлады ул, — ычкынырга кирәк тизрәк!»

## IV

Муса поляк партизаннары белән килешкәннән соң бик атлыгып Едлинога кайтты. Ниһаять, иң кыен мәсьәләләрнең берсе хәл ителде. Димәкки, хәзер таяныч бар, юл ачык! Инде килеп актык төенне генә чишәсе калды. Аннары киң урман кочагы, аның яшерен сер тулы сукмаклары буйлап туган якларга таба сәяхәт башланачак!

Кайту белән клубка юнәлде. Анда барган репетициягә үзе җитәкчелек итеп, артистлар уенына күп кенә үзгәлекләр кертте. Сүзсез солдат булып уйнаучы Ямалтаевка да, җан өреп, үлек хәленнән чыгарды. Шул ук вакытта Кормаш һәм Рушатов белән сүз алмашкаларга да мөмкинлек булды. Репетиция беткәч, музыкант һәм артистларның нота белемнәрен тикшерде. Ул инде бу эшне күптән башлаган иде, ничек үзләштерделәр икән? Аннары фон Зикендорф янына калын гына бер ноталар җыентыгы күтәреп керде.

— Сезгә бүләк итәм, майн һерр, — диде. — Немец халык җырлары. Мин аны Радомнан алып кайттым. Менә шул җыентыкны легионга күбрәк кайтартсагыз, яхшы булыр иде, безнең музыкант һәм җырчылар андагы иң һәйбәт көйләрне өйрәнеп, немецча да җырлый башлар иделәр.

Зикендорф сыек кына елмаеп куйды.

— Нигә, начармыни? — дип гаҗәпләнде Муса, беркатлы кешеләрчә. — Бөек немец халкының матур көйләрен татар егетләре җырлый икән — бу, минемчә, мактаулы эш!..

Зикендорф тагын отылды. Ул соңгы вакытларда Мусаны байтак күрмичә торгач, Блокк сөйләгән һәр төрле шик-шөбһәле фаразларга ышана һәм Мусаны астыртын усал кеше дип уйлый башлаган иде. Ә хәзер килеп Мусаның шул хәтле ихлас күңелдән немец халык җырлары кайгыртып йөрүен күргәч, күңеле яңадан аптырауда калды.

«Һәрхәлдә, яшертен комиссарга караганда, ачык күңелле шагыйрь күбрәк бу егеттә», — дип уйлады карт немец. Ә Муса Зикендорф белән Блокк күзенә ныграк ташланырдай тагын берничә шундый эш башкарып алды: шул көннәрдә нииндидер мәүлүтме, гашүрәме бәйрәме килеп җиткән икән, солдатка ике көн ял бирделәр. Муллалар аларны җыеп, ачык мәйданда намаз укыттылар. Шуннан соң алар, үзара төркем-төркем булып, елга һәм чишмә буйларына, урман итәкләренә таралып, күңел ача башладылар. Культвзвод һәм башка бүлекчәләрдән җыелган шундый бер төркем солдат, кунак йортына килеп, Мусаны да урманга, кура җиләгенә алып китте. Берсенең аркасында аккордеон, Кылычбай кулында газетага төргән шешәләр, Зиннәт Хәсәнев кулында кухня тастымалына уралган ашамлыклар бар иде. Алар байтак барганнан соң, чынлап та кура җиләге үсә торган вак агачлы ачыклыкка килеп чыктылар. Һәммәсе дә мәмердәп пешкән җиләкләргә ташланды. Кайберләре үзләренең бала чакта җиләккә бару истәлекләрен сөйләп алды. Урман тын, якын тирәдә кеше тавышлары ишетелми иде. Озакламый Гайнан Кормаш, Рушатов, Габдулла Баттал, Солтанай Фәритов һәм тагын берничә егет берәм-берәм бу төркемгә килеп кушылды. Шуннан соң алар, яшел үләнле матур бер мәйданчык сайлап, шунда тәгәрәделәр. Кылычбай шешәләрен сүтеп, кружка һәм стаканнар шылтырата башлады. Зиннәт табын җәйде, Фәхри бер чынаякка кура җиләгенең иң эреләрен генә җыеп китерде. Хәл кадәренчә табылган поляк бемберыннан һәм ризыклардан барысы да авыз итеп алдылар. Уенкөлке сүз башланды, ләкин ул озакка бара алмады, Гайнан Кормаш аягүрә басты да:

— Фәхри дус, син уңга — йөз метр, Фәритов, син сулга — йөз метр, Кылычбай, син алга — йөз метр, Әмиров, син артка — йөз метр, — дип команда бирде. Аннары һәркайсының бурычын аңлатты. — Тирә-якны нык күзәтергә, горизонтта шикле фигура күренсә, Киекбаев, «Ирәмәлкәй»не җырлый, Фәхри — «Карурман»ны, Фәритов мандолинда «Эрбет»не уйный, Әмиров гармонда «Галиябану»ны сыза.

Дүрт егет күрсәтелгән дүрт тарафка китеп барды. Яшерен оешманың булачак рота командирлары белән берлектәге утырышы эшкә кереште. Иң элек барлык команда составы расланды. Теге көнне өчәүләшеп фикер алышканча, Муса аларның исемнәрен һәм нинди бүлекчәгә билгеләнүләрен әйтеп чыкты. Тагын фикер алыштылар. Әмма кертелгән тәкъдимгә каршы килүче булмады, аларны расладылар.

Кормашның оператив группасына сигез кеше билгеләнде. Склад часовойларын мөмкин кадәр тавыш-тынсыз алырга, шау-шу кузгатмаска кушылды.

Батальонның радио, телефон, телеграф шикелле элемтә челтәрен, радист Омаров командасындагы биш кешелек төркем, Кормашлар склад сакчыларына ташланудан ун минут элек эштән чыгара. Чыбыклар берничә урыннан киселеп, радиоаппаратлар ватылып, тиз генә торгызылмаслык хәлгә китерелергә тиеш.

Кузгалыш көне: 1943 ел, 14 август, кичке сәгать 10. Бу вакытка склад сакчылары алынган. Спектакль бетеп, солдатлар клубтан чыгуга музыкантлардан трубач Байсаров сигнал уйный. Оешма билгеләгән командирлар үз солдатларын әйдәп складларга ташлана һәм тиз генә мылтык, автомат, җиңел пулемет һәм гранаталар белән коралланa. Шуннан соң булачак хәрәкәтләрдә һәркем батальон командиры Зиннәт Хәсәнев һәм батальон комиссары Муса Җәлил боерыкларына буйсына. Немецлар каршылыгын җимерү белән төп көчләр урманга керә башлый. Өченче рота, каплавыч булып, урман кырыена ята һәм төп көчләргә юл алырга мөмкинлек бирә. Аннары әкренләп үзе урман эченә чигенә бара һәм, дошманнан аерылып, төп көчләргә кушыла. Бу операциядә поляк партизаннарыннан килгән ярдәмче группа да булышачак. Яралыларны

һәм корбаннарны дошман кулына калдырмаска! Алдан ук рота саен санитарлар билгеләп, кирәгенчә носилкалар булдырырга.

— Бурыч менә шундый, иптәшләр, — диде Муса. — Монда әле безнең ике атнадан артык вакытыбыз бар. Тагын бик күп мәртәбәләр уйлашып карарбыз. Сез дә уйлагыз. Аерым детальләрдә ачыклык җитмәсә, кат-кат эшләп карагыз. Мин үз вакытымда монда килеп җитәрмен. Конкрет мәсьәләләр хакында шунда тагын бер сөйләшербез. Командирлар, бүгеннән үк үз кешеләрегез белән бик нык аралашыгыз, эчләренә керегез. Шул ук вакытта шымчылардан, дошман җибәргән провокаторлардан бик нык сакланыгыз. Монда әйтелгән көн, сәгать һәм кузгалыш мәсьәләсен фәкать үзегез генә белергә! Бу — безнең уңышны хәл итә торган иң мөһим хәрби сер. Әйдәгез, шушы серне ялгышып кына да ачмаска ант итик!

Җитди һәм киеренке төс белән утырган егетләр барысы да аягүрә бастылар. Күкрәк түреннән тыелып чыккан тантаналы тавыш яңгырады:

— Бу изге хәрби серне һичкем алдында ачмаска ант итәбез!

— Хәерле сәгать, хәерле уңыш телик үзебезгә, дусларым! — диде Муса.

Командирларның әле генә шундый кырыс күренгән йөзләре тирән дулкынланудан кинәт яктырып китте, бер-беренең кулларын кысыштылар, кочаклашып алдылар, бәхетле юл теләштеләр...

Аннары, яңадан яшел күләгәгә утырып, мәҗлес башладылар. Дүрт якка карап сызгырудан соң постлар да килеп җитте. Хәзер аларның кирәге юк иде инде. Күләмле авызына бая ук «ябалак шулпасы»н шактый эләктереп алган Кылычбай «Әлмәле»не яңгыратып җибәрде:

Аппак икән, йомшак икән
Җаныемның куллары,
Салават күпере кебек
Суга барган юллары! —

дип, бөтен кешене рәхәтләндерде ул. Димски дә аңардан калышмады, Әмиров белән Фәритов гармон һәм мандолинда сыздырдылар. «Кура җиләгенә сәяхәт» бик күңелле узды. Муса, батальонга да берничә егет белән кочаклашып, җырлап кайтып керде. Баскыч төбендә торган Зикендорф киң елмаеп куйды:

— О-о! Майн һерр Мусза Һумерoф ист ангеһайтерт!..[1]

Иртәгесен Муса икенче батальонга китте. Анда Уразаев һәм Бикмулла «хәзрәт» белән шушы ук мәсьәләне сөйләште. Поляк партизаннарының булышлыкка һәм алып китешергә килүләрен хәбәр итте. Батальонны алып чыгу аларның икесенә һәм үзләре билгеләгән командирларга тапшырылды. Ярдәмгә оешма тарафыннан Гариф Шабаев билгеләнүен һәм аның 12 августта килеп җитәчәген вәгъдә итте Муса. Анда ул озак юанмады, шушы йомышлары тәгәлләнү белән Демблинга юнәлде. Юлда аның күзләре гел вагон тәрәзәсендә булды. Кшерка урманы башланган массивны, аннары «Бүре чокыры»н карап узды. Әнә нинди тирән икән ул. Куе агачлык засаданы якын ук китерергә җай бирәчәк икән. Качарга да шәп...

Демблиндә ул немец начальникка кереп, Зикендорф әфәнденең телдән әйткән үтенечен тапшырды: легион башлыгы инде байтактан бирле пополнение көтә, шуны тизрәк җибәрүләрен үтенгән иде. «Өйрәнүләр бетмәгән, унбиш көнсез дә җибәрә алмыйбыз» дип җавап бирде Демблиндәге немец. Мусага шуны белү кыйммәт иде. Бу мөддәт алар билгеләгән көнгә туры килгәнлектән, елмаеп куйды.

— Анысын гына көтәр инде Зикендорф әфәнде, — диде ул. — Калганын үзегез хәбәрләшерсез тагы... — Һәм үз кешеләрен эзләп китте.

---

[1] О, безнең Муса әфәнде кызмача икән!..

Монда беренче килүендә үк усал телле, усал күзле бер кеше белән очрашкан иде ул. Соңыннан, ныклабрак таныша башлагач, Баскаков фамилияле кызыклы бер егет булып чыкты бу кеше. Аның агач аяклы әтисе татар авылында рус бае тоткан тегермәндә засыпкәче[1] һәм каравылчы булып озак еллар яшәгән. Валентин Баскаков шул авылда туып үскән. Татар малайлары аны Вәлеттин дип йөртә башлаганнар. Ул әнисе өйрәткән рус телен татар теленә караганда аксатыбрак сөйләгән. Соңыннан шул колхоз кешеләре булып киткәннәр, тимерче булган, партиягә кергән. Сугышта да шушы авыл егетләре белән бергә әсирлеккә эләккән һәм аны Демблингә дә үзләре белән алып чыкканнар. Тегe вакытта аның Мусага каты орынуы юл таба алмаудан гаҗиз булу аркасында иде. Муса икенче очрашуында аңа ул юлны күрсәтеп бирде һәм Баскаков аны бик теләп кабул итте. Ләкин Муса бер шарт куйды:

— Моннан китәргә ашыкмыйсың. Без сине башта отделение, аннары взвод командиры итәрбез, немецларга яхшы хезмәт итсәң, әлбәттә, — дип көлде ул. — Ә син легионга җибәреләсе кешеләрнең күзләрен ачып, башларын җилләтеп озатасың. Үзеңә ярдәмче булырлык иптәшләр тап.

«Вәлеттин» Баскаков эшли башлады һәм үзенә йөкләнгән эшне моңарчы йөз кызартырлык итеп үтәмәде. Аның әллә ничәмә агитатор егетләре бар, һәм Демблиннән чыккан егетләр батальоннарга ватанчыл рух алып киләләр иде.

Муса кыскача хәлне Баскаковка да сөйләп бирде. Бу юлы инде үзең дә, иптәшләрең дә калмый, бергә чыгасыз диде. 14 нче августта сезне «Бүре чокыры» күперендә кунаклар каршы алыр. «Эш» башлану белән вагоннардан җиргә сибеләсез һәм үрмәли-үрмәли, урманга перебежка! Сез инде коралсыз булырсыз, шулай да берәр дистә «лимон» хәстәрләсәгез, шәп булыр иде, озатучы «дусларыгыз» алдына «төтен коймасы» корып китәр идегез.

Баскаков башта бу сүзләргә бик куанган иде, хәтта кулларын уып куйды ул: «Эх, котылабыз икән!» — диде. Әмма берничә минуттан соң пошына да башлады. — Әгәр барып чыкмаса? Аларны унөчендә яки унбишендә озатсалар? Шулай итеп аймыл булырга туры килсә?..

— Алай булмас, — диде Муса. — Лагерь башлыгыгыз унбиш көннән соң диде. Сез шул вакытка әзер булып торыгыз. Әгәр шулай да китү көнегез туры килмәсә... «Бүре чокыры»н узгач Кшерка урманы башлана, менә шул ике арада вагоннардагы стопкраннарны ачып, тиз генә тышка сикерегез. Һәм лимон яудыра-яудыра урманга керегез. Анда сез юлдаш табарсыз... Главное — не ждать нянек, действовать самостоятельно, но организованно! — дип, бармак янап сүзен бетерде ул.

Баскаков әз генә көлемсерәп куйды:

— Бу — куркытуыгыз түгелдер бит, иптәш Гумеров?

— Юк, әлбәттә, — диде Муса. — Ләкин бу юлы мин командир буларак сөйләшәм. Шуңа күрә бу әйткәннәрне үтәү — закон! Сүзсез. Ә ничек үтәүнең оператив планын төзү — сезнең өстә. Әлбәттә, калган иптәшләр белән киңәшеп. Ә хәзергә: хуш, дустым! Алдагы көрәшү — Кшерка урманында. Хәерле юл!

## VI

Немецлар, бик зур көч туплап, бишенче июльдә Курск дугасында һөҗүм башладылар. Берничә көн буена өзелми барган искиткеч каты сугышлардан соң алар кайбер уңышларга да ирешteләр. Ләкин бу уңышлар әле бик бәләкәй иде. Күпме көч кую, ут һәм металл түгүгә карамастан, алар совет гаскәре сафларын өзеп тактик тирәнлеккә, танк һәм мотопехота иркенләп чабарлык киңлеккә үтә алмадылар.

[1] Ашлык алып торучы.

Монда һәр ике яктан меңәр ярым диярлек танк бүксәгә-бүксә килеште. Һәр ике якның меңләгән самолетлары күкләрне каплап алды. Аларның ничек ажгырып бер-беренә ташлануларын карар өчен күз күреме җитәрлек түгел иде. Уннарча мең туплар, тәүлекләр буенча гөрселдәп, җирне тетрәтеп тордылар. Монда йөзләрчә мең солдат пулемет һәм автоматлардан бер-беренә ут яудырды. Җәйнең чилләсе иде. Борынгы дастаннардагы шикелле, күк йөзен тузан катыш кара сасы төтен каплады, кояш тотылгандай җир өсте караңгыланып китте, үлем ачысы белән атлар чинады, бүреләр улады, һәртөрле җанварлар җан газабы белән ыңгырашып, мөгрәшеп бу тирәләрдән качтылар. Сугыш шулай каты булды. Андагы җирләрдә ятып калган солдат гәүдәләрен җыеп һәм санап бетерерлек түгел иде. Менә шуңа күрә дә немецлар бәләкәй генә уңышларын да бик олы күрсәтәселәре килеп, яман шау-шу кубардылар. Геббельс әфәнденең бөтен пропаганда машинасы хәрәкәткә килде, һәм барысы да совет гаскәрләрен тар-мар итү, Сталинград өчен үч кайтару турында кычкыра башладылар. Шунсы гаҗәп, июль ахырларында инде дошман һөҗүменең бугазына таш утырган булса да, һәм безнекеләр каршы һөҗүмгә күчеп, аның үзен җимерә барсалар да, тылдагы пропаганда һаман көчәя, һаман җиңү турында кычкыра бирде. Чөнки бу инде немецның актык тилпенеше, үләрлек яраланган ерткычның җан ачысы белән тырмашуы иде...

Шулай да пропаганда кубарган шау-шу легион солдатлары арасында төрле хәбәрләр тудырды: «Немец тагын бик каты алга бара икән, Курскины һәм тагын әллә кайсы шәһәрләрне алган икән, шул яктан әйләнеп, арттан китереп Мәскәүгә сугачак икән, безне дә озакламый шул фронтка озатасылар икән...» дип сөйләделәр. Бу һөҗүм турында чын хәлне белү һәм төрле имеш-мимешләр белән солдат күңелен чуалтмау өчен легион оешмасына яңа һәм ачык мәгълүматлар, пропаганда материаллары кирәк булды. Шуларны алып кайту өчен август башында Берлинга кеше җибәрергә уйладылар. Гадәттә мондый йомышны оешманың тапшыруы буенча Габдулла Баттал белән Фәритев үти иде. Бу юлы Фәритев башка музыкантлар белән каядыр концертка киткән булып чыкты. Шуңар күрә Кормашев, Батталның үзен генә җибәрмәкче булып, аңа документлар яздыру өчен штабка керде.

Зикендорф әфәнде, бер генә кеше җибәрүне хуп күрмичә, икене җибәрергә кушты. Фәритовның өйдә юклыгын әйткәч,

— Соң башка кеше ярамыймыни? — диде. — Әнә яшь кенә пропагандист Мәмүт Ямалтаев барсын, Берлинны да күреп кайтыр шунда, иптәш тә булыр...

— Мәйлегез, — дип җавап бирде Кормаш. — Ул егетне әзрәк беләм, — миңа якташрак кеше, Казагстаннан...

Шулай итеп, Зикендорф әфәнде бу очракта гестапочы фельдфебель Блокк роленә керде. Чөнки Ямалтаев, инде ай ярым буена төрле рольгә кереп бик астыртын гына иснәнеп йөрсә дә, һичбер «җеп очы» табалмый, ә немецларга ашыгырга кирәк иде.

Фельдфебель Блокк, әлбәттә, Ямалтаевны бик нык өйрәтеп җибәрде. Шуның өчен ул, Берлинга килгәч, Габдулла Батталовтан бер генә адым да калмаска тырышты. Редакциягә һәм «Идел-Урал» комитетына аның белән бергә барды. Үзе бик мыштым гына һәм тыйнак кына сыман күренсә дә, Батталның кемнәр белән очрашып, ниләр сөйләшүен һаман күзәтеп йөрде. Шулай да кич белән Баттал, куну йортында аның үзен генә калдырып, Алишлар янына китеп барды. Һәм шунда ул әле берәр атна гына элек Демблиннән кайткан Муса белән очрашып, үзенең ни өчен килүен һәм батальон хәлләрен сөйләп бирде.

— Немецлар бик каты җиңеп баралар икән, безне тиздән шул фронтка җибәрәләр икән, — диде.

Муса аңа ике-өч көн торырга кушты. Курск дугасындагы сугышлар турында совет сводкасын тыңлап, тулырак мәгълүматлар табу, аны «ил хаты» итеп басу, шулай ук батальон солдатларына фронтка китүдән баш тартырга өндәп мөрәҗәгать чыгару өчен шул чама вакыт кирәк булачак иде.

Икенче көнне иртүк оешманың ашыгыч утырышы булды. Симайга тиз арада Информбюро хәбәрләрен булдырырга һәм шуны Алиш белән бергәләп язарга, матрицага алырга, басарга кушылды. Муса өндәмә тексты язуны үзенә алды. Булатов, экскурсияләр өчен һәр төрле белдерүләрне, чакыру билетларын типографиядә үзе хәзерләгән булып, хәреф җыярга ярыйсы ук өйрәнеп килә иде инде. Муса язган өндәмәне, шундый эшләр арасына тыгып, немец надзорының борын төбендә көпәкөндез җыеп, көпә-көндез кул ротациясендә басып алу Гариф белән икесенә тапшырылды.

Әмма бу ашыгыч эшне башкару шактый кыен булып чыкты. Элек ансат кына үтелә торган киртәләрдә хәзер кат-кат төпченүләргә, шикчән карашларга очрарга һәм аларны яңа хәйләләр белән әйләнеп узарга туры килде. Шуның өстенә Курск сугышлары турындагы листовка басыла башлагач кына, Әхмәт Симай яңа хәбәр белән йөгереп керде:

— Безнекеләр, немецларның тәмам тешләрен коеп, Орел һәм Белгород шәһәрләрен азат иткәннәр. Әллә никадәр пленный, трофей! — дип пышылдады ул тыны-көне бетеп. — Бишенче августта Мәскәүдә җиңү салюты! Сугыш тарихында беренче мәртәбә!

«Ил хаты»на бу куанычлы хәбәрне дә кыстырып, яңадан басмыйча мөмкин түгел иде. Шулай итеп, Габдулла Баттал үзенең юаш юлдашы белән алтынчы август иртәсендә генә легионга кайтып китте.

Әмма бу ыгы-зыгылы көннәрдә бүтән адәмнәр дә тик ятмады. Шәфи Алмаз, Карип Ишбулдинны чакырып алып, аның борын төбендә алтын сәгать уйнатты.

— Сиңа, энкәш, шыгырлар китабың өчен нәни генә бүләк, — диде. — Белеп тор Гаптрахман абыеңның яхшылыгын! Бальшәвикләрне каты сүккәнсең, афәрин!.. Әмма мин кушкан эшләрең буенча — җебегән тавык! Һични булдыра алмыйсың. Көтәм! Вә ликин күпме көтәргә?

Карип калтыранган куллары белән сәгатьне әйләндереп-әйләндереп карады. Чыннан да, алтын бугай! Чыннан да, йөри, швейцарски кул сәгате! Унҗиде ташлы, дип язган. Кайчаннан бирле шушындый бер сәгать, алтын пенснэ, велюр эшләпә һәм шәп костюм турында хыяллана иде ул!.. Бәхете бу тар дөньяга гына сыярлык булмаганга, йөгереп урамга чыкты, әлеге автоэчергечтән генә бер-икене төшереп алды да, шатлыгын кем белән уртаклашырга, үзен кая куярга белмичә, Албайнплацка таба юнәлде. Чөнки аның сер бүлешерлек бер генә дусы да, гомумән, беркеме дә юк иде. Хәтта комитетта Мусалар ягына кушылмаган һәм ниндидер бер күләгә сыман гына йөреп гомер уздыручылар да аңардан тайчаналар, аны шымчы дип уйлыйлар иде.

Карип Албайнплацка кайтып төште. Үзеннән алдарак баракка якынлашып килүче Алишны шактый ерактан күреп алды һәм сөенеп куйды: менә хәзер аны тиз-тиз куып җитәсе һәм үзенең бүгенге шатлыгын сөйләп бирәсе, мактанып аласы килде. Ул бит Карипнең элекке дусы, аның шикелле үк партиясез, аның шикелле үк кайчандыр кагылып йөргән кеше. Шулай булгач, ул аны аңлар иде. Бәлки, бергә ресторанга китеп, бераз кәефләнеп тә утырырлар!.. Әмма аның бу изге уйларын усал мыскыл иткән шикелле, Алиш баскыч төбендә дә тукталмады, баракка да кермәде, ә ни өчендер урман эченә таба атлап китте. Карипне күреп юри качты бугай ул чукынмыш! Очрашасы килми, янәсе! Тукта, кая барыр, ни кыланыр, ничек котылыр икән...

Һәм Карип, агачтан агачка поса-поса, аның артыннан китте. Алиш талчыгып эштән кайтучының салпы адымнары белән ашыкмый гына

эчкә таба керә, әледән-әле арт ягына әйләнеп карый, ләкин шик туарлык һични күрми, ахры: юлын тагын дәвам иттерә. Юан агачлар артына сеңгәндәй генә хәрәкәт итүче Карип аны күздән ычкындырмый. Менә Алиш, җирдән бер ботак алды да, ялгыз бер карт каен төбенә чүгәләп, балчыкны казый башлады. Аннары, шактый маташканнан соң, кесәсеннән нәрсәдер чыгарып, шул чокырга салды да күмәргә тотынды. Шул арада тирә-ягына әллә ничә тапкыр карап алды, әмма Карипне барыбер күрмәде...

Ишбулдин күңелендә кинәт әллә ничә төрле гөманнар уйнаклап китте: нишли бу — акча күмәме? Әллә бик кыйммәтле берәр әйбер табып, шуны яшерәме? Әллә... кесә коралы-фәләнме?.. Әллә!..

Ул арада Алиш, үзенең әлеге яшерен эшен бетереп, килгән юлыннан түгел, бөтенләй икенче яклардан әйләнеп, баракка таба юнәлде. «Эз югалта, янәсе!» — дип көлеп калды Карип. Һәм Алиш күздән югалу белән ул үзенең поскан җиреннән чыкты да әлеге каен төбенә ташланды. Биш бармагын тырпайтып комсыз бер хәрәкәт белән кармана башлады. Җир өсте тип-тигез, бер генә кисәк яңа балчык та күренми, һәркайда тигез булып, кипкән яфраклар, мүкләр, үләннәр ята... Кай төштән генә казыды соң ул?.. Һәм Карип, дүрт аяклап үрмәли-үрмәли, шашкан бер кабалану белән эзләнүен дәвам итте. Ниһаять, кармана торгач, бер йомшаграк урын табылды. Өстенә чирәм капланган... Ул тагын да шашыныбрак шул урынны казырга тотынды. Озак та үтмәде, гади типография кәгазьләренә төрелгән бер нәрсә килеп чыкты. Карип аны калтыравык куллары белән тиз-тиз сүтеп карады.

— Я, ходай! — дип, кычкырып пышылдады ул. Кәгазь эчендә дүрт-биш кисәккә ертылган юка гына синтетик матрица ята иде. Карип аны тиз генә яктыга тотып, күздән кичерде һәм, барын да аңлап алгач, яшен тизлегендә метрога, Шәфи Алмаз янына чапты...

Әйе, соңгы листовканың матрицасы иде бу. Фоат, кинәт кенә йөрәк белән авырып, төнге сменага чыга алмады. Ә листовканы тиз өлгертү кирәк иде, Алиш үзе тотынды. Газета полосаларын уку-тикшерү арасында, урлап-урлап шуны басты. Төн буе алҗып беткән баш белән иртәсен чүп-чарларын вентиляция юлына тондырганда, аптырап калды: әндагы һава агымы матрицаны йота алмый иде. Алиш аны тиз генә кәгазьгә төрде дә кесәсенә салды һәм, эштән соң монда алып кайтып, бер этең дә табалмастай итеп урман эченә күмде, тик әнә нәрсә килеп чыкты...

Карип Ишбулдин, авызына зур сөяк кабып, хуҗасы янына чабып кайткан овчарка шикелле, кулындагы әйберсен болгый-болгый, Шәфи Алмаз кабинетына атылып килеп керде.

— Таптым! Ниһаять, сөенче сездән, Гаптрахман абый! — дип кычкырды ул.

Артык тиле сикеренүләрне бик үк өнәп бетерми торган карт сәүдәгәр бер кашын гына күтәрде дә:

— Ни пычагыма шул хәтле акырасың, әллә дөлдел күкәе таптыңмы? — диде.

Карип мондый түбәнсетүдән бик югары кешеләрчә горур адымнар белән аның каршына килде һәм, кулындагы төргәген сүтеп, өстәлгә тезеп салды да бармакларын кире яктан йөртеп укый башлады. Аннары ничек һәм каян тапканын сөйләп бирде.

— Ну, мөртәт малай, молодис икәнсең! — дип мактады Шәфи аны. — Исәнә торгач, тәки өстенә бастың тизәкнең!.. Моның өчен сиңа кара-зәңгәр бостон костюм, менә дигән туфли!..

Шәфи, «апсатар» табигате буенча, шпион түгел, үзенең товары-байлыгы күпме икәнен шундый юллар белән белергә теләүчеләрне дә җене сөйми иде. Әмма милләтнең сәяси хадиме булып киткәч, җасуссыз яшәп

булмавын аңлап алды ул. Шулай да Карипне җирәнү сүзләре кыстырмыйча мактый алмады.

Карип Ишбулдин исә, аның бу мыскыллавын бөтенләй ишетмәгәндәй, мең рәхмәтләр укыды һәм Шәфинең бүртләч тамырлы кул аркасын үбүдән дә тартынмады. Ләкин моның белән генә эш бетмәде әле: аның Алиштан бик нык үч аласы, моңарчы күрсәткән каршылыклары өчен утлы табага бастырасы килә иде. Ул хәзер — җиңүче! Алишның язмышы аның кулында! Тукта, калтырансын, үлсен әле бер...

Һәм Карип әлеге матрицаның бер кисәген алып кесәсенә салды да яңадан Албайнплацка чапты. Алиш почмагына дөбер-шатыр килеп кереп, тумбасы өстенә матрица кисәген ташлады.

Топчанда китап укып яткан җиреннән йокымсырап киткән Алиш моны тоймыйча калды. Тик яңадан шартлап ябылган ишек тавышына гына уянып китте һәм ишектән чыгып баручы Карип шәүләсе күзенә чалынып калды. «Шатунлы шайтан» дип уйлады һәм каядыр кабалангандай, җәһәт кенә урыныннан торды. Шуып идәнгә төшкән китабын тумбочка өстенә алып куйганда әлеге матрица кисәген күрде. Кинәт кай җирендәдер ут капкандай як-ягына карады. Аның шунда ук бөтен чырае көл кук булды, матрица кисәген алырга сузылган кулы калтырана, иреннәре дерелди башлады.

— Син?.. — дип ыңгыраште ул. — Сволочь икәнсең!..

Абдулла, шактый вакыт урынында чайкалып торды-торды да, ишеккә ташланып, урманга йөгерде. Актарылган балчыкны күргәч, йөзтүбән җиргә капланды һәм ыңгыраша-ыңгыраша үксергә тотынды.

— Ах, йөзекара, йөзекара! Бетерде бит... Кая булды соң минем күзләрем!

## VII

Мәмүт Ямалтаев, Берлинда Габдулла Батталовны күпме генә каравыллап, үзенчә бик сизгер булып йөрмәсен, барыбер һичнәрсә белә алмады. Аның кәефе бер дә шәп түгел иде. Менә ике ай була инде, ул һаман пропагандистлар һәм музыкантлар арасында буталып йөри, әмма бер генә сер дә урлый алганы юк. Шулай итеп, менә Берлиннан да буш кул белән кайтып килә ул. Ә фельдфебель Блокк тагын аның якасына ябышачак. Нинди елан юллары белән боларның эчләренә керергә соң?..

Алар, ут белән су шикелле, ике дошман, кара-каршы утырып вагонда кайталар. Газеталар тутырылган чемодан тәрәзә турындагы бәләкәй өстәлгә утыртылган. Ачык тәрәзәдән бәргән җилне кимәтү өчендер, күрәсең. Күңелендә һич начар уй булмаган, беркатлы һәм шаян холыклы Габдулла үз каршында үзенең газраиле утырып кайтуын, әлбәттә, белми. Киресенчә, ул аны дус күрә һәм үз күрә булса кирәк әле: әйбәт сүзләр сөйли, Мәмүтне үз ягына аударырга тырыша, туган илне онытмаска, совет солдаты исеменә тап төшермәскә өнди. Аннары, башын югары күтәреп, Такташның «Киләчәккә хатлар»ын укып җибәрә. «Башларыннан инде сез яшәгән коммунизм кыры күренә!» — дигәннән соң, «Эх, шәп язган иде бит! — дип куя. Аннары укып бетергәч, тагын яңаларына күчә. «Кичер, илем», «Ирек», «Сандугач һәм чишмә» дигәннәре, сугыш һәм әсирлек турында язылгангамы, бигрәк тә йөрәккә үтә. Кайчандыр шундыйрак сыман тойгылар Ямалтаевта да булып узган иде бит. Хәзер инде алардан эз дә калмаган. Мәмүт бу шигырьләрнең кемнеке икәнен сорап карый, ләкин Габдулла мәгънәле елмаеп бер күзен генә кыса. Сабыр ит, янәсе, башың яшь...

Мәмүт Ямалтаев юлдашының сүзен тәүфикъ белән генә тыңлап бара. Аның сүзләренә каршы җавап бирми. Һәм каршы килерлек тә түгел, чөнки ул дөрес сөйли, хакыйкатьне әйтә. Шулай булгач, Ямал-

таевка үзенең кара битлеген салырга да елый-елый тәүбә итәргә: «Мин синең башыңны ашарга йөрим, дус кеше, изеп ташла, үтер син мине, яки кичер син мине! Кичерсәң — иң тугры дустың булырмын!» — диярга иде. Ник әйтми соң ул шушы сүзләрне? Нәрсә комачау итә? Мәмүт тә кайчандыр комсомол булган кеше бит. Ник йөрәген ачып сала алмый ул бу саф күңелле кеше алдында?..

Юк шул, булмый. Мөмкин түгел. Соң инде, бик соң! Аның аркасындагы җинаять йөкләре артык күп, артык авыр шул хәзер. Бер генә түгел, берничә тегермән ташыдай, аңа кыймылдарга да ирек бирмичә, басып торалар. Ул әшәкелекләрнең береннән дә тайчанмады, аңа хәтта фашист кулы белән медаль дә тактылар. Менә шулай булгач, хәзер мең тәүбәләр итеп, мең төрле яхшылыклар эшләсәң дә, ул пычракларны юып ташлау мөмкин түгел инде. Алар кайчан да булса бер вакытны барыбер беленәчәкләр һәм барыбер Мәмүткә тиешле җәзасын бирәчәкләр. Беткән баш — беткән инде, күперләр яндырылган, басмалар сүтелгән — үлгәннән соң тәүбә юк...

Ә Габдулла үзенең Мәмүт өчен һич кенә дә кирәге булмаган әйбәт сүзләрен дәвам иттерә:

— Моңайма, егет, салма башыңны, менә бергәләп туган илләргә кайтырбыз, — ди ул. — Дус булып кунакка йөрешербез. Син безнең Биләргә килерсең. Тигәнәлене, Казанны күрерсең, алар дөньяда ике генә шәһәр! — дип көлдергән була.

Мәмүт Ямалтаев тулысынча аңа ышанган һәм кушылган кеше булып кылана. Сүзләрен җөпләгәндәй итә. Ләкин эчтән нервысы кайный, түземлеге җитми: ник һаман суган суы сата, ник төп серен ачып бирми?..

Габдулла, әлбәттә моны сизмәде, киресенчә, егетне тәмам «эшкәртеп», үз ягыма аудардым дигән фикергә килде. Чөнки Мәмүт гел якты чырай күрсәтеп, гел аның сүзләрен куәтләп кенә кайтты, шуңа күрә Габдулла озакламый бу егетне үз араларына кертү мөмкин булачагы хакында уйлап куйды. Әлекке Ямалтаев өчен кирәкле сер аның авызыннан һаман ычкынмады әле! Хәтта чемоданда нәрсәләр кайтканын да белә алмады Мәмүт. Чөнки аңа Габдулла хуҗа иде. Шуның өстенә ул аны вагонга кергән саен тәрәзә каршындагы өстәлгә утыртып куя да оныта. Ачык тәрәзәдән төшеп китәр дип тә курыкмый. Күрәсең, анда Шәфи Алмаз чыгара торган газетадан башка һичбер кадерле нәрсә юктыр...

Ә Габдулланың ул чемоданны юри тәрәзә каршына куюы һәм, андый-мондый тентү була калса, тиз генә төртеп төшерәчәге Мәмүт Ямалтаевка, әлбәттә, билгеле түгел иде.

Алар шулай Едлинога кайтып җиттеләр. Ә кайтып җиткәч инде, газеталар арасында булган «Ил хатлары»н тараткачы кайда яшереп тору мәсьәләсе килеп чыкты. Алар клубта Гайнан Кормаш бүлмәсендә өчәү генә иделәр.

— Иләренә җиткергәнче, боларны кая куеп торабыз соң? — диде Габдулла елмаеп. — Анда бик интересный хәбәрләр бар. Орел, Белгород... Мәскәүдә беренче салют!

Гайнан күзләрен зур ачып, Батталга, аннары Ямалтаевка карады, иреннәрен нык йомып, чыраена аңламау төсе чыгарды.

— Ничава, — дип куйды Баттал, үзенең төкәнмәс шаян тавышы белән,— мин инде аны юл буе эшкәртеп кайттым. Мәмүт начар егет сыман күренми.

Кормаш та аны байтактан бирле күзәтеп йөри һәм урыны килгән саен кылын тарткалап карый, ә егет ничек тә гел уңай тәэсир калдыра кебек иде. Шуңа күрә Батталның бу сүзләренә Кормаш та каршы төшмәде, ә туп-туры Мәмүткә сорау куйды:

— Әйт, Ямалтаев, сатарсыңмы безне?

Мәмүтнең күзләре акайды, төсе агарды. Ул гаҗәпләнгән һәм шундый әшәкелектән җаны-тәне белән курыккан кеше булып күренде.

— Ни сөйлисез, Кормаш абый, үз кешеләребезнеме? — диде ул, тыңкыш тавышы белән. — Ике күзем чәчрәп чыксын менә!

Саф күңелле Гайнан да, Габдулла да ышанмыйча булдыра алмадылар, тик йөрәкләрен генә нидер тырнап куйды. Шулай да күп уйланырга ара аз иде, таратыр көн килгәнче, кая яшереп торырга? Башка вакыт Фәритев үзе таба иде урынны, ә бүген ул юк...

Мәмүт хәзер инде тыңлап торучы гына түгел, киңәш бирүче дә булып китте.

— Ә үзебезнең һәм якын иптәшләрнең матрас эчләренә, салам, стружка арасына тыгып торсак? — диде ул. — Капшанучы була калса, салам да, кәгазь дә бердәй шыштырдый.

Бу тәкъдим ярыйсы булып күренде. Шулай да Гайнан уйланып торды, күңеленнән башка урын, башка мөмкинлек эзләп карады, ләкин тапмады, тизрәк берәр җиргә урнаштыру кирәк иде аларны. Бәлки иртәгә Фәритев үзе кайтып җитмәсме, бәлки бүген төндә ук урманга күчерергә мөмкин булмасмы?.. Әмма хәзергә бүтән хәвефсез урын күренмәде. Һәм алар, шунда ук кеше саен илле-алтмыш листовка бүлеп, үз матраслары эченә алып кереп яшерделәр. Калтанын икегә аерып Зиннәт Хәсәнев белән Сәйфелмөлекев матрасларына тыктылар. Шушы эш арасында ук Кормаш, үзләренең яшерен көрәшләрен кыскача гына аңлатып, Мәмүтне ант иттерде.

— Син безнең оешма члены хәзер. Изге көрәштә җаныңны аямаска һәм иптәшләреңне сатмаска ант ит! — диде.

Ямалтаев калтырана-калтырана ант итте. Шуннан соң алар үз эшләренә таралыштылар. Мәмүт исә төнне ничек җиткерергә белмәде. Юк, сөю сагышлары тилмертмәде аны, егерме яшьлек егет Мәмүт Ямалтаевка мәхәббәт шикелле изге хисләр таныш түгел иде. Ул — төн уртасында гестапо агенты Ясәви Ихсанов белән һәм фельдфебель белән кавышуны көтә иде.

Менә аның ул минутлары килеп тә җитте: төнге беренчедә гадәттәгечә «теше сызлый» башлады, һәм Мәмүт эчке күлмәк-штаннан килеш кенә итекләрен киде дә тешен тотып сызлана-сызлана чыгып йөгерде. Ә бер данә листовка алдан ук итек кунычына яшерелгән иде инде!

Утын сүндерсә дә йокламый яткан Ясәви янына керде. «Ай, тешем, авырта минем тешем!» — дип кычкырды. Аңа каршы тегесе: «Авыртса синең тешең, анда минем ни эшем?» — дип җавап бирде.

— Булды! — диде Мәмүт, күзлеге аркылы да шашкын елтыравы бәреп торган сары-яшел бәбәкләрен уйнатып. — Булды! — Һәм ике сүздә Ясәвигә хәлне аңлатып бирде. Ясәви аны Блокк хөҗрәсенә алып китте. Анда кергәч, Мәмүт итек эченә яшерелгән листовканы чыгарып, Блокк кулына сузды һәм вакыйганы сөйләп бирде.

Моңарчы фельдфебель әфәнденең күпме башын катырган, күпме шелтәләргә, күпме күңелсезлекләргә дучар иткән һәм хәтта аның карьерасын сындыра язган бу нәләт төеннең кинәт шушылай ансат кына чишелеп китүе ис-акыл киткеч бер хәл иде. Фельдфебель хәтта Ямалтаевның авызына карап катты, калай күзләре йөрмәс булды. Байтактан соң гына аңына килеп, листовканы әйләндергәләп карады, андагы латин хәрефләреннән сүзләр җыярга тырышты, ләкин бернәрсә дә аңламагач, Ихсановка сузды. Ул исә, ярты-йорты пупалап, листовканың эчтәлеген түрәсенә әйтеп бирде.

— Ярар, — диде Блокк. — Кайтыгыз. Хәзергә бөтен кәгазьләр үз урыннарында торсын. Әгәр башка урынга күчерә яки солдат арасында тарата калсалар, миңа алдан хәбәр итәрсең. Син хәзер оешманың ак-

тивы бит. Шулай булгач, сиңа мәгълүм булмый калмас. Ә мин Берлин белән хәбәрләшим.

Мәмүт белән Ясәви чыгып киттеләр. Фельдшер, Мәмүтнең авыртмаган тешен дарулап, хәтта яңагына сары кәгазьле бәйләвеч тә салып җибәрде. Фельдфебель исә төн буе радиоаппарат яныннан китмәде. Яшерен код цифрлары өзлексез шыкылдый торды. Таңнан ук әлеге листовка махсус фельдпочта белән Берлинга озатылды. Анда аны юка синтетик матрица кисәкләре белән чагыштырып карадылар. Әчтәлектә аерма булмады, хәреф рәвешләре бер төсле иде. Шуңар күрә матрицаның «Винета» бүлегендәге машинкада сугылуын, ферлагтагы кул ротациясендә күбәйтелүен һәм кемнәр тарафыннан эшләнүен ачыклау гестапочылар өчен артык кыен булып чыкмады. Бөтен план тиз арада хәзерләнеп бетте һәм «операция» көне билгеләнде...

## VIII

Алдан сөйләшеп билгеләнгән көнне Муса юлга чыкты. Берлиндагы иптәшләре аңардан ике көн соңрак кузгалырга тиеш иде. Кичә генә нинди кояшлы, матур һәм җылы булган көн бүген шундый ямьсез һәм, Балтик өсләреннән килгән томан белән томаланып, инә күзедәй вак кына яңгыр сибәли иде. Ул, кара эшләпә киеп, плащының яка төймәсеннән генә эләктергән һәм кулына әлеге үзеннән калмый торган чемоданын тоткан килеш, Варшава вокзалына килеп төште. Әллә кайчан җимерелгән элекке вокзалның инде үз төсен җуя башлаган ватык кирпеч өемнәре, тутыгып яткан кәкре-бөкре тимер-томыр кисәкләре, шуларның бер читенә акбурлы такталардан гына тиф барагы сыман итеп корамаланган вакытлы вокзалның авыр карболка исе аңкытып торуы һәм шуңа мазут, күмер төтене исләре кушылуы белән бүген бигрәк тә иләмсез күренә иде. Радом поездына утырыр өчен бер платформадан икенчесенә күчкәндә, ни өчендер бу йөз тапкыр күрелгән нәрсәләр һәммәсе дә аның күзенә яңадан чалынды. Известь, тимер-томыр катыш ала-кола төстәге ул өемнәр яңгырда чыланып, җансыз таркалып ятулары белән нинди үлгән шәһәр хәрабәсен хәтерләтәләр, шул ук вакытта бу урында кайчандыр тормыш кайнап торуын да искә төшерәләр һәм, ихтимал, шуның өчен дәдер, аерата моңсу, йөрәк кимергеч сагышлы, хәсрәтле булып күренәләр иде. Составны платформага бирергә ун минут бар әле. Шушы сәяккә үтә торган шыксыз вак яңгыр астында шуңарчы торырга кирәк. Мусаның аргы баштагы вокзалга барып торасы килми, озак түгел бит, әрле-бирле йөрүе генә калыр, әйдә, плащы үткәрмәс әле. Ә состав бирүләре белән — вагонга чумар...

Юеш перрон өсте тып-тын, хәтта үле диярлек. Анда-санда хәрби немецлар гына узгалый. Алар да әз бүген, көн эшәке булгангадыр инде. Әнә ике «СС» козгыны да йөреп яткан була. Бүтән немецларның башы бу араларда тагын салына башласа да, болары сер сиздерми әле: башлары, озын казык очына элгән чүлмәк шикелле, туры тора, түшне дә тәгәрмәч итеп тоталар. Янәсе, Германиянең тоткасы, җирнең кендеге алар!..

*(Дәвамы бар)*



## З. Маликов

*Язасы килә! Яшәгән саен, тормышның катлаулылыгы күбрәк аңлашыла барган саен язасы килә! Назыйм Хикмәт, Һади Такташлар кебек...*

*Заман тирән эчтәлекле, кешелекле хисле шигырьләр таләп итә. Шуңа күрә янарга, эзләнергә; язган әйберләрнең укучы күңеленә барып җиту-җитмәү турында җитди уйланырга кирәк.*

*Күңел хисләр белән тулган минутларда мин каләмгә ябышам. Ә күңелнең төрле чагы була: сагыш та, шатлык та, соклану да били аны...*

*Миңа 18 яшь. Университетка керергә ниятем бар.*

### Дауларга телим

Балачакта тормыш—
шәп әкият;
Балачакта хыял—
аргамак, —
Биек үрләр, кыя таулар үтеп,
Еракларга алып барган ат!

Тирән хисләр әле яңа туа,
Бәхеткә дә шулар китерә—
Балачакта туган шашкын уйлар
Биеклеккә сине күтәрә.

Кеше гомере — гасырларга тузан...
Тормыш сукмаклары — тауларда!
Балачакта туган хыялларны
Киләчәктән телим дауларга!

### Әйтче

Агымсуга күзең текәп
Ни уйлыйсың, әйтче миңа—
Агымсуда ни югалттың,
Ни җуйдың соң, әйтче миңа?

Ни сөйли сиңа дулкыннар—
Ник соң моңлы тавышлары?
Иелеп нәрсә пышылдыйлар
Яр буеның камышлары?..

Тал-тирәккә башың салып
Нинди уйга чумдың әле—
Кая синең шат җырларың—
Бүген нигә тындың әле?

Тормыш дулкыннары сине
Яр буена какты мәллә?—
Сөйгәнеңә ышанычың
Дулкыннарда акты мәллә?..

## Упкын янында

Җайдак оча чапкын ат өстендә,
Атның ялы биткә сугыла—
Буйсынмаска теләп җил иркенә,
Җиңел гәүдә алга сыгыла.

Тигез җирдән оча җитез чапкын,
Артта кала юлда барсы да,
Күз ташлый да кинәт җайдак алга—
Тирән упкын күрә каршыда!

Тугры аты туктап каушап кала...
Каула тизрәк, егет, атыңны!
...Тик үтмәде аты упкын аша,
Һәм упкынга егет атылды...

Аты юлдаш иде,
Тик упкынга
Егет төште, аты төшмәде—
Таш кыялар үтеп яңгырады
Ялгыз атның шомлы кешнәве...

Якын дуска сине исәпләдем,
Яшьлегемнең тәүге таңында,
Син нишләрсең,
Икәү бергә шулай
Упкыннарны кичкән чагында?!

## Шаян таң җиленә

Чәчәкләрнең исен җилләр
Таратып бетерәме?—
Яз исен җилләр китерә,
Сөю дә китерәме?
Әй, таң җиле!
Сөю бирсәң,
Булмасын хуш ис кебек
Җилгә очып таралырдай,
Юкка чыгардай эреп!
Син беләсең чәчәкләрнең

Исе бетеп корганын—
Беләсеңме исе, төсе
Мәңге бетми торганын?..
Сөю бирсәң, шул чәчәктәй
Мәңгелеген бир миңа—
Мәңге шатлык, мәңге рәхәт
Бәхет алып кил миңа.

## Сагыныр чак

Кояш чыгар әле тагын,
Болытлар үтәр әле;
Күңелдә тик бер хыял бар:
«Онытмас—көтәр әле...»

Еллар белән юллар гына
Аера, сагындыра:
Сагыну—сөю юлдашы,
Сагыныр чагың гына!

...Кояш чыгар әле тагын,
Болытлар үтәр әле—
Еллар тагын очраштырса,
Сагыну бетәр әле!

Сагын әйдә—
Сагынулар
Яшәтә сөю хисен:
Оныта алмас ул сине
Сагына белгән өчен!

## Аңа әйтер сүз таптым...

Елатты язмыш егетне—
Чын йөрәктән юаттым,
Кайгы юшкынын юарга
Мин җылы сүзләр таптым!

Язмыш түгел, тормыш аны
Баш идереп елаткан—
Яңакларын яшь чылаткан:
Ул әнисен югалткан...

Күзләреннән яшен сөрттем,
Сүзләр күп табылдылар:
Күңел бит ул нечкә нәрсә—
Хисләрем агылдылар...

Күңел тыңлады җанымның
Иркәләп әйткән сүзен;
Елаучы, юатучы да—
Икесе дә мин үзем!..



# Рөстәм Мингалимов

*Мин 1937 елда Куйбышев өлкәсенең Камышлы районы Йолдыз авылында туганмын. Малай чакта ук шигырьләр белән дуслаштым һәм үзем дә яза башладым.*

*7 класста укыганда шагыйрь Әнвәр Давыдов белән очраша башладым. Ул миңа шагыйрь һәм дөнья турында гаҗәп матур итеп, шул чаклы күп сөйләде ки, мин шигырьләрне артык нык ярата да, шигырьләрдән артык нык курка да торган булып калдым. Күбрәк уйлый, азрак яза башладым. Авыл хуҗалыгы училищесына укырга кердем.*

*Училищены тәмамлап, тормышның эченәрәк талпындым. Чирәм җирләр... Заводлар... Шәһәрләр... Бөгелмә. Кечке унны тәмамладым. Ниһаять — Казан, ВУЗ. Язам. Укыйм. Күп шагыйрьләрне яратам. Күп шагыйрьләрне яратмыйм: чүпрәкче арбасында яткан ящиктагы сыбызгы, уймак, энә-җеп һәм шуңа охшаш башка вак-төяк сыман булмасыннар иде шигырьләр. Язасы иде, колхозчы кебек — гади; кешелек үсеше кебек — катлаулы; бүгенге революцияләр юнәлеше кебек — ачык; дөнья халкын катастрофадан саклау нияте белән речь тоткан дипломатлар пульсы төсле тыйнак һәм көчле тибеп торган шигырьләр язасы иде.*

## Минем яшьлек

Яшьлек елларымны,
сарут белән бутап,
аттым
яшел эскерт өстенә,
буразнага салдым,—
кыр тутырып
эре башак булып үстеләр;
кайсыларын
асфальт белән кушып
олы юлга җәеп калдырдым.
Кайсыларын
корыч эреткәндә яндырдым,
төтен булып
биек торбалардан чыктылар...
Һаман елларымны чакырам:
Саклармын,— дим,—
Җил дә тигезмәм.
Үзләрен,
тимер-бетон белән аралаш,
урнаштырам яңа нигезгә.
Мәһабәт йорт
калкыр бик тиздән.
Безгә төбәп куйган
ракеталар
җиргә иңеп керер
куркудан.
Ак этажлар түбәсендә,
ал байракка сеңгән
минем яшьлек
калыр
дулкынлап.

# Иделдә

Әллә көнләштерергәме, иркәм, уең?
Күлмәгеңне яр өстенә куеп,
кояш нурларына төренгәнсең,
якты бер дулкыннан
хасил булган төсле күренәсең.
Идел үбә тезләреңне.

Идел
керфекләрең белән шаяра,
Кара кашларыңа кагыла,
кайнар күкрәгеңдә тирбәлә,
чәчләреңнең сары бөҗралары белән
каплый күзләреңне.

Көнләшмим, көнләшмим, беләм бит:
дөньяны,
йолдызларга атылган яшьлекне
ничек сөйсәң,
мине дә шулай сөясең.
Диңгез һавасы кебек саф
сүзләр пышылдаган иренең—
миңа гомерем бәясе.
Кына тигән ун тырнагың—
ун кояшым минем.

Мин соң
җирдәге һәр кызга, һәр егеткә
шундый бәхет бүләк итмәс идемме?!
Көнләшмим.
Җимерелмәс дуслык,
таш калалар тудыра белгән
йомшак кулларың белән
кочакла, кечкенәм, зур Иделне.

# Әткәйгә

Кырык беренче елда,
чыкканда капканы,
әйткәнсең:
— Кайтырмын...
Биш ел үтте—
Кайтмадың.
Ун. Унбиш.
Егерме...
Улларың өлгерде—
Сәламең-хатың юк.
Бездә
бары
саргайган документ—
«Хәбәрсез югалды».
Бүген
шуңа,
басылган җилсыман,

тын калдым:
Уйланам.
Эзләнәм—
күренми исемең
мәрмәр тактада.
Юк китапта да,
Монда да,
Монда да юк.
Кайда соң?!
Эндәшми җир өсте.
Син
укылмыйча югалган
кыйммәтле
хат төсле.
Йөрәк тоя
аның
матур эчтәлеген.
Көнем,
кояшым—
миңа истәлеген.

## Кирәк идең

Әлемтә бүлеге
Шырпы кабы шикелле,
Яңа хәбәр тәэсиреннән
Гөжләп кабынып йөрәкләр белән
Шыгрым тулы.
Ун минуттан җиде тула.
Очрашабыз,
Үткәргечләр аша очрашабыз бүген...
Белмим, нәрсә була?
Артык сагындым шул үзеңне.
Яңа уздырган минутым—
резина,
ел булып сузылган шикелле тоелды.
Бәлки...
Анда...
Очрашу сәгатен җиткерү
сиңа да кыендыр.
Бәлки син дә шулай сагынгансыңдыр.
«Алмагачым», дисәм,
— Алмам,—дигән чагың бар иде.
— Синнән башка торалмам—
дигән чагың бар иде.
Бәлки үкенәсеңдер
Минем белән китмәвеңә,
Китүем өчен ачулануыңа,
ун хатыма
бер хат—
шундый җавап язып
миннән үч алуыңа.
Ышанмадым хатыңа.
Ышанмадым сүзләреңә.

Мөмкинме соң
йөрәк
афишадай үзгәрергә?!
Кил,
ярдәмгә кил дип, күпме яздым,
Көчсезлектән түгел, иркәм,
ир күтәргән йөкне күтәрә ала җилкәм,
тик син миңа кирәк идең.
Әсирлектән качарга җыенган солдатка
төн кирәк булган кебек
кирәк идең...
Хәзер
безне сөйләштерәчәк үткәргечләрнең
берсенә
икенчесе кирәк булган кебек
кирәк идең...
Рәхмәт... сөйләшергә чакыргансың...
Белмим. Нәрсә була?
Бер минуттан җиде тула.
Булды...
Урамга чәчрәдем
шырпы кабыннан.
Баганалардагы үткәргечләргә дә—
сүзләреңне миңа җиткергән үткәргечләргә
дә
авырдыр, салкындыр күрәсең:
алар салынган,
аларга бозлар туңган,
бозлар туңган...
Ә син миңа ничек кирәк идең?!

## Казан аэропортында

*(ВУЗ тәмамлап эшкә китүче иптәшләрне озату уңае белән)*

— Югалтышмабыз диделәр.
Винтлар гүләве,
аэропорт ыгы-зыгысы,
Казан шавы,
бөтен Татарстан тавышы...

Ә шулай да миңа
саубуллашу сүзләре
ачык җитә.
Бергә укыган дуслар китә
ВУЗлар китә,
Казан китә...

Аларсыз... мин нәрсә?
Гомеремдә бер тапкыр да
кызлар елмаюы күрмәскә
хөкем ителгән егет кебек
калыр идем.
Бер тирәдә тугангамы шулай? Юк.
Бер ВУЗда укыгангамы? Юк.
Милләттәшләр булгангамы? Юк.
Әмма алар миңа тиңсез кыйммәт.

— Югалтышмабыз,— диделәр.
Китәләр...

...Самолет
ак канатлары белән
карашыма таянган:
«Дусларны күтәрәм,
ВУЗларны күтәрәм,
Казанны күтәрәм
кадерләп, сак кына,
дөньяга күрсәтер өчен...»

— Югалтышмабыз,— диделәр.

## М. Садыйков



*1934 ел. Май. Кун авылы. Әнкәй мине колхоз басуында язгы буразнада тудырган.*

*Балачагым — сугыш еллары. Җәен — колхозда ындыр каравылчысы, басу сакчысы, кышын — укучы. Үсмер чакта — бригадир ярдәмчесе, монтер, урман кисүче, чаер агызучы, каравылчы, торф чыгаручы.*

*Аннан армия, мәктәп, пединститут.*

*Әдәбият белән яшьтән кызыксынам. Поэзия юлларыннан гади бер солдат булып атлыйсы иде!*

## Туган тел

Йөреп чыктым ярты Европаны,
Күреп кайттым Гейне илен дә.
Европада аккан чишмәләр дә
Сөйли кебек Тукай телендә.
Дунай буйларында үскән таллар
Әллә инде миңа якташмы?!.
Болгар урманының усаклары
Җырын җырлый кебек Такташның.

Татарча өн алып килә җилләр
Иссәләр дә миңа һәр яктан,—
Туган телем, камыш бишектән үк
Мин бит сине шулай яраткан.
Туган илдә миңа каеннар да
Татарчалап сәлам бирәләр,
Шушы телдә бөтен йөрәгемне
Илне сөю хисе биләгән.

Тел ачканмын шушы нәфис телдә,
Тәүге кабат очына-очына.
Шушы телдә соңгы сүзләрем дә
Тибрәр салкын иренем очында.

# Урал корычы

Ул — танклар булып үрмәләгән,
Снарядлар булып очкан да,
Катюшалар булып, җир тетрәтеп,
Үлем алып килгән дошманга.

Үлем генә алып килми корыч,
Яшәртә дә җирнең тормышын.
Тыныч чорда Польша кырларында
Очраттым мин Урал корычын.

Юл читендә басып туктап калдым,
Басу буйлап таныш җыр акты:
Бураэналар ярып кыр түреннән
Менеп килә таныш трактор.

Мотор җырлый-җырлый Татарстан
Нефте исен килә таратып.
«Уралсталь» койган сабаннарның
Күзгә кебек уйный канаты.

Алар окопларны гына түгел
Сугышны да гүя күмгәннәр,
Иркен сулый шуңа яшәүчеләр,
Тыныч ята шуңа үлгәннәр.

# Шагыйрь үлми

*Ф. Кәримгә*

Мин Балтика ярларыннан узам,
Көнбатышка атлыйм.
Фатих Кәрим узган юллар бит бу,
Эзлим — үзен тапмыйм:

Кичке офык шагыйрь тәнендәге
Бинтлы яра сыман.
Килеп чыгар кебек янгын булып
Болыт арасыннан.

Балтик ярларына башын куеп
Шагыйрь йоклый микән,
Ай нурында утырып җыр язамы,
Я хат укый микән?!

Шагыйрь күңеле Балтик диңгезедәй
Дулкынлана микән,
Үткән яу юлларын искә алып
Илһамлана микән?

Шагыйрь үлде диеп кем дә әйтми,
Шагыйрь үлми, исән!
Үлемсезлек чишмәсенә ятып
Яшәү суын эчкән.

Җырга сыймый калган уй-хисләрен
Җилләр көйли сыман,
Язылмыйча калган шигырьләрен
Гөлләр сөйли сыман.

Кайда йөри икән, кайда йөри
Кайтмый бу көнгәчә.
Узылмаган озын юлы ята —
Илгә, Иделгәчә.

## Көзге бакчада

Тирән моңга чумган бакча эче.
Арган мәллә кошлар сайрашып?!
Саргаешкан агач яфраклары
Коелалар җиргә шып та шып.

Көзне көтеп каен кызлары да
Түшен ачкан җилләр иркенә.
Карт топольдә әнә соңгы яфрак
Яшәп калыйм диеп тилпенә.

Туган яклар белән саубуллашып
Җылы якка кошлар очканда,
Агач яфраклары бөтерелә
Иярергә теләп кошларга.

## Кич килде

Кич җил булып болыннарга,
Кырларга тынын өрде.
Көтүче яккан учактай
Кызарып кояш сүнде.

Йокы кунды чәчәкләрнең,
Гөлләрнең керфегенә.
Тирбәлеп тынды табигать
Сабыйлар төсле генә.

Бала йоклаткан анадай
Ай җиргә карап тора.
Тракторчы кичке кырда
Җиргә юрганнар сыра.

## Фаил Шәфигуллин



*Туган елым: 1939 ел. Май.*
*Туган урыным: Норлат районы.*
*Эш урыннарым: колхоз кырлары,*
*Чирәм җирләр,*
*Пермь урманнары,*
*Находка төзелешләре,*
*Ерак Көнчыгыш*
*һәм Төньяк диңгезләре,*
*Тын океан...*
*Профессиям: Тракторчы, слесарь,*
*балыкчы, урман кисүче*
*һәм башкалар.*

*Хәзер Зеленодольск шәһәрендә яшим, заводта эшлим, кич укыйм. Завод, район, өлкә һәм шәһәр газеталарында басылам.*

*Хәзер поэзия һәм проза магнит кырлары арасында тартышам. Кайсы җиңәр? Әлегә билгесез.*

## Гомер

Кыштыр-кыштыр... менә кызык... булдыра бит —
Ак кәгазьдә кәкре-бөкре юллар кала...
Зурлар өйдә юк чагында юри генә,
Уйнап кына кулына каләм алган бала.

Вакыт уза метеор кебек, яшен кебек,
Еллар ай күк, айлар көн күк тоела аңа.
Төне-көне йөзә уйлар диңгезендә,
Уйнап кына кулына каләм алган бала.

Яшь кәләшкә күңелсездер: кайчагында
Театрга, киноларга ялгыз бара... —
Дала, таулар, рудникларда нидер эзли
Уйнап кына кулына каләм алган бала.

Кешеләр өчен кызганмый ул саулыгын да,
Кирәк булса йөрәген дә утка сала.
Ак кәгазьдәй ап-ак чәчле кеше инде
Уйнап кына кулына каләм алган бала.

## Карт чыршы

Юатса да аны язгы давыл,
поезд үткән саен сыкрана ул.
Дер-дер килә, гүя үксеп елый,
әйтерсең лә сагышы эченә сыймый.
Поезд үткәч, башын иеп гүя,
шпалларга: «Балаларым», — дия, —
йөкләрегез бигрәк авыр инде,
эх, куялсам иде үз иңемне!

## Шәфкать туташы

Нишләптер сынган да төз нарат
таянган ак каен иңенә.
Урман тын. Нәрсәдер әйтергә
ымсына бары тик җил генә.
Әйтергә телидер, ахры, ул:
«Карагыз, күрегез: ут аша
яралы солдатны кочаклап
чыккан ич бер шәфкать туташы».

## Бер уч печән

Юлдан олау узды.
Шул олаудан
Бер уч печән алып иснәдем.
Исерттеме әллә бер уч печән?
Нишләдем мин,
Тукта,
Нишләдем?

Ак чәчәктәй балкып тагын килден,
Ак алъяпкыч сиңа килешә,
Болын гүя дәртле сабан туе —
Тальян чыңлый, кызлар көлешә.
Печән төсле яшькелт күзләреңдә
Әйтеп булмый торган матурлык.
Шул көнне без иң беренче тапкыр
Иңне иңгә куеп утырдык.
Тәүге канат,
Ах, шул канатларда
Баскан җирне тоймый йөрүләр...
Кулларыңнан алып сөяргә дә
Ник кыймадым икән мин юләр.

Юлдан олау узды,
Шул олаудан
Бер уч печән алып иснәдем.
Менә хәзер,
Әле яңа гына
Бөреләнде гүя хисләрем.

# Хәниф Хөснуллин



●

*Саран гомер сәгате утызны сукты. Аның дистәдән артыгына туган авылым Шәңгәлче шаһит, өчесенә — Алабуга китапханә техникумы, тагын өчесенә — хәрби хезмәт, бишесенә — Казан педагогия институты, икесенә — Чаллы районы Бикләп урта мәктәбе.*

*Үткәннәргә борылып карасам, еракта, кулына чыбык тотып көтү каршылаган, сөзгеч белән балык сөзеп, инеш куентыкларына тынгылык бирмәгән малай чагым күренә. Якында — иптәшләргә, дусларга бай булган, бәхәсләргә мул булган Казан еллары.*

*Уку белән бергәттән, Казанда авыр атлетика белән шөгыльләнә идем. Дөрес, мастерлыкка барып җитә алмадым. Икенче разряд тирәсендә чуалдым. Шул ук Казанда әдәбиятка мәхәббәтем тирәнәйде, көчәйде. Хәтта, шигырь төсенә кереп, газета-журнал битләрендә урын алгалады. Иҗат эше авыр атлетикадан авыррак. Ничәнче разряд нәтиҗәләре күрсәтермен? Мастерлык еракмы? Эзләнәм.*

## Хәтер

**Хәтерләр**
**үтә күренмәле.**
**Хәтерләр**
**күңел түрендә әле.**
**Таныш биш елны бер итеп,**
**Әнә берсе,**
**Искә алуымны тора көтеп.**
**Үзендә—әти тавышы,**
**Үзендә—абый тавышы.**
**Әнә берсе.**
**Капчык асып үсмер бала**
**Болын юлы буйлап бара,**
**балтырган,**
**юа җыярга.**
**Арып-талып, көчкә-көчкә**
**Өенә кайтып җитә кичкә.**
**Анысы — мин.**
**Ә тегесе —**
**Кечкенә гәүдәле хатын**
**Укый иренең соңгы хатын.**
**Ул — әнием. Гаҗәп кеше.**
**Ачы хәбәр, зур югалту**
**Меңәр атмосфера белән**
**басым ясый йөрәгенә.**
**Ул һаман да түзә белә.**
**Гаҗәп кеше.**
**Түземлек дигән нәрсә ул,**
**Ахры, минем әни төсле...**
**Мәктәпне тәмамлаган ел,**
**Сөеклемне күрер өчен**
**Күрше авылга озаткан юл,**

Мине якыннары күреп,
Күрешәләр куллар биреп:
— Исәнмесез, исәнмесез!
Я, егеткәй,
Хәлең ничек?
Җавап бирәм:
— Бик шәп,
бик шәп.
Еллар тыныч.
Мондый шартта
Гел бишлегә була яшәп.
— Дөрес,—ди абый тавышы,
— Дөрес,— ди әти тавышы
Артта калган еллар аша.

## Авыллар керә

Авыллар керә шигырьгә,
Җимереп сүзләр биген.
Түрдән үз урынын ала
Алтын күк сары иген.
Басу кебек киң урамнар,
Комбайннар тавышы
Кисәтә, без кертелмәсәк
Сез ритмсыз калырсыз...
Төнлә ял итеп ятамы,
Я мөһим эш беләнме—
Керә берләп,
Керә меңләп
Авылның кешеләре.
Ач син, шигырь, алар өчен
Каера-каера капкаңны.
Ә син, кузовы йөк белән
Тулган машина шикелле
Үтәрсең вазифаңны.

## Болында

Бер кош сайрый,
Таллар каплый үзен.
Тавышы китә ерак-еракка.
Күлләр тынган,
Юлчы туктап кала:
Уймак кадәр генә йөрәктә
Нинди җырлар,
Нинди мактау сүзе
Үзе торган болын турында.
Җиде офык артындагы авыл,
Шул кош сыман
Синең улың да...

## Тиде, диде

Унжиденче яшемне мин
кар күк йомарлап,
Бер кызга ыргыткан идем,
турыдан узганда.
Борылып та карамады,
Әллә
кирәк санамады.
Унсигезенче яшьне аттым.
Төн кебек кара чәчлесе
Сизмәгәндәй таптап китте.
Ә унтугызынчы яшем
табалмады үз иясен.
Егерменче яшьне аттым.
Чибәр бер кыз
кичә генә,
Тиде, диде,
йөрәгемә...



# К. Мостафин

●

*1932 елда Зеленодольск шәһәрендә туганмын. 1951 елны Чүпрәле урта мәктәбен, 1956 елны Казан университетын тәмамладым. 1957 елдан бирле Уралда инженер булып эшлим. Шигырьләрем студент елларыннан бирле басылып килә.*

*Миңа гражданлык мотивлары бик якын. Минемчә, поэзиянең йөзен, магистраль юнәлешен ул билгеләргә тиеш.*

*Поэзиянең төп дошманы — шигъри әсәрдә оригиналь фикер булмау. Хәзерге шигырь техникасы шактый югары. Һәм бу бик яхшы. Ләкин кайчак, «шома» техника киемнәренә төренеп, суык, җансыз поэзиянең укучылар күңеленә елышуы йөрәкне әрнетә.*

*Хәзер татар поэзиясендә яңа дулкын яшь шагыйрьләр үсеп килә. Аларга өметем зур. Яңа формалар белән бергә поэзия эчтәлеккә байый, тирәнәя...*

## Әни

«Алтын әни», — диеп аңа әйтмибез без,
«матур әни», — дип тә аңа әйтмибез.
Аңа карап, без тик
«әни», — дибез.

Сабый кеше әнә җылы күкрәк имә,
абый кеше чал чәчләрне әнә үбә,
«әни», — диеп.
Үлчәп була алтын-көмеш, асыл ташны,

чагыштырып була кыйгач кара кашны...
Тик ул биргән гомеребезне иңләп булмый,
тик ул биргән гүзәллекне тиңләп булмый...
әйтеп кенә була аңа
«әни», — диеп.

## Казан урамыннан Җәлил килә

Казан урамыннан килә Җәлил
кырык беренченең маенда.
Түбәләргә куна күгәрченнәр,
Яшел бөре шыта каенда.

Витринада — «Кызыл Татарстан»,
я нәрсә бар анда, күрикче...
Чәчү бара. Менә — сводкасы,
Мамадышлар кырда — беренче.

Тагын нәрсә? Губкин егетләре
нефть эзли Кама артында.
Әйбәт... Ә дүртенче биттә...
тагын
грек авыллары ялкында.

Варшавада облавалар бара.
Радиодан Гитлер сөйләгән...
...Җәлил укый. Җәлил уйчанлана.
Күләгәләр төшә өйләрдән.

Казан асфальтыннан Җәлил килә,
ә асфальтны кояш җылыта...
...Ә кайдадыр әсәс
Эммаларның[1]
Джимнарын утка ыргыта.

Бетон юллар буйлап фашист атлый,
сискәндереп таңда бар илне.
Тельман егетләре Моабитта
очратмаган әле Җәлилне.

Моабит саный секунд, минутларын,
ыңгырашып йоклый таңгача.
Ике елдан аның карцерында
Җыр туачак, — кызыл ромашкалар,
утлы гөлләр чәчәк атачак.

Ә Казанда менә җилләр уйный,
Тузгыта күк Җәлил чәчләрен.
Муса исән, без тоябыз аның
Бөек рухы бездә яшәвен.

[1] Эмма — Муса Җәлилнең «Джим» исемле поэмасының герое, нәни кыз.

# Кеше яши

Бу без — һәлак булдык... Ә җил сөйли:
кеше яши җирдә, аннан — җырда...
һәм һәр кичне без керәбез уйга,
һәм һәр таңда без чыгабыз юлга.

Озын юлда — безнең гомер. Анда —
күзне сукырайтып чәчелгән ут.
Анда — җиргә сеңеп яткан чакта
атакага күтәрелгән минут.
Без барабыз — утка керә Вәдүт,
уза Мөҗәй, йөгереп үтә Гайдар...
Безнең артта ал чәчәкләр яна,
ә аласы рубеж һаман алда.

һәм яңадан күтәрелә Мөҗәй,
баса Гайдар. Гранаталар кулда.
Җир чайкала, ә җыр алга оча...
Кеше яши җирдә, аннан — җырда.

# Озын чәчле сәфәрчене

Озын чәчле сәфәрчене
Лексей диеп атаганнар.
Аны руслар гына түгел,
яхшы белгән чуваш, татар.

Иделдәге акчарлаклар
таныш булган ул егеткә,
очкан чакта, канатларын
алар манган ак күбеккә.

Ак күбеккә Алексей да
карап торган ярга басып.
Аннан юлын дәвам иткән,
котомкасын иңгә асып...

Зур диңгезгә җиткән юлчы,
кулын сузган дулкыннарга...
Шушы таңда давыл купкан,
һәм җыр туган шушы таңда.

Бу җыр, давыл кошы булып,
җәйгән горур канатларын,—
аска очкан — дулкыннарга —
һәм омтылган өскә тагын...

Ә мин беләм: җир башланган
Казаннардан, безнең яктан.
Үскән давыл хәбәрчесе,
Идел, синең акчарлактан!

*Мәсгут Шәрифуллин*

# КҮН АЛЪЯПКЫЧ

## Хикәя

Кайсы гына авылга барып чыкма, бөтен җирдә алачыклар чишмә кырыена, я берәр елга буена салынган булыр. Алар барысы да таштан өелгән, ә түбәләре саламны кызыл балчыклы суга чылатып ябылган. Хәзер кайбер авылларда калай белән ябылганнары да очрый. «Яңа юл» колхозының алачыгы да калай түбәле. Кырыеннан гына чылтырап Гаделәй чишмәсе агып ята. Чишмә исеменең каян килеп чыкканын беркем дә рәтләп белми. Имештер, Гаделәй исемле бер кеше кайчандыр шушы чишмә кырыена алачык салган һәм гомере буе тимерчелек белән шөгыльләнгән. Ә авыл бер якта булган. Еллар узган саен, өйләнүче яшьләр, башка чыга-чыга, Шахмарай авылын алачыкка таба күчерә башлаганнар. Хәзер инде Гаделәй чишмәсе авылны икегә ярып уза. Ә алачык кешеләрнең бакча артларында ямьяшел чирәмлектә утыра. Җилсез тыныч көннәрдә тың-тук, тың-тук иткән чүкеч тавышлары тирәдәге урамнарны яңгырата.

Алачык каршындарак ат дагалый торган иләмсез юан баганалы стан эшләнгән. Шунда ук арба тәгәрмәчләренә коршау суга торган стан да бар. Алачык янында чәчкечләр, тырмалар, күп төрәнле сабаннар, культиватор кебек нәрсәләр бер дә бетеп тормый. Шунда ук атналар буе ярым сүтелгән тракторлар ята, автомашиналар килеп туктый. Шактый читтә ташкүмер көле һәм кирәкмәс тимер-томыр өеме тора.

Алачыкның икегә аерылып ачылышлы ишеге көннәр буе ябылмый. Үткән бер кешене кунакка чакырып торган шикелле ул. Ишек алды һәрвакыт себерелгән һәм коры көннәрдә су сибелгән булыр. Ә тимерчелекнең эче шактый корымлы. Почмакта ташкүмер өеме. Түрдә учак. Минһаж аны, гыж-гыж иттереп, зур күрек белән очкыннар очыртаочырта өрдерә. Буйчан гына булса да, күреккә беркетелгән сиртмә күтәрелгәндә, көчкә кулы җитә. Соры күлмәге чалбар эченә кыстырылган булган да хәзер чыгып беткән диярлек. Җиңнәрен сызганган, якасын ычкындырып җибәргән. Кем күрсен, чын тимерче диярсең! Кепкасын нигәдер артын алга әйләндереп кигән. Кул тырнаклары гына ак көе калган. Бераз сипкелле какчарак йөзе тирләп чыккан. Җебегән борынын әледән-әле тартып куя. Аны уңлы-суллы сөрткәләүдән һәр ике як борын яфрагы каралган. Ләкин Минһаҗның күңелендәге уйлары тышкы күренеше белән пар килми. Әтисе белеп торсын: иртәгә эшкә чыкмаячак ул. Җитәр, ике көн килде инде. Күрше малае Ягъфәр кармак салып йөри, ә ул монда күмер белән тимер-томыр арасында!

Минһаж, күрек баса-баса, алачык эченә күз йөртә. Инде мең мәртәбә генә күрмәгәндер ул бу алачык эчен! Ә һаман да карый, караган саен әлек күрмәгән нәрсәләр күзгә чалына.

Ян-якта күп итеп шүрлекләр ясалган. Хәзер анда Сабирҗан агай трактор сабанына шөрепләр сайлый. Ул шүрлекләрдә ни генә юк!

Аларны бер башыннан төшеп икенче башына җиткәнче актарып чыкканы бар Минһаҗның. Әтисе дә шунда актарынырга бик ярата. Зур куллары белән шалтыр-шолтыр килә, үзе бераз бөкрәйгән һәм аркасында тир эзләре бар. Алъяпкыч баулары кара күлмәген җыерган, чалбары инде тузган, ә күн итекләре ялт-йолт итә.

Минһаҗ нигәдер верстак өстендә утырган Борһанга карап алды. Тегесе шунда ук лап итеп идәнгә төште. Беркемгә бер ни әйтмәстән, яньчелгән чиләкне алып, чыгып та китте. Тимер суыта торган улакта су азайган, шуңа өстәмәкчедер инде ул.

Сабирҗан агай гайка сайлый-сайлый улына таба борылды.

— Күмер өстә, — диде ул, коры гына. Минһаҗ күрек басуын ташлап, тиз генә соскы алды да почмакка китте. «Ну шушыны. Эшеңнән гаеп табып кына торыр!» — дип сукранды үзе.

Сабирҗан агай сизелерлек үк аксаклый-аксаклый сандал янына килде.

— Тизрәк кыймылда, учагың сүрелә бит,— дип, мыек астыннан гына мыгырданды ул. Мыегы аның ике якка тырпаеп үсә һәм нигәдер элекке ат каракларын искә төшерә. Мыегының бер ягы саргайганрак, икенче ягы кара көе.

Минһаҗ: «Тагын нәрсә әйтер икән инде!» дип курыккандай, тиз-тиз генә күмер күтәреп салды да сиртмәгә тотынды. Бүгенгә түзсә, иртәгә килмәскә ничек тә хәйләсен табар әле. Ну шушы зур тимерләрне кыздыруы!.. Кадак-мазар ясаганда бераз гына өрдерәсең дә әзер дә була. Ә бу трактор сабанының күчәренә дигән тимерне кыздырасың-кыздырасың, ә ул һаман агармый. Агарса, сандалга салып, бераз гына тукмыйлар да тагын учакка тыгалар.

Сабирҗан агай озын очлы тимерне учакка батырып, кызарган күмерне каергалады. Аннан меңләгән вак очкыннар күтәрелде һәм өстәге зур калай каплавычка бәрелеп, морҗа тишегенә суырылды. Аннары тимерче агай учакның тирә-ягына чүмеч белән су сибеп чыкты. Минһаҗ аның нигә шулай иткәнен күптән белә инде. Тузан чыкмасын, ташкүмер көле күзгә кермәсен дип шулай су сибеп чыга ул.

Сабирҗан агай дүрт кырлы тимернең кызганлыгын чамалап алды да ишеккә таба каерылып кычкырды:

— Борһан, нәрсә син анда... чишмәгә баттың мәллә!!

Ул яргаланган зур кулларын күн алъяпкычына ышкып алды да тәмәке төрергә тотынды. Алачыктагылар белеп тора: Сабирҗан агай тәмәке төрә башладымы, әзерлән — кызу булачак!

Дөп-дөп атлап, кулына чиләк тоткан Борһан да керде. Кулында әллә ун литр керешле чиләк, әллә котелок — аның өчен барыбер шикелле. Керү белән күз салды: Сабирҗан агай каз борыны кебек борынлы келәшчәсенә күмер кыстырган да тәмәке кабызып маташа. Борһан, суны улакка бушатып та тормыйча, җир идәндә яткан унике кадаклы чүкечкә үрелде. Минһаҗ, тимерне алганда тагын да агарып китсен дип, тизтиз өрдерә, үзе дә күреге кебек гыж-гыж килә.

Сабирҗан агай авызындагы тәмәкесен җәһәт кенә мыегының саргайган ягына күчерде дә кулларын күн алъяпкычына ышкып алды һәм иң зур келәшчә белән алсу-аксылланган тимерен тартып чыгарды. Аны сандалга китереп салуга, бер-берсенә кара-каршы торган тимерче белән чүкеч бәрүче йөзенә кызыл яктылык төште.

Тың иттереп берне сукты Сабирҗан агай, шунда ук Борһан гөпелдәтеп дәү чүкечен китереп төшерде. Тирә-якка очкыннар чәчелде. Менә тотындылар тимерне тукмарга: «Тың-тук, тың-тук, тың-тук...» Сабирҗан агай кая сугарга кирәген күрсәтеп, бәләкәй чүкече белән тың-тың итә. Борһан нәкъ ул күрсәткән җиргә китерә дә бәрә, китерә дә бәрә. Очкыннар очып, үзенә бер күңелле көй чыга.

— Тың-тук!

— Тың-тук!
— Тың-тук!
Сабирҗан агай бер тимергә, бер сандалга сугып, чәбәкәй чапканны искә төшерә, ә тегесе аяк типкән кебек гөпелдәтеп гөпелдәтә. Шул ук көйгә сандал өстендәге кызыл тимер дә әйләнеп тора, чүкечләр бии. Тимерчеләр үзләре суккан саен ух-кых итеп куялар. Сабирҗан агайның кулы киләшчәне әйләндергән көйгә, исән аягы да идәнгә типкәләп тора.
— Давай-давай...
— Ух, кых... ух, кых...
— Тартыбрак, тартыбрак...
— Тың-тук, тың-тук!..
Минһаҗга күңелле карап торуы!
Борһанның майкасы ертылырдай булып тартыла, ут капкан кебек кызыл шәүлә төшкән тәннәре ялтырап-ялтырап китә. Кыска гына итеп алдырган чәчләре селкенеп-селкенеп куя. Минһаҗ боты юанлыгы беләкләрендә мускуллар чүкеч төшкән саен дерт-дерт, дерт-дерт итеп ала. Кырык бишенче размерлы кирза итек кигән, баганадай аякларын кин итеп аерып баскан. Кайсыдыр әкияттәге баһадирны хәтерләтә ул. Тик шунысы гаҗәп: йөзендә бер генә тир бөртеге дә юк.
Тимер тукмаганда Минһаҗ әле этисенең киләшчәне әйләндергәләвенә, әле Борһанның беләкләренә карый. Менә шундый булсаң иде! Шулай уникe кадаклы чүкечне уйната алсаң иде! Бу күрек басу нәрсә?.. Моны Ягъфәр дә булдыра.
Сабирҗан агайның бернидә эше юк — кашларын җимереп, тәмәкесен авызына капкан да дүрт кырлы тимерне түгәрәкләттереп тукмата да тукмата. Тәмәкесе сүнгән инде, шуны төкереп ташламыйча, ник авызында тота торгандыр. Соңыннан ул шул төпчекне кызган тимердән кабызачак.
— Тың-тук, тың-тук...
Тимер инде сүрелеп бара. Ә аны тиешле юанлыкка җиткерә алмадылар әле. Минһаҗга тагы кыздырырга туры килә инде.
Ниһаять, Сабирҗан агай сандалга сугып, чүкечне аударды. «Тукта, житте», дигән сүзе ул аның. Борһан шунда ук туктап калды һәм, озын саплы чүкечен җилкәсенә салып, тамырлары беленеп торган беләге белән маңгаен сөрткән булды. Бик күп эшләп арган-талган кешеләрне күзәткәне бар аның.
Сабирҗан агай тимерне күзенә якын ук китереп, әйләндерә-әйләндерә карады: тагы кай җирләрен чүкисе бар икән? Күргәнен хәтеренә салгач, тәмәке төпчеген шул ук кызган тимердән кабызды да рәхәтләнеп төтен чыгарды. Тимерне тагын учакка тыккач, Минһаҗга кырын торып кына эндәште:
— Ну, тагын бер кыздырып алабызмы?
Минһаҗ, бер сүз дә әйтмичә, борынын ышкып куйды да соскы белән учакка күмер салды. Аннан сиртмәгә тотынды. Борһан аңа карап тагы елмайды. Янәсе: «Өрдертәләр генәме!?» Ул гел шулай авызын ерган була. Көн буена үзе ике сүз әйтмәс. Сабирҗан агай аны кайчагында сүгеп тә ташлый, суынган тимер дә тукмата, ә теге ләм-мим... ник авызын ачып бер сүз әйтсен!
Кичәрне кирәкле юанлыкка җиткереп, бөгеп, эшен бетергәч, ачык һавага чыктылар. Иң алдан Сабирҗан агай атлый, күрек басучы койрыкта, ләкин ул да тимерчеләр рәтенә керә. Биленә бәйләгән алъяпкычы юк югын да... булмаса ни!.. Аңа нигә ул? Шулай да алъяпкыч белән шәбрәк инде...
Сабирҗан агай тәгәрмәч суга торган станга утырды да, ашыкмый гына күн алъяпкычын салып, изүләрен ычкындырды. Күлмәген чиметеп кенә тотты һәм тартып селеккәли-селеккәли тәненә һава алдырды. Мин-

һаҗ ат дагалый торган станның аркылы агачына атланып, авыл ягына карана. Халык эштән кайтырга ерак әле. Борһан чишмә буена барып юынды, көрәктәй куллары белән чүмереп су эчте һәм Сабирҗан агай кырыена килеп утырды.

— Тәмлеме су?

Тимерченең тел төбендә: «Нәрсә, кызу булдымы әллә?!» дигәнрәк шаярту иде бу.

— Су яхшы-ы, — диде Борһан елмаеп. Елмайганда аның битендә кызларныкы кебек чокырчык хасил була. Тәмәке тартмый ул, аракы да эчми диләр, шуңа, мөгаен, йөзе ап-алсу. Башын аз гына борса да, муенында калын-калын җыерчыклар барлыкка килә. Гомумән, аның муены, алдан караганда, башы белән бер тигез калынлыкта, хәтта бераз калынрак та түгел микән.

— Чишмә әйбә-әт. Суы да тәмле, — дип сузды Сабирҗан агай, тәмәке янчыгын чыгарып. — Мин белә башлаганда ул тегеннәнрәк ага иде. Ташу булган саен юлын үзгәртә бара. Әлек әнә теге тирәгә, куаклар буенда чегәннәр тукташтыра иде. Яталар иде шунда ике-өч көн буена чатырларын корып.

Сабирҗан агай кәефе килгәндә гел шулай элеккеләрне сөйләргә ярата. Ул чакларны мактамый да, хурламый да, тик болай... гадәте шундыйга гына. Үткәннәрне искә төшерүе күңелле бугай аңа. Ә Борһан балалар кебек тыңларга ярата.

— Әти, ә синең чатырларына кергәнең бармы?

— Кемнәрнең, чегәннәрнеңме? Юк, кергәнем юк. Бер җәйне шулай алачыкка килде болар. Без әти белән тәгәрмәчләргә коршау сугып маташабыз. Кешегә инде. Ул чагында аерым хуҗалык иде. Минһаждан кечерәк булганмындыр. Әти мине гел күрек басарга ияртеп йөртә иде. Таза өч чегән. Ат җитәкләгәннәр. Әти белән русча нидер сөйләшәләр. Дагаларга диләр икән. Мин ул чагында ычпачибадан башка берни белмим. Әти белә инде — солдатта булган. Кул сугыштылар да болар — килешүләре шул булгандыр инде — эшкә тотындылар. Бик әйбәтләп атларын дагалап бирде әти. Шунда үзләре дә ярдәм иткәләп, кысылып йөргән булдылар. Соңыннан бик юмарт түләделәр, хәтта миңа да биш тиенлек бакыр бирделәр. Әти сөенеченнәндер инде, чегәннәрне озаткач, алачыкны япты да кибеткә китте. Төн уртасына кадәр эчте аннан. Иртән алачыкка килеп карасак, күзләр шар булды — түбәнең бер почмагы каерылып ачылган. Ул чагында глин түбә иде. Әтинең пахмиле майлап куйган кебек булды. Нәрсә булган соң дип караштырсак, ни күзебез белән күрик, почмактагы тәгәрмәчләрдән җилләр искән. Ялгаусыз коршаулар суккан, өр-яңа тәгәрмәчләр иде. Әти шунда ук: «Чегәннәр эше булыр бу!» дип, җилләнә-җилләнә алачыктан чыкты. Ә тегеләрнең эзләре дә юк. Куаклык буендагы чатырлары да купкан, кичә яккан учаклары да әллә кайчан сүнгән.

Сабирҗан агай тәмәкесен соңгы кабат чытырдатып суырды да, җиргә ташлап, күн итек башы белән туфракка күмде.

— Шулай итеп бабагызны бер акылга утыртканнар иде.

Минһаҗ алачыкка карап торды да:

— Кайсы почмактан кергәннәр иде? — дип кызыксынды.

— Юк, монсына түгел. Ул алачык әнә тегендәрәк иде. — Сабирҗан агай тимер-томыр калдыклары өеменә таба күрсәтте. — Мондый ук зур түгел иде ул. Минем әти белән бабай салган булганнар. Әти шул алачыгы белән колхозга кергән. Сугыш чыгар алдыннан тегесенең ташларын да кушып, менә шушы алачыкны салдык. Бу чишмә ул — бәхетле чишмә — алачыктан өзелми. Бик күп эшләргә шаһит.

Сабирҗан агай Гаделәй чишмәсенең чылтырап акканын бераз тыңлап утырды да экрен генә урыныннан кузгалды. Борһан да торды. Ә Минһаҗ кояшка күз төшереп алды: баерга шактый бар икән әле

шул. «Әндри вакыты» гына житеп килә. Нишләсен, аңа да әлпән-сәлпән атлап, тегеләргә ияреpгә туры килде. Элек аның ничектер алачыкка гел киләсе килеп тора иде. Укудан кайткач, әнисеннән берәр пирог кебек нәрсә алып тиз-тиз капкалый иде дә шушы алачыкка чаба иде. Монда килгәч, бөтен почмакларны актарып чыга. Әтисе шулай тәмәке тартырга чыккан арада, учакта тимер кыздырып, берәр нәрсә ясап азаплана иде. Хәтта бер вакыт мәктәп капкасына куярга ике элгеч тә ясап алып барды. Әтисе ярдәменнән башка түгел, әлбәттә. Борһан гел алачыкта эшләсә дә, Минһаж кадәре булдыра алмый. Тимерче эше ул ниндидер бер гаҗәеп эш, җаена төшенүне, тәмен тоюны сорый, ахрысы. Карап торсаң, бар да бик аңсат кына эшләнә кебек, ә кулыңа чүкүч, келәшчә тотып эшли башла — һич нәрсә чыгарып булмый. Я тимерне суккан көйгә әйләндереп өлгермисең, я ул келәшчәдән ычкынып төшеп китә. Син бераз җайлап өлгермисең — тимер суынган да була. Шәһәрдән ялга кайтып, алачыкка әллә нинди оста токарьлар, югары разрядлы слесарьлар кергәне бар. Тотынып-тотынып карыйлар, берсенең бер килеп чыкмый. Азапланып-азапланып та кулларыннан килмәгәч: «Булмый икән бу!» дип, чүкечне, келәшчәне Сабирҗан агайга тоттыралар. Мактанып керешкән ничәмә кеше шулай көлкегә калды инде. Ә менә Минһаҗның бераз гына булса да бу эшкә кулы ябыша шикелле. Кайчагында кадак, тырма теше кебек әйберләрне килешле генә итеп ясап куя. Тик көч дигән нәрсә генә чамалы. Ансыннан да бигрәк, көннәр буе алачыкта эшләргә җилкәсе юка икән. Аның эше дә бит иң эч пошыргычы: күрек басу да учакка күмер салу. Үткән елларда атасы Минһаҗның алачыкта эшләү-эшләмәве турында сүз кузгатмаган иде. Ә быел, укулар беткәч, сүзне кыска тотты: «Әйдә, шар сугып йөргәнче, бераз эшкә өйрәнмәссеңме! Бераз хезмәт көне дә булыр», — диде. Минһаҗ өченче көн берсүзсез риза булып, әтәчләнебрәк керешкән иде. Ләкин бүген бөтенләй җебеп төште, түземлегенең соңгы чиге житте. Үзе турында «ялкау малай» дип әйттерәсе килми килүен дә, әмма иртәгә барыбер эшкә чыкмаячак. Хәйләсе дә табылыр.

Сабирҗан агай аксабрак сандал тирәсен урады да:

— Калган вакытны кадаклар гына ясыйк, — дип сөйләнде, келәшчәләрне бәләкәй өстәлгә тезә-тезә. — Югыйсә берьюлы авыргарак килер.

Минһаж тиз генә учакка күмер салды һәм сиртмәгә тотынды: бармак юанлыгы тимерне кыздыру күчәрлек кыздыру түгел, җырлап эшләргә була! Борһан аңа карап тагы елмайды. Минһаж үртәлеп куйды, әйтерсең, Борһан үзе сөенмәгән!

Авыл очында сыер абзары салалар. Шуның бүлмәләренә кагарга юан кадаклар кирәк. Сабирҗан агай аларны күптән ясарга кирәк дип йөри инде. Кичә шуңа чамалап тимер дә кискәләп куйган иде.

Һәркем үз урынына баскач, Сабирҗан агай көтмәгәндә генә:

— Я, кайсыгыз тотына? димәсенме? Әйтәм аны кулын алъяпкычына да ышкымый, тәмәке дә төрми! Шундыйрак бер нияте булган икән.

Борһан белән Минһаж бер-берсенә карашып алдылар. Бу юлы Борһан ник елмайсын! Минһаж да башын аска игән килеш тиз-тиз күрек баса — әтисенең сүзләре аңа бик үк кагылмый, янәсе. Әнә бит ул ничек үз эше белән мәшгуль! Сандал каршына басып, кулга келәшчә-чүкеч алу ул сиңа чегәннәр турында әкият тыңлау түгел! Бер барып тотынмакчы да булган иде, ләкин шунда ук кире чигенде. Әллә ясый ала, әллә юк. Әтисе мыек астыннан гына көлеп торыр иде бугай. Ә Борһан инде авызын ера да ера!

Сабирҗан агай әле улына, әле Борһанга карап алды да:

— Я, нәрсә берегезгә берегез салынасыз! Миңа ышанып торсагыз... Гел шулай булырмыни! Дөньяга мәңгегә килгән кешеләр юк. Мин картайгач нишләрсез?!

Борһан, ни чарадан бичара, кискәләнгән тимерләрне берәм-берәм учакка тыгарга мәҗбүр булды. Кемгә дә булса тотынырга кирәк бит инде! Үзең яса дип әйтеп булмый. Шуның өстенә ул монда, Сабирҗан агайдан кала, өлкән кеше. Минһаҗ күрек басуын белә. Алар Борһан белән тагын карашып алдылар. Бу юлы инде Минһаҗ елмайды.

Сабирҗан агай үзе, штангенциркуль алып, әле генә ясап ташланган кучәрнең юанлыгын үлчәп маташа. Ул арада кадакка дигән тимерләр дә кызып өлгерде.

Борһан бөтен көчен җыеп, эшкә керешге. Башта шулай кадакның очын ясарга кирәк, аннары түбәсен. Моны Минһаҗ да белә.

Сандал өстендә чүкеч тавышы яңгырый башлау белән, Сабирҗан агай гәүдәсен турайтты. Әллә ни әһәмияте юк нәрсәне күзәткәндәй, карап тора башлады. Борһанның тимере башта ук келәшчәгә аркылы килде. Яхшылап каптырыйм дигәндә, төшеп тә китте. Авыр гәүдәсе белән бөгелеп алгалаганчы, җир идәндәге тимер каралып та өлгерде. Тимер урынына ул үзе кып-кызыл булды. Нәрсәдер төшереп ваткан кешедәй, Сабирҗан агайга карап алды һәм тимерне яңадан учакка тыкты. Икенчесен алып ясарга тотынды. Ләкин монсы да эшкә яраклы нәрсә булып чыкмады. Кадакның очын дүрт кырлы итәргә кирәк, юкса ул агачны яра, ә Борһанның әллә ромба кебек, әллә өчпочмаклы булып чыга шунда, белмәссең.

Ул үзе кызарынды, шабыр тиргә батып өлгерде. Унике кадаклы чүкеч күтәреп калтырамаган куллары калтырый. Тешләрен кыскан, кашларын җыерган. Борын очында тир тамчысы асылынып тора-тора да ныграк суккан чакта төшеп китә, аннан тагы җыела.

Минһаҗ аңа җаны-тәне белән көч биреп тора. Иреннәрен кыймылдатып, телен бер якка чыгарып, тегенең эшен җайга салмакчы була, ләкин барып чыкмый гына бит! Менә шуны әйтәләр инде кулы ябышмый, эш рәте белми дип.

Ниһаять, Минһаҗның түземлеге җуелды.

— Бир әле, бир әле булмаса... Үзем! — дип кычкырып җибәрде ул. Һәм Борһанның келәшчәсенә барып та ябышты. Тегесе бик риза булып, бөтенесен аңа бирде. Сабирҗан агай улы ташлап киткәч калган сиртмәгә тотынды һәм әкрен генә өрдерә башлады.

Минһаҗның да эшләре барып чыкмады шул. Кызып китүенә үкенә. Кадак түгел, ә шуңа охшаган нәрсәләр генә килеп чыга. Шулай да аңа тимерчелек эше күбрәк йоккан. Аскы иренен тешли-тешли, ярыйсы ук тимерче кыяфәтен китереп суккалый. Хәзер инде Борһан аңа көч биреп тора. Ансының бар теләгәне шул: «Ясый гына күр. Югыйсә тагы миңа тотынырга туры киләчәк».

Сабирҗан агай ымлап Борһанны чакырды да сиртмәне аңа тоттырды, ә үзе улы янына килде.

— Менә болайрак итеп син аны... — диде ул һәм чүкечне үз кулына алды. — Сөякләрең катып өлгергәнче, җаен белеп кал. Бу эшкә яшьләйрәк өйрәнсәң генә...

Сабирҗан агай рәтләп күрсәтергә дә өлгермәде, Минһаҗ килеп тылкышты.

— Белдем, белдем... — дип сөйләнде ул келәшчәгә тотынып. Әтисе коралларны кире бирде. Аннары, башын бер якка кырын салып тора башлады. Борһан исә буш кулы белән һаман кулъяулыгына битләрен, җилкәсен сөртә. Минһаҗ икенче кадакны да кадак кыяфәтенә кертеп, идәнгә ташлады.

— Сиңа алъяпкыч тегәргә кирәк булыр, — диде Сабирҗан агай.

Ләкин аңа бу ниятен тормышка ашырырга туры килмәде. Минһаҗ тимерчелек эшендә Борһаннан арттырып җибәрүенә дә карамастан, икенче көнне алачыкка бармады. Сүзендә нык торды. Әтисе селеккәләп уятса да, башым авырта дигән булып, урыныннан тормады. Әнисе дә

аны яклап маташты. Сабирҗан агай түрдәге тимер караватта йоклап яткан малайга кырын карый-карый киенде дә алачыгына китте.

Минһаҗ тәмам йокысы туеп уянганда, нарат исе аңкып торган яңа өйдә беркем дә юк иде инде. Билгеле, барысы да эшкә киткән. Ян тәрәзә каршындагы өстәлгә, марля белән ябып, ашарга әзерләп калдырганнар. Ә алдагы өй ишегеп тышкы яктан бикләп киткәннәр. Минһаҗ бер дә каушап калмады: юынып, киенеп, ашамлыкларның тәмлерәкләрен сыптырды да ачылмалы тәрәзәдән бакчага сикерде.

Ә хәзер кая барырга соң?

Аларның бәрәңге бакчалары артында тар гына елга агып ята. Бераз каранып торгач, шул елгачык буена төшеп китте. Су буенда беркем юк, тик өстәрәк кайсыдыр кер бәләкли. Яр буйларын алабута, әрекмән басып бара. Минһаҗ бакчадагы түтәлдән суган кыягы өзеп алды. Аны авызына кабып, яр буенда «ләп-ләп» ясап йөрде. Суган кыягы икегә аерылып, матур булып бөгәрләнде. Бераздан бу нәрсә аны туйдырды, һәм ул суган кыягын «ләп-ләбе» белән бергә ашап җибәрде. Аннары алабута башлары өзеп алып, суга ыргытты. Агалар да китәләр, агалар да китәләр. Бу нәрсәнең дә әллә ни кызыгы юк.

Минһаҗ ишек алларына кайтып, җимеш бакчасына керде. Анда әле өзеп алырдай бернәрсә дә юк. Агачлар күптән түгел чәчкәләрен генә койдылар. Беравык иске эскәмиягә утырып торды ул.

Хәзер нишлиләр икән тегеләр? Борһан күрек басадыр, авыр чүкече белән тимер дә тукмыйдыр. Йокыдан тора алган булса, бара иде инде ул, мөгаен. Торасы гына килмәде. Мыш-мыш килеп күрек басу да бик рәхәт түгел. Кичә үзенә үзе: «Барыбер килмим!» дип сүз бирүе дә хәтердә.

Авыл арасы тып-тын.

Минһаж урамга чыгып китте. Эч поша. Кая барырга соң? Әллә кармаккамы? Юк, кирәкми. Шушы буй белән, Ягъфәр кебек, бала-чага шикелле...

Урам почмагыннан колхоз председателе Гарифуллин белән ферма мөдире килеп чыкты. Нәрсә турындадыр кызып-кызып сөйләнәләр. Минһаҗ эшкә бармый калганына әллә ни булмасын белсә дә, арусынмыйча, тиз генә капкадан кире кереп китте. Ләкин аны Гарифуллин күргән иде инде.

— Нишләп бүген алачыкка бармадың син, малай?! — дип кычкырды ул, капка аша.

— Баш авыртты... — дип мыгырданды Минһаж, ботинка башы белән җиргә нидер сыза-сыза.

Гарифуллин аның ягына баш изәп:

— Күрдеңме?! — диде ферма мөдиренә. Ул капка төбендә чак кына тукталып торды. — Эх, си-ин... — дип сузды председатель, чалбар кесәсеннән портсигар чыгарып. — Кичә Борһан кәнсәләрдә мактап утырган булды тагы! Моңа ышаныч юк. Урынына башка берәр малайны җибәрергә кирәк.

Зур гәүдәле председатель эре-эре атлап, папиросын көйрәтә-көйрәтә китеп тә барды. Ферма мөдире дә аңа иярде.

Минһаж яңадан урамга чыгып, уйланып торды. Әллә барыргамы соң? Бер баш авырта дип калгач, күренеп йөрүе бик шәп түгел шул. Алдакчысы тотыла. Бармаска да була ла. Тик менә эч поша. Ни әйтсәң дә, алачыкта күңеллерәк. Атасы белән Борһан пыр туздырып тимер тукмыйлар. Очкыннар оча! Аннан тагы Борһаннан кадак ясатып, шабыр тиргә батыралар. Шуннан Минһаҗ тотына да, аныкы шәбрәк чыга. Ял иткәндә әтисе тагы берәр кызык та сөйләсә... Көзен мәктәпкә җыелганда, һәркем күпме хезмәт көне ясаганын әйтеп мактанып.

Алачык янын урап кайтырга кирәк әле. Нишлиләр икән? Читтән генә күз салырга була ич.

Минһаҗ шундый ният белән алачык ягына таба китте. Ләкин шунда ук тукталып калды: анда барып эләксәң, пычагым ычкынырсың! Өстәвенә этисе пыр туздырып ачуланыр, ә Борһан авызын ерыр.

Ул кире борылды. Председатель белән ферма мөдире Олы урамга кереп киттеләр. Нәрсә ди?! Урынына икенче малай җибәрергә кирәк диме? Минһаҗ хәзер генә председатель сүзләренең мәгънәсен аңлады. Димәк, аның урынына башка берәр кеше эшләргә тиеш! Аннан инде Минһаҗ алачыкка бүтән барып йөрмәс. Шулай килеп чыга түгелме соң! Башка малай эшләр... Юк! Эшләми генә торсын әле!..

Минһаҗ кырт кына борылды да алачыкка барып була торган тыкрыкка кереп китте.

Бакча башларыннан атлый-атлый алачык артына барып чыкты ул. Тукталып, эчкә колак салды. Ләкин анда бернинди чүкеч чыңлавы да, күрек өрдергән тавыш та юк. Күптән түгел тың-тук, тың-тук итүләре ишетелә иде ләбаса. Якынрак килде. Кайдадыр мыгыр-мыгыр кешеләр сөйләшкән кебек. Нииндидер ят кеше тавышы да бар шикелле. Әллә аның урынына башка берәр кеше килеп тә өлгергәнме? Кинәт аны коточкыч көнләшү биләп алды. «Неужели этисе аның урынына башка берәүне алыр?!»

Минһаҗ, кызыксынуын җиңә алмыйча, ян стена буена чыгып, тәрәзәгә үрелде. Тәрәзәнең бер як кырыеннан гына алачык эченә күз төшермәкче иде. Ләкин шунда:

— Әй, кем ул анда!? Минһаҗ, синмени? — дип кычкыруга, дерт итеп китте. Тавыш бөтенләй алачык эченнән түгел, ә каяндыр тыштан ишетелә. Каерылып караса, этисе белән Борһан тәгәрмәч станы өстендә утыралар.

— Кил бире. Алачыкның ишеге бу якта ич, — дип шаяртты Сабирҗан агай. Минһаҗ башын аска иеп, гаепле кешедәй, станда утыручылар янына атлады. Борһан тагы елмая. Аның шул булыр инде!

— Әйдә утыр, ял ит, — диде Сабирҗан агай. Әйтерсең, Минһаҗ алар белән иртәдән бирле бергә эшләп, алачыктан чыгып килә!

Сабирҗан агай күн алъяпкычына суккалап:

— Ул чагында бу шактый яңа иде әле, — дип, бүленгән сүзен дәвам итте. — Мин аның шушы почмагын гына кызган тимер тотып яндырдым. Аннан менә бу читеннән бераз прокладкалык кисеп алдык. Чегән ул синең әйткәнеңне аңлыймыни! Сат та сат. Аннан давай алышабыз дип бәйләнде. Мин башта аңламый торган идем. Чегәнгә итек тектерергә күн кирәк икән. Ялтырап торган шәп күн теге. Әти безнең бик шаян кеше иде. Әмма кызып китсә, түзеп кенә тор. Таный да алмыйсың! Ул вакытта да шулай булды. Кинәт тәгәрмәчләр югалуы исенә төште тегенең. Кызып китте дә, синең куалды кебек чүкечне күтәреп, чегән өстенә бара бу! Ярый әле этинең дусты Афзалетдин мәрхүм тотып калды. Югыйсә әти теге бәйләнгән чегәнне кызу баштан сугып үтергән иде! Без дә ятим кала идек. Чегән ычкынып, әти сүрелә төшкәч, Афзалетдин абзый: «Бирергәе булмаса, шул кадәре ялынды... хакын да ару гына түли иде», — дип сөйләнә. Бик сабыр, басынкы кеше иде, мәрхүм. Ничек әти белән дус булгандыр. Бакчага кергән тавыкка да: «Көш-ш, рәхмәт төшкере», — дип куа торган иде. Әти тагын күтәрелеп бәрелде. Тегесе аны, бетте, бетте, Габсабир, әйттем исә кайттым дип, суытырга тырышты. Әти алачык алдына чыгып, тәмәке тартырга утыргач, үпкәсен белдерде. «Син, Афзалетдин, — ди бу моңа, — кайчагында бөтенләй тузга язмаган нәрсәләр сөйләп ташлыйсың. Ничек инде мин атамның төсе булган шушы алъяпкычны телсә кемгә биреп җибәрим ди! Я, акыллы кеше киңәшеме бу! Син лутчы минем штанымны салдырып ал!» Афзалетдин эндәшми. Ә тегесе һаман сөйләнә. Ярый, биреп тә җибәрдек ди шул сукбайны җәлләп. Ә менә ул нәрсә киеп эшләр?! Әти мине күрсәтә. Ә мин кая, үзем дә алъяпкыч буе булмаганмындыр әле. «Аңа икенчене

тектерегез», — ди Афзалетдин абзый, миңа күрсәтеп. Әти тагы кыза башлады. «Һы, әйтте сүз! Ул бит сиңа теләсә нинди алъяпкыч түгел, икенче алъяпкыч белән алыштырырга», — дип шаулый теге. Шушылай тезенә суга-суга аңлатырга маташа: «Бабайдан калган алъяпкыч! Тимерче алъяпкычы!»

Борһан рәхәтләнеп елмая, Минһаҗга карап ала.

— Шундый әкәмәт бер кеше иде ул безнең әти.

Сабирҗан агай тәмәкесен суыра, иренеп кенә өрә һәм төтен «мыегына уралып» тора. Борһан аның озын һәм маҗаралы тарихы булган күн алъяпкычына карап утыра. Чыннан да, ниндидер тылсымлы кебек ул. Ни кадәре эшләргә шаһит булган алъяпкыч. Ядкәр итеп сөйләрлек хезмәт алъяпкычы.

Тимерче агай аңа киләшчә тотудан кытыршыланып, уч төпләре калынайган кулын ышкып утыра. Алъяпкычның бер өлеше күкрәгеп каплый, аскы өлеше тезләрен. Муенга кия һәм бәйли торган баулары каеш. Алар кайчандыр ак булганнар. Бил каешларының бер сыңары бик үк каралып өлгермәгән әле — соңгы буыннарның берсе яңага алыштырган, ахрысы.

Сабирҗан агай бераз тын утырганнан соң кинәт Минһаҗга таба борылды да:

— Ну ничек, йокы туйдымы? — дип эндәште.

Минһаҗ чак кына каушап калды. Ул болай сорарлар дип көтмәгән иде. Һәрхәлдә баш авыртуы турында сораулары гына ихтимал иде анынча.

— Туйды, — диде ул, үзе дә сизмәстән. Баш авырта диюгә барыбер ышанасылары юк.

— Туйса, әйдә күрек басарга! — диде Сабирҗан агай һәм урыныннан күтәрелде. Борһан тагы Минһаҗга карап елмайды да, чайкала-чайкала атлап, тимерче артыннан китте. Ул Сабирҗан агайны куып җитеп уза алса да, һич кайчан узмый — артыннан гына бара. Минһаҗ аларга ияргәнче әтисенең чак кына бөкрәйгән аркасына, аксаган көйгә алъяпкыч бауларының чайкалуына карап торды. Менә гел шулай аның атасы. Ичмасам, бер генә мәртәбә «улым» дип эндәшсә дә күңеле булыр иде Минһаҗның. «Әйдә күрек басарга!» — имеш.

Минһаҗ икенче көнне дә бик авырлык белән торды, дөресрәге, атасы йолыккалап торгызды. Әнә шул иртән торулары бик кыен. Бер аякка басып, юынып алгач әллә ни түгел, әмма торып китүләре авыр шул. Кыш көне ул бик сизелми, әмма җәй көннәрендә...

Шулай да Минһаҗ бу җанга тия торган нәрсәгә көннән-көн күнә барды һәм атна буе «башы авыртмады». Кичкә таба тәмам арып аяклары талса да түзде. Шуның өстенә әтисе: «Эшләгән хезмәт көнеңә велосипед алырсың», — дип тә ычкындырды.

Икенче атнада көннәр явымлыга әйләнеп китте. Башта болытлап кына торган иде. Аннары, көзге яңгыр шикелле, пыскып яварга тотынды. Аңа карап, алачыкта эш тукталмады, әлбәттә. Тик Сабирҗан агай гына көннән-көн ныграк аксый башлады. Һава бозылдымы, аның яраланган аягына көн бетә. Үзәгенә үтеп сызлый. Бернинди барометр-мазар кирәкми, әнә шул кырык дүртенче елда яраланган аягы әйтә дә бирә. Үткән төнне ул аеруча сулкылдап сызлады, ә икенче көнне яңгыр коеп яуды. Бөтен җир өсте бүртеп, йомшарды. Уйсу урыннар пычракка, сөзәк җирләр тайгакка әйләнде. Сабирҗан агай алачыктан кайтканда Хикмәтулла тыкрыгы почмагында таеп егылды һәм яралы аягын авырттырды. Чүп өстенә чүмәлә булды инде бу. Быкырдыкка егылып, өс-баш пычрануы юк нәрсә, ә менә авыру аягы өстенә төшүе аяныч. Минһаҗ аны кочаклап, тегесе улының кулбашына таянып, көчкә кайтып җиттеләр.

Шуның икенче көнендә үк, ачу иткәндәй, күк йөзе ачылды да китте. Ялтырап кояш чыкты һәм җир өстен киптерә дә башлады. Сабирҗан агайны аяктан егарга яуган икән.

Алачыкта эшләр җанлы барганда, тимерчелеккә әллә ни игътибар итмиләр кебек иде. Әмма бу алай булмаган икән. Иртән иртүк бар да шау-шу килде. Колхоз хуҗалыгы көйле генә эшләп яткан мотор кебегрәк бит ул. Ә шуның бер нәрсәсе аксый башласа, моторның бөтен җире дә аксарга тотына. Көн дә иртән ачылып, чүкеч тавышлары яңгырый башлаган алачыкның ябык торуы Шахмарай кешеләренә сәер тоелды. Әкренләп алачык тирәсендә ыгы-зыгы туа башлады. Аннан ул ыгы-зыгы Сабирҗан агай йортына да күчә барды. Иң элек, ишеккә көчкә сыеп, башын ия-ия Борһан килеп керде. Ул алачык янында Сабирҗан агай белән Минһаҗны көтеп утырган-утырган да менә аптырап өйгә килгән. Алачыкка кичә ясап калдырган каптыргычларны алырга да кеше җибәргәннәр икән. Инде иллегә чыккан тимерче караватка утырган да, аягын сузып салып, кай җирендәдер снаряд китеге яткан ботын ышкый да ышкый. Элегрәк ул кыйпылчыкларның икесен алдылар, ә монысы калган.

— Менә, Борһан туган, эшләр ханәгә әйләнде бит, — дип шаяртырга маташты Сабирҗан агай. — Егерме ел инде шулай кадерләп йөртәм фриц күчтәнәчен. Йомшакны сизеп алган да рәхәтләнеп ята.

Борһан, нәрсә дияргә дә белмичә, тимерченең куллары йөрүенә карап утыра. Куалды белән бәреп чыгара торган нәрсә түгел шул. Берни кырып булмый. Бераздан ул алачык ачкычын алды да, башын иеп, күңелсез генә кыяфәттә чыгып китте.

Аннан соң төзү бригадасы бригадиры кереп чыкты. Авыл башында салынып яткан шул сыерлар абзарының түбәсен күтәрә башлаганнар икән. Ә анда бәпкәләр кертергә бик күп каптыргычлар кирәк булачак. Кичә ул каптыргычларны ясый башлаганнар иде инде, ә бүген менә нәрсә килеп чыкты. Шуңа да артларына ут капкан кебек йөриләр. Чөнки эш тукталып торуы бар. Моторның бер җире аксады да, машина чош-пош итә башлады. Сыер абзарын кышка кадәре өлгертергә кирәк. Искесен сүттеләр. Ташы кирәк булды. Маллар көндез көтүдә, төнлә утарда куналар. Ә аларны түшәме күк, стеналары киртә утарда кышлатып булмас.

Каушап калган Минһаҗ әле ишек алдына чыга, әле өйгә керә. Әнисе эшкә китте. Өйдә торып та ул Сабирҗан агайга бер ничек ярдәм итә алмас иде. Алачыкка бармакчы иде, ләкин анда атасыннан башка нишләсен. Үзе генә барып тотынырга йөрәге җитми. Тимерчелек эше бит ул! Атасының бер үзен калдырып китү дә ничектер уңайсыз кебек. Авыру кешегә тегесе кирәк, монысы кирәк була. Минһаҗ аңа армиядән таянып кайткан култык таякларын төшереп бирде. Өй чормасында алар бик коргаксыганнар. Шуларның тузанын юып чүпрәк белән сөртеп маташканда, Гарифуллин килеп керде.

— Исәнмесез, — диде председатель, кулъяулыгы белән муенын, ияк асларын сөртә-сөртә. Каядыр ашыга төсле ул үзе. — Ничек булды соң әле бу, Сабирҗан туган? Авыртамы?

Гарифуллин бер якта торган артсыз урындыкны дыңгырдатып карават кырыена китерде дә авыру янына утырды.

— Сызлый шул, — дип зарланды Сабирҗан агай.— Бастың исә, күздән утлар күренә.

Председатель култык таякларына баш иэп:

— Боларны да кузгаткансың икә-ән, — дип сузды. Ул колхоз тимерчесенең шулай кисәк кенә авырып китүенә ышанып бетмичәрәк торган, ахрысы.

— Бәла аяк астыннан чыга, ди.

— Ике кулсыз калдырдың бит, ә! Печән чапкычларны да карыйсы

бар. Бу фермасы да... Әй-яй-яй... — Гарифуллин яшел фуражкасын салып, караватка ташлады. Чал кергән кара чәчләрен бармаклары белән тарап, җилкәсен кашып алды.

— Врач чакыртыйкмы?

Сабирҗан агай кул селтәде.

Председатель портсигар чыгарып ачты да, папиросларга карап торгач, нигәдер тагы шыртлатып япты. Авыру кеше утырган өйдә тартырга кыймады, ахрысы. Моны күзәтеп, ярым утырган, ярым яткан Сабирҗан агай улына эндәште:

— Минһаҗ, бар әле теге өйдәге шкафтан тәмәке алып кер. Калай савыттагысын ал.

Минһаҗ култык таякларын карават башына сөяп куйды да алдагы өйгә чыгып китте. Стенага кадаклап куйган капкачсыз шкафтан калай савытны эзләде. Аны алганда икенче савыттагысын төшереп түкте. Шуны җыештырып азапланды. Өйгә кергәч, озак йөргәне өчен әтисе сукраныр дип көткән иде, ләкин председатель белән тимерчедә тәмәке кайгысы юк иде. Алар, Минһаҗ керү белән сөйләшүдән туктап, үсмер егеткә сынаулы караш ташладылар. Минһаҗ кулындагы савытын карават башындагы өстәлгә куйды һәм, тагы нәрсә кушарлар икән дигәндәй, мич буена барып басты.

— Кара әле, Минһаҗ энекәш, — дип эндәште Гарифуллин, бик зур үтенече төшкән кешедәй. — Алачыкка барырга иде бит.

— Нәрсә алып кайтырга, Мөдәррис абый?

— Юк, андый йомышларга йөрүдән узган инде син. Атламалар ясарга кирәк иде бит.

Аптырап калган Минһаҗ, күзләрен тутырып, әтисенә карады.

— Бар, улым, бар, — диде Сабирҗан агай, чак кына калтыранган тавыш белән. — Әкренләп ясарсыз. Шуннан китә инде ул.

Минһаҗ, бер сүз дә әйтмичә, җыена башлады. Әтисе «улым» дип эндәште. Бик кирәк микәнни соң?

— Әйдә, капка төбендә машина тора. Утырып барыйк. Минем дә шул тирәгә барасым бар.

Председатель белән Минһаҗ ишеккә юнәлделәр.

— Алъяпкычны бил турыннан икегә бөкләп бәйлә, — дип кычкырып калды Сабирҗан агай улы артыннан. Ишек ябылгач, үз алдына мыгырданды: — Уң аягын атлап чыкты. Хәерле юлга, хәерле юлга...

Минһаҗ белән Гарифуллин, машинага утырып, эһ дигәнче алачыкка барып җиттеләр. Төзү бригадасыннан бер егет күрек басып азаплана. Борһан тирләп-пешеп атлама ясарга маташа. Аның каршында авыр чүкеч тотып, бригадир басып тора. Каптыргычка охшатыбрак, ике нәрсә ясап ташлаганнар. Кыска гына буйлы ферма мөдире Хәйбүш тә шунда чуала.

— Ну, егетләр, эшләр ничек? — дип шаулады председатель, алачыкка килеп керү белән.

— Эшләр ярыйсы-ы. Үзебезгә кирәкне ясап маташабыз, — дип такылдый ферма мөдире, Борһанның суккалавын күзәтә-күзәтә.

— Менә бәләкәй Сабирҗан ясап карасын әле. Берәр нәрсә чыкмасмы.

Ферма мөдире дә җавапсыз калмады:

— Ихтимал, бик ихтимал. Оясында ни күрсә, очканда да шуны куар.

Минһаҗ, беркемгә бернәрсә әйтмичә, түргә узды һәм баганадагы кадакка элеп куйган көн алъяпкычны алды. Муенга кигәч, ул шактый озын булып чыкты. Әһә, бил турында икегә бөкләп бәйләсәң, кыскара икән. Каешларны бәйләгәндә куллар бераз калтыранды. Атларга бераз комачаулый икән бу алъяпкыч дигән нәрсә. Ә үзе кешегә ниндидер көч биргән, дәрт өстәгән кебек.

Минһажга эссе булып китте: бөтенесе аңа карап тора. Ул зурлардай салмак кына атлап, учак каршына килде. Борһан инде чүкечне, келәшчәне урынына куйган һәм үзенең гадәттә торган җиренә чыгып баскан. Ничектер бөтенесе шулай килеп чыкты, әйтерсең, моңа кадәр тимерче булып Сабирҗан агай түгел, ә Минһаҗ эшләгән.

Күрек выж-выж итә. Учактан вак кына очкыннар оча. Ташкүмер янган ис килә.

Минһаҗ улактан чүмеч белән су чүмереп алды да учакның тирәягына сибеп чыкты. Аннары, нигә икәнен үзе дә белмичә, кулларын күн алъяпкычка ышкып торды. Бригадирдагы зур чүкеч Борһан кулына күчте. Минһаҗ келәшчә белән кызган тимерне тартып чыгарды да сандалга китереп салды һәм чүкече белән сугып та куйды. Борһан шунда ук, җавап кайтаргандай, куалды белән бәрде. Шуннан ялганып китте: «Тың-тук, тың-тук...» Минһаҗ кая сугарга кирәген ярыйсы гына күрсәтә болай. Келәшчәсе белән тимерне дә оста әйләндерә. Бөтен кыяфәте әтисенеке кебек, тик авызында тәмәкесе генә юк. Чүкечләр чыгарган көй аксаса да, тимерне кирәкле формага китерәләр.

— Тың-тук!

— Тың-тук!

— Давай, давай...

Бар да елмаешып карап тора. Әллә Минһаҗның нәкъ атасы шикелле кыланувы кызык кебек тоела, әллә сөенәләр, белмәссең.

— Тың-тук, тың-тук...

— Тартыбрак, тартыбрак...

— Тың-тук, тың-тук...

Гаделәй чишмәсе буенда тагын чүкеч тавышлары яңгырый. Күн алъяпкыч та чираттагы буынга күчәр микәнни?

Култык таякларына таянып, алачык ишеге төбенә килеп туктаган Сабирҗан агайның күзләре дымланган, ә үзе елмая.

# Салих Батталга 60 яшь



## Хөрмәтле каләмдәшебез

## *Салих Баттал!*

*Сез татар поэзиясе күгенә „Эшче" аэродромыннан моннан 40 ел элек күтәрелдегез һәм „Җир өчен күктән матур җырлар" алып кайттыгыз. Аннары укучыларыбызга Сезнең „Очучылар букеты" бүләк ителде. Сез театрда „Язулы яулык"ны күрсәтеп сәхнәбезне баеттыгыз, „Сынау"ыгыз белән җитди уйландырдыгыз, үзегезгә генә хас булган сатира-юмор белән тормыштагы кимчелекләрне көйдерә-көйдерә, поэзиядә „Олы юл буйлап" киттегез.*

*Киләчәктә дә „Баттал икәнегезне онытсагыз да, постта икәнегезне онытмыйча", шул „Олы юл буйлап" очуыгызны дәвам итегез.*

*Сезгә озын гомер, саулык һәм яңа иҗат уңышлары телибез.*

*Татарстан язучылары союзы.*

*„КАЗАН УТЛАРЫ" журналы коллективы каләмдәшләренең котлавына кушылып, юбилярны бәйрәм белән тәбрикли һәм талантлы яңа әсәрләр көтеп кала.*

*„КАЗАН УТЛАРЫ" журналы редакциясе.*

# ЧИРМЕШӘН ЯКЛАРЫНДА

## Роман

*Октябрьның 50 еллыгына багышлана*

1 кисәк

### КЕРЕШ

Тыңлыйк әле сандугачны
Чирмешән якларында
талга басып, тал тибрәтеп
сайраган чакларында.

Сандугачлар сайрый-сайрый
сындыра тирәкләрне;
сындыралмый тирәкләрне—
сыздыра йөрәкләрне.

Сандугачның берсе бар—
тал төбендә эше бар.
Тал төбенә төшәр иде—
тал төбендә кеше бар.

Таң җиле исеп китәдер,
былбыл тынды нигәдер...
Яңа туган бала чөнки
нечкә тавыш бирәдер.

Чылтыр-чылтыр су ага,
тирән урын тын ага.
Бала елый, тик кузгалмый
исеннән язган ана.

Ала карга килә инде,
таллар бөгелә инде;
яңа туган баланы ул
ит диеп белә инде.

Әрәмә тавы башында—
елан яфрак астында.
Кырмыскалар йоклый әле
кырмыска оясында.

Сандугач, уят анасын,
кулга алсын баласын,
ул сабагыннан өзелгән
чәчкә сыман ятмасын.

Сараның тузгыган чәчен
(җил исте дә катырак)
калтыранган кулы белән
сыйпап алды яфрак.

Шунда Сара аңга килеп,
баласын кулга алып,
«Бала табу шул икән!» — дип
тора хәйранга калып.

Мин дә хәйран калдым әле:
шулай ук дөресме бу,—
шигырь семьясына миннән
тагын бер өлешме бу?

Бу әсәр күп әсәрләрнең
берсенә охшашлымы,
бу синең зәгыйфь балаң да
кешегә охшашлымы?

Нишләр аны ташка бәйләп,
суга кертеп ташласаң;
яхшы чакта бу юлларны
мин дә ертып ташласам?

Икебезне дә югыйсә
бертөрле язмыш көтә —
төн йокысыз кайгыртулар
һәм аяусыз эш көтә.

Юк, Сара, тор, барсы үтәр,
төшермә күңелләрне,
куып җибәр шик кортларын
тараткан чебеннәрне.

Ал кулыңа урагыңны,
кис улыңның кендеген.
Мин дә кисәм шикләр белән
бәйләнешемне бүген.

Җырлый-җырлый киттек, әйдә,
җырлап ачыла күңел.
Җырлап ачылмаса күңел,
елап ачылачак түгел.

I

И, яраннар, тыңлагыз,
бер генә көй көйләем;
Чирмешәнлеләр бәетен
мин сезләргә сөйләем.

Бу тарихның мең тугыз йөз
бишенче елларында,
бер бала дөньяга килде
Чирмешән буйларында.

Туган чагында баланың
әтисе читтә иде,
шуннан тугыз айлар элек
ул кайтып киткән иде.
Әнекәсе бер муллага
эшләп көн итә иде.

Мулла инде яшьтән түгел,
Яше илледә иде.
Авыр чалмасы астында
башы иелгән иде.

Бай иде ул. Өйләре—
Җете яшел түбәле.
Түбәләрен каплап үскән
бакчаларын күр әле!

II

Иртәрәк иде. Таң иде.
Хәзрәт уянган иде.
Бимазаланган уйлардан
йокысыз калган иде.

Бер-бер артлы тирә-яктан
килә әтәч өннәре,
гөлдердәшәләр читлектә
мысыр күгәрченнәре.

Хәзрәтнең дә шунда иркә
бер сүз дәшәсе килә,
мысыр күгәрченнәре кук
гөлдердәшәсе килә.

Аның остабикәсе шул
үткән елның көзеннән,
сырхаулык инәсе белән
тушәгенә тегелгән.

Әкертен, ләкин токтарсыз
үлем юлыннан бара.
Онытылган чәй шикелле
каны суына бара.

Аның үлүен көтте хәзрәт.
Гәрчә көтү—бик авыр,
хәзрәт ул көтү ягыннан
нәкъ минем кебек сабыр.

Күп көннәрен әрәм итте
мәдәт көтеп таңредән.
(Шулай мактау сүзен көтәм
мин дә Хәсән Хәйридән.)

Ә бүген төшенде хәзрәт—
булдыралмый йокларга!
Аның сабырлыгы җитми
безнең сабырлыкларга.

Менә ул беренче кабат
җомга иртәсе белән
чыгып китте, сөйләшмичә
остабикәсе белән.

Саба җиле исәдер,
иртә намаз җитәдер.
Азан әйтә, хәзрәт уйлый:
«Гомерем зая үтәдер...»

Мәчет манаралары,
манара аралары,
урамда, капка төбендә
кое баганалары—

чыгу белән чалындылар
хәзрәтнең күзенә...
Тукта, кемнеңдер бит анда
зифа буе күренә!

Каз канатын кагадыр,
таң сызылып барадыр.
Зифа буйлы бер хатын-кыз
коедан су аладыр.

Аны гына зурлый кебек
бүгенге көн иртәсе,
аны зурлап, җиргә кадәр
иелә кое сиртмәсе.

Бу кем? Йөзе кара икән...
Әлеге Сара икән!
Уракка алып барырга
салкын су ала икән!

Тырысына салган чакта
салкын суы түгелә.
Азаплана Сара мескен
тик сыңар кулы белән.

Чөнки аның бер кулында—
безгә таныш баласы.
— Улым,—дип сөйләнә үзе,—
ничек итеп саласы...

III

Мулла теләде тик аңар
ярдәм итәргә генә.
Әмма үкенде үзенең
ашыгыч ярдәменә.

Йөкле чакта гына күреп
Сараның төсен-буен,
уйламаган да иде ул
мондый гүзәл булуын!

Кара кашлары, гүяки,
нечкә, үткен чалгылар,
карт буыннарын мулланың
чалдылар да салдылар.

Су салганда карап ала,
кашыннан күзе кара.
Чиләгеннән суы ага,
керфегеннән гөл тама.

Кемне кол итмәс матурлык
һәм тазалык берләшеп!—
Бакчаларда алма пешә
битләреннән көнләшеп.

Нишләргә дә белми хәзрәт.
Ул куя бөтен көчен
эчеп егылмас өчен бу
хисләрнең исерткечен.

Уйлый: «Нечкә билләрен бу
юри шулай борадыр,
нечкә билләрен боргалап,
мине кызыктырадыр...»

Шундый өзек-өзек уйлар
Тарката зиһенен аның,
тиз генә алып таяна
сөяп куйган таягын...

Сара аңар рәхмәт укый
беләүсәләрен рәтләп:
«Олы башың кече итеп
булышуыңа рәхмәт».

Һәм китеп барды кинәт ул.
Тавис сыман атлый бит!
Туктатты мулла, эндәшеп:
— Балагыз ни атлы?—дип.

Шунда туктап әзмәкчемен
шигырьләр юлын да мин,
сөйләп бирим ул баланың
исеме турында мин.

### IV

Чирмешәнле авылында—
метрика дәфтәрләре.
Юк микән,—дип,—исемнәрнең
миңа кирәккәннәре.

Сара малаеның исемен
мин шуңардан эзләдем.
Эзләп-эзләп табалмадым
һәм кулымны селтәдем.

Шунда бер колхозчы бабай:
— Нәрсә,—диде,—эзлисең?
Нәумизләнеп җавап бирдем:
— Кирәк иде бер исем.

Кемне эзләвемне белгәч,
якын ук килде бабай,
— Аны моннан тапмассың. Ул—
отпавший,—диде бабай.—

Бер заман бетермәк булып
Халыклар аермасын,
шул Сараның әнисенең
әбисенең бабасын
Иван патша әмер биреп,
чукындыра башлаган.
Башлаган да, тәмамламый,
ярты юлда ташлаган.

Ярты юлда калган: һаман
керәшен саналмаган.
Мулла метрикасына да
ул кире кайталмаган.

Беләсең килсә, үзем дә
шулар нәселе инде.
Әлеге Сара миңа ул
бертуган сеңел иде.

Менә шундый кешеләргә
«Отпавший» нәсел диләр.
Чакырасың муллаларны—
ашка-суга килмиләр.

Өйләнергә кыз тапмыйсың,
тапсаң никах укылмый.
Бала-фәлән туа калса,
аңа исем кушылмый.

Бушлай урды мулла җирен
безнең Сара—уракчы:
баласына шәригатьчә
бер исем куштырмакчы!

Тукта,—диде, тынып калды
бабай шул сүзгә җиткәч,—
беләсеңме, мулланың бер
хаты бар миндә, иптәш!

Теге елны язылган ул.
Ерак түгел моннан ул.
Очырмадан килеп чыкты—
Сара сандыгыннан ул.

Әйдә безгә чәйгә! Рас!
Мәе дә булыр бераз.
Достоверный булсын әшең,
иренми өйрән дә яз!

### V

## МУЛЛАНЫҢ САРАГА ЯЗГАН ХАТЫ

«Чук сәламләр булсын сезгә—
күңелем мивәсенә,—
дөнья вә ахирәттәге
байлыгым иясенә.

Мәгълүм инде, бер байлык та
сезләргә лаек булмас.
Әмма ләкин, инша алла
Өмидем заегъ булмас.

Бу хатны безләр башладык
җомга көн өйләдән соң,
тау-тау изге теләкләрдән,
истихарәләрдән соң.

Тәңре каршында зар кылып,
яшьләр түгелгәч кенә;
корьән фалы ачып карап,
яхшы күренгәч кенә.

«Эльзарурәте табихель-
мәхзурат» дигән кеби,
башмакчы була икән шул
башына төшкән кеши.

Без дә шулай булдык ахры.
Бик ошап җитмәсә дә,
хаят, мәмат, ягъни—яшәү,
үлем дигән мәсьәлә.

Шул мәсьәлә мондый эшкә
безләрне мәҗбүр итте;
олыларны кечерәйтте,
кечеләрне зур итте.

Исеңездәдер, ул көнне
юк эшне дә бар итеп,
сезнең җәнапларыгызга—
кыюга юнәлгән идек.

Морадына ирешүгә
ышанып йөргән күңел
сезнең алай баш тартудан
асла канәгать түгел.

Һәм ушандак икенче кат
күрешү мәгъкуль түгел:
андаен гади чаралар
безнең өчен кул түгел.

Ярдәм итәр кешем дә юк.
Кемгә серне ачарга?—
Туры киләдер хатымны
җансыз илче ясарга.

Остабикә апагыз да
күптәннән авыру инде;
ахыры ни булачагы
күпләргә мәгълүм инде.

Сизенәдер ул үзе дә
булырмын, дип, мәрхүмә,
төшләренә җәннәт керә,
үзен җәннәттә күрә.

Ята иде ул мискинәм
тик минем өчен көеп,
бу гөнаһлы җир өстендә
ялгыз каласың, диеп.

Сиңа мәелемне әйткәч,
ул шатланды бигаять,
бәрәкалла, диеп, җиңел
сулу алды, ниһаять.

Әйе, сүнә-китә гомер,
ул—бер ходай яккан ут.
«Вә ма тадри нәфсен,—дигән,—
би әйи әрзон тәмуть».

Ягъни, безнең кулда түгел
кай җирдә үләсебез.
Бәлки бардыр сезнең белән
бергә көн күрәсебез...

Сезнең бала булыр иде
безнең уртак баламыз.
Бар мөлкәтемезне аңар
мирас итә аямыз!

Бикәрдер адәм затына
мөлкәтсез туган җисем,
эткә биргән кушаматтыр—
аңар бирелгән исем.

Улыңызга булган уем
хатымнан анык булсын:
файтонымыз дилбегәсе
кулына лаек булсын.

Утыртып икәвемезне,
йөретсен ашка-суга.
Хуҗа булып үссен хәзер
сезләр урган басуга.

Мелла мөлкәте иминдер,
иядер ихтирамга,
һич кагылмыйдыр аңарга
фетнә дә, ихтилал да.

Мелла үзе, сәүдәгәрдәй,
зимагурдай каңгырып,
бер генә көн дә йөрмидер
гаиләсен калдырып.

Бәлаләрдән дөньялыкта
һәм ахирәттә имин.
Шулай сезләр белән бергә
яшәргә язсын.
Амин!»

---

Мулла хаты үземнең дә
күңелгә ятып китте.
Аңар биргән урыным, ахры,
муллага артык китте.

Бер метр да бирмәс идем,
торак таләп итсә ул.
Тик җанымда урын алган,
гел күңелдә, истә ул.

Әби әйтә торган иде:
«Рәсем ясый күрмә,—дип,—
ясаган рәсмең җан сорар
кыямәт көнендә»,—дип.

Тартынмыйм хәзер дә моңар
әбиләрчә караудан:
художникның рәсемнәре
җан сорыйлар аңардан.

Уңай тип дигәннәре дә
башка ниятә түгел,
һәммәсе дә җан сорыйлар.
Тик кыямәттә түгел,
менә хәзер, язган чакта
каләм астыннан давай!—
Бер үк хокук белән даулый
бай һәм ярлы ябагай.

Миннән җан алып, Сарага
елыша мулла бабай.

Бирешмә син мәкеренә,
явызлыгына аның!
Сиңа да җанымны бирәм,
бирешмә, Сара җаным!

### VI

Межадан межага илтеп,
урак кыштырдауларын,
сизмәде ул көнне Сара
билчәннең тырнауларын.

Шул минутларында аны
бер нәрсә генә изде;
нәрсә изгәнлеген аның
күкрәге генә сизде.

Шундый чакта ул баласын
имезеп ала иде,
тик бүген аның баласы
авылда калган иде.

Әрнеп, ташыса да сөте,
тәтеми ими аңар,
күрше кызы киндер аша
суырта ипи аңар.

Чыдамады, кайтты ана.
Авырып кайтты кеше.
Ташка әверелде күкрәге,
чыкмады, катты сөте...

Җан керде Сара йортына:
яшь балалы түтәйләр
хәл беләләр, җил капкадан
җир идәнгә үтәләр.

Имүче геройга бәйрәм,
юмарт апалар килгәч;
үз сөтләре белән аны
сыйлыйлар алмаш-тилмәш.

Менә баланы арадан
таза хатын алды бер.
— «Кем хатыны?» — дисәгез, ул
беркем хатыны түгел,

Мәгъзия ул. Аның җирен
«Мәгъзия җире» диләр.
Ирен дә Фатих димиләр—
«Мәгъзия ире» диләр.

Мәгъзия иргә чыкмады—
Мәгъзиягә чыкты ир.
Мәгъзия өчен ир биле—
сыгылмалы, нечкә бил.

Ирен—нечкә билен ташлап
шахтага барып кайтты,
ел буена күмер чабып,
шактый мал табып кайтты.

Урак ура, зурат куя,
аннан көлтә кертә ул,
начар юлда йөкне тарта
аты белән бергә ул.

Кыскасы, дөнья җимереп
эшли үгез урнына.
Маңгай—тигез. Күкрәк үскән
ике мөгез урнына.

Шул мөгезләрнең очларын
авыз эченә төрткәч,
имми булдырмады бала,
имәрсең башка төшкәч!

Нинди генә изүләрдән
нинди күкрәкләр генә
иммәде ул, — нинди куе
һәм сыек сөтләр генә!

Агып китә язды имеп,
белештерми ул һаман.
Бәхетенә каршы ләкин
илче килде мулладан.

### VII

Изүе эченә тыккан
безгә таныш хаты бар.
Аны Сарага укырга
мулладан рөхсәте бар.

Юкса үзе язган хатны,
адресатына килеп
үзе укымас ич мулла,
Хуҗа Насретдин кебек!

Имезүләр туктатылды.
Инде аналар хәзер
үзләре
илче шәкертнең
серен имәргә әзер.
Кыштырдый ул хат, шәкертнең
йөрәге тибүеннән.
Балкып чыгармы ул аның
кулмәге изүеннән?

Чыгарды. Укыды. Һичкем
әйтмәде гаеп диеп.
Хат дип укымады чөнки,
укыды бәет диеп.

Укучылар! Сез дә хәзер
бу әсәрнең, ниһаять,
нинди «бәет» икәнлеген
төшенгәнсездер шаять.

Мин дә шәкерт малай идем.
Зур белем бирде «мәптек»,
моны Фатих Хәсни кебек
«Дөресен генә әйттек.»

Моңар шаһит күрше кызы,
шул каһәр генә мине
«Шәкерт-мәкерт!» — дип мыскыллап
теңкәмә тия иде.

Мин хәзер дә сезнең шәкерт.
Минем эшем кечкенә:
сезнең хисне адресатка
тапшырам илтеп кенә.

Бу миңа комачауламый
сизәргә мулла көчен.
Чыннан да бит зур кыюлык
бу адым мулла өчен:

Дин башлыгы була торып,
гөнаһ дигән нәрсәгә
төкергән ул, хат җибәргән
отпавшийга! — Мәкрәгә!

VIII

Моны сизмәгән дисезме
Мәгъзия, Нәфисәләр? —
Чабатаң эчендә бармак
кыймылдавын сизәләр!

Сөйли авыл иртә белән
көтү куганда таңнан:
— Сара бит — яшь остабикә,
беләсеңме?
— Кит аннан!

Әгәр ире кайтып төшсә!
— Кайта ди! Ник кайтсын ул,
исеме генә ир бит аның,
мәкрәгә никахсыз ул.

— Ә муллага ярыймыни?
— Патша монафист биреп,
мәкрәләргә дин сайларга
биргән икән ди ирек.

— Ә!.. Алайса белеп эшли
ул дингә карап кына:
мәкрәне мөселман итсә,
муллага савап кына.

IX

Алар сөйләшә торсыннар,
Кайтыйк Сарага хәзер.
Сизә Сара, икеләтә
авыр аңарга хәзер.

Аның күкрәгән таш итә
имелмәгән сөтләре;
аның йөрәген фаш итә
түгелмәгән хисләре.

Ул тора торган тыкрыкка
тик шуның өчен кереп,
юри сөйләшеп уздылар
аңарга ишеттереп:

— Фытыр илтер өчен әлек
ерак иде мулла, — дип, —
инде эшләр җиңеләйде,
Сара — ярты юлда, — дип.

Ята Сара, ничек кенә
бушатыйм, — диеп, — эчем...
Мулладан әлеге шәкерт
килеп чыккач та кичен,
Кабызды сукыр лампасын,
гомрендә беренче кат
барлык сагышларын түгеп,
иренә яздырды хат.

САРАНЫҢ ХАТЫ

«Хатлар язам, хатлар язам,
айлы кичәдә язам.
Кайгым хаттан ташып айны
күмеп китсә дә язам.

Читен эшләр, кыска төннәр
кызу урак өстендә.
Нинди кыска төннәрдә дә
сине күрәм төшемдә.

Нәрсә языйм гына соң —
барысын онyттырасың.
Күземне йомар хәлем юк —
күз алдымда торасың.

Бәлки ачуланырсың да
бу моңлануларыма,
сагынуларың җитмәсә
минем сагынуларыма.

Кемнәр шаһит? — гөлләр шаһит —
яшел дуслар янымда. —
Яшем белән битем юам
хатлар язган чагымда.

Яшь гомердә нинди ямь бар
аерым яшәргә булгач,
синнән килгән бүләкләрне
сатып ашарга булгач.

Шундый читен минутларда
серләшергә кешем юк.
Күз алларымда торсаң да,
сөйләтергә көчем юк.

Ичмасам бәйләнә тагын
чалмалы бер бәласе.
Чын мәхәббәтләр булмагач,
кадалсын дәрәҗәсе!

Гайбәт теле озын була,
дөреслек телсез булгач.
Сөйләсеннәр, китми исем
йөрәгем керсез булгач.

Сүз ишетәм, сүз ишетәм,
баш иеп тыңлыйм гына,
сагынып елыйм гына да,
моңаеп җырлыйм гына.

Бер генә нигезләре юк
гаеп итәргә мине.
Азмаганны аза диләр,
азсам нишләрләр иде!

Бергә булсак, безгә алар
берни димәсләр иде.
Аерым яшәү рәхәт булса
безгә тимәс тә иде.

Өзеләмен, өзеләмен,
өзелеп ялганамын,
исән булсак кавышырбыз
дип кенә алданамын.

Бәйлим, сүтәм; бәйлим, сүтәм
бәйләгән шәлләремне,
бәйдәге колдай яшимен,
белмисең хәлләремне!

Ак күлмәгеңне юамын,
киптерергә эләмен,
эләм дә, әйләнеп карыйм —
үзең диеп беләмен...

Сагыну язмыштан микән,
әллә үземнән микән?
Аерылган минутларда
ничек түзелгән икән!

Көнчыгыш як агара,
караңгылык тарала.
Хатымны тапшырмас микән —
ай синең якка бара.

Ай янында якты йолдыз —
минем йолдызым гына,
йолдызым — улым бар минем,
түгел ялгызым гына!

Йолдызыбыз — улыбыз бар,
котларга лаекмы бу,
әйт, җанашым, синең өчен
кайгымы, шатлыкмы бу?

Кояш чыкканын күргәнчә
күрәм аның батканын,
баткан кояш чыккан кебек
кайтырсың бит, аппагым?!

Кайтмас булсаң, нихәл итим,
эшлә үз белгәнеңне.
Күп тормассың, ишетерсең
саргаеп үлгәнемне...»

## X

Ачы буранлы кышкы җил
сызгырып исә иде.
Төн иде. Әрәмә буйлап
җәяүле үтә иде.

Колакчыннан. Чикмән кигән
бау белән билен буып.
Арты белән әйләнгәләп,
я битен читкә борып,
кар көртләрен кисә-кисә
атлый ул җилгә кырын.
Хыялында — якын авыл,
җәелгән җылы урын...

Арттан җитеп, җилкәсенә
бер ат пошкырды кинәт,
шул ук вакыт иңбашына
тартә ышкылды кинәт.

Чанада икәү иделәр.
Һәм үзара киңәшеп,
— Әйдә, утыр! — диде алар
җәяүлегә эндәшеп.

Җәяүле ауды чанага
аякларын күтәреп,
чабу эченә яшерде,
берсен берсенә бәреп.

Сорашты ул. Чаналылар:
«Күрше авыллар» диде.
Җәяүле әйтте — исәбем —
бер ат алырга иде, —
акча җыеп кайтам, — диде.
Һәм шунда олаучылар
серле итеп, терсәкләшеп,
үзара ымлаштылар.

һәм сискәнде яңа юлдаш:
янбызы сиздә моның —
салам астында балтадан
бушанып калды урын.

Кулын терәгән иде дә,
шуып төшәргә диеп,
берсе кинәт албастыдай
өстенә ятты килеп.

Үтерделәр... Кем өчендер
ул иде — якты кояш!
Артык ул чыкмас әйләнеп,
мәңгегә батты кояш.

Әрәмәдә — бер аланчык,
өч ягы — таллык кына.
Өч ягы — тал, бер юлы бар
чана сыярлык кына.

Безгә таныш бу урыннар:
нәкъ менә шунда инде
җәй көнендә тал төбендә
бер бала туган иде.

Атасының гәүдәсен дә
шунда кертеп салдылар,
киемнәрен баштан аяк
тентеп, кармаладылар.

Итек асларына кадәр
куптарып карадылар, —
атлык түгел, чебешлек тә
акча табалмадылар.

Юкка гына тырыштылар
ямауларын да сүтеп,
юкка гына үтерделәр
зур табыш өмет итеп.

Берәүләр әйтер — үлемен
теленнән тапкан, — диеп, —
акчасы булмый торып, ул
нигә мактанган! — диеп.

Мактанган ул, олаучылар
«күрше авыл» булганга,
һәм гомер буе зарлану,
сукранудан туйганга.

Бай санаган ашарына
булса бүген бер сынык,
калганын чүпкә санаган
ярлы, баһадир сыйныф.

һәм чыннан да бай иде ул:
үз туган авылына
кайта иде гарык булып
мәхәббәт байлыгына.

Мин дә мәхәббәткә гарык...
Сөямен, халкым, сине,
Уйларың, моңнарың белән
син урап алдың мине.

Сөю җырлары... Болар бит
тик синең җырлар гына,
аларга минем каләмем
сала тик юллар гына.

Шушы юллар алып кайта
мине синең каршыңа.
Өметләнәм, очрамам дип
Гарифым язмышына.

XI

Чыкты гәүдәсе Гарифның —
җир кочып яткан иде.
Кайгылы таллары гүя
почетлы сакта иде.

Табылгач та, күмелгәч тә
онытылмады, җырлагыз,
тагын да бер бәет чыкты —
«И, яраннар, тыңлагыз!..»

... Казыган ул шахтагын,
кулына тотып лампасын;
сигез сажин җир астыннан
күрми дөнья яктысын.

Шунда забастовка куптан —
(су бит шахтада — билдән).
Судан алып, утка салып,
Сараның хаты килгән.

— Кайтыр өчен акча кирәк,
Эшкә төшәм! — дип барса,
— Төшмәгез! — дип Ворошилов
тора икән шул чакта.

Бәет әйтми — ялгышканмы,
я дөресме эшләгән,
тик стачканы бозмаган,
Гариф эшкә төшмәгән.

Шуннан берничә ай үткәч,
инде кыш җиткәч килеп,
кайткан ул йорт-җир кебеген
сатып китәргә диеп.

Әрәмә сусаган икән
менә аның канына...
Яшәүчеләр генә булсын, —
үтерүче табыла.

*Беренче кисәк бетте.*



# Очерклар

*Әдип Маликов*

## ЯКТАШЛАРЫБЫЗ ЛЕНА БУЕНДА...

### ХУҖАСЫЗ ӨЙНЕҢ ҚУНАКЛАРЫ

Моннан өч йөз ел элек Марково поселогы буласы урынга беренче нигез корып җибәргән Кирюша Марков болай дигән:

— Себер туфрагы — авыр туфрак...

Авыр. Чөнки ул туфракны тайга урманнары тамырга, ташка әвереллергән. Аңа көрәк тертүче дә булмаган. Тик аюлар гына, кар ятар алдыннан шул туфракка тырнакларын батырып, үзләренә өн казып кергәннәр.

Авыр туфрак. Чөнки Кирюша Марков шикелле башлап йөрүчеләрнең тозлы тире сеңгән, меңнәрнең тозлы яше тамган аңа. Кул-аякларын богаулап, сөргенгә озатылган «бунтарь»ларның хәләл сөякләре белән дә сугарылган бу җирләр. Мондагы кырыс, җәберле тормышка җайлаша алганы исән калган, җайлаша алмаганы башын җуйган.

— Ә бүгенге Себер сезне ничек каршы алды?

— Ипи-тоз, якты йөз белән...

Шулай дип җавап кайтарды Марковода очрашкан якташым Исхак Гыйләҗев. Урта буйлы, шат күңелле бу кеше белән без Владимир Чернозубов квартирасында таныштык. Ул аларның өйләрен саклап калган икән. Ә Владимир Әлмәткә яшь нефтьчеләр слетына киткән җиреннән һаман кайтмаган. Аның отпуска көннәре ялганып, сәяхәте сузыла төшкән. Ул хәзер семьясы белән Астраханьдамы, Кисловодскидамы ял итә дип аңлатты Исхак.

— Ә якташлардан бүген тагын кемне күреп булыр соң? — дигәч, Исхак:

— Бүген беркемне дә күрсәтмим сезгә, кич буе икәү генә сөйләшеп утырабыз, — диде. Аның шулай булачагын раслау өчен, өстәп тә куйды: — Бүген бит шимбә көн, аучыларның, балыкчыларның аппетиты котырган көн. Кайсы тайгага, кайсы шунда Тунгуска елгасы буена куна китә. Бораулаучыларның бер өлеше төнге вахтада...

Чернозубов яшәгән йорт Лена ярына терәтеп үк диярлек салынган. Елга өстендәге хәрәкәт, көзгедәге шикелле, аерым-ачык күренеп тора. Караңгы төшә, күз бәйләнә башлаган иде инде. Кайдадыр, поселокның бер читендә, дөберт-дөберт килеп, движок эшләргә тотынды. Марково поселогында гөлт итеп электр утлары кабынды...

— Менә Чернозубовның үзе утырткан ике түтәл бәрәңгесе, — диде Исхак, фонарь белән яктырта төшеп, — мин, үз рөхсәте белән, көн саен бер төбен ашап торам. Ә бүген, кунак килү хөрмәтенә, ике төп казысак та була.

Һәр төбе саен эре-эре биш-алтышар бәрәңге чыкты. Бәрәңгеләр чиста, сап-сарылар. Себер бәрәңгесе шул.

Аннары без түбәнгә, яр астына төшеп киттек.

— Хәзер голомянкада гына калды мәсьәлә, — диде якташым, агым суга карап торганы хәлдә. Мин тыела алмыйча көлеп җибәрдем: үзенең бәрәңгесе дә, тоткан балыгы да юк икән ләбаса. Бәлки табада кыздырасы үрдәге дә һавада очып йөридер әле...

— Шикләнмә, якташ, — диде Исхак, бер дә исе китмичә генә. Ул колагын елга янына борды. — Әнә, ишетәсеңме?

Каидадыр бик еракта «тук-тук-тук...» дигән авазлар кабатланды. Ул торган саен көчәя барды. Аннары кинәт тынып, югалып калды. Исхак фонарен баш очына куеп, ниндидер сигналлар бирде.

Тәмам караңгы төшеп өлгерде. Гудок авазлары белән тайга киңлекләрен яңгыратып, буксир пароходлары уза. Аларның зур тәгәрмәчләре чап-чоп килеп, каен миллек белән чабынгандагы шикелле, суны чәбәкләп баралар. Елганың бер ягыннан икенче ягына ай юлы сузылган. Әнә шул күз камаштыргыч көмеш юлдан теге як ярга кадәр атлап китәсе килә.

«Тук-тук...» авазлары бик якында гына ишетелделәр. Ул да булмады, нәкъ безнең турыга моторлы көймә килеп туктады.

— Әй, парня, голомянкамы, налиммы?

— Голомянка, — диюгә, йомшак ком өстенә ниндидер алсу нәрсәләр килеп төште. Алар лаштыр-лоштыр сикерешергә тотындылар.

«Голомянка» дигәне дә балык икән. Мин, кызыксынып, берсен кулыма алып карадым. Тәнкәләре юк, чистартырга да кирәкми. Үзе алсу төстә, йөзгечләре кош канаты шикелле, зур... Ул арада көймә «тук... тук...» итеп китеп тә барды.

— Эвенк карты, — диде Исхак, балыкларны җыеп, сеткага тутыргач. — Кич җитсә, маяклар кабызып йөри. Балыктан өзелми, үрдәк атарга да оста. Ә акча бирсәң — үпкәли. Тиешлесен миңа хөкүмәт түли, ди.

— Лена елгасы туңып, пароходлар йөрүдән туктагач, син аны язга кадәр күрә алмыйсың, — диде Исхак, — үзенә генә таныш сукмаклардан ерак тайга эченә, Тунгуска елгасы буена китеп югала. Аның кайда йөргәнлеген беркем дә белми. Аннары кыйммәтле кеш тиреләрен елкылдатып, дөньясыннан бик канәгать булып, кайтып керә.

Без кыздырган голомянка балыгы һәм Себер бәрәңгесе ашап, Чернозубовлар әзерләп калдырган тайга вареньеләрен мактый-мактый чәй эчеп, шактый озак сөйләштек.

Голомянка дигәнең бик тәмле нәрсә икән, түзмәдем:

— Каян тота ул моны, Ленаданмы? — дип сорадым.

— Юк, — диде якташым, — бу балыклар фәкать Байкал күлендә генә үрчиләр. Алар Ленада да, Тунгускада да юк. Менә каян тотадыр ул, анысын әйтми, сер итеп саклый...

Исхак аннары бирегә ничек килеп җитүләре турында сөйләде.

— Әлмәттән утыз семья май ахырында кузгалып чыктык, — диде ул, — безне язның беренче чәчәкләре белән, бик шәплэп озаттылар. Бөгелмәдән Казанга кадәр самолетта очтык. Аннары поезд белән Мәскәүгә. Башкалада ике тәүлек буе кунак булдык, театрларын, музейларын карадык. Аннары Мәскәү—Лена поезды безне Лена станциясенә китереп төшерде. Ике бригадага ике саратский гармонь. Вагонда юл буе җыр өзелмәде. Лена станциясендә безне оркестр белән, ә Марково поселогында ипи-тоз, якты йөз белән каршы алдылар.

Болай коры гына сөйләүдән Исхак үзе дә канәгать булмады шикелле. Бераз уйланып торганнан соң, каяндыр табып алып, кулыма бер фоторәсем тоттырды.

...Лена елгасы буенда сабан туе ясарлык халык җыелган. Яр читендә унлап самовар пар бөркеп утыра. Самоварлар тирәсендә пароходтан төшүчеләр, Марково кешеләре белән бергә, чәй эчеп утыралар. Сандык, чемодан өстенә менеп баскан малай-шалайлар, гармонь тоткан егетләр... Кемдер су коена, кемдер балык тота...

— Кайчан булды бу хәл?

— «Аккош» теплоходыннан Марково туфрагына төшеп аяк баскач, безнең өчен менә шулай сабан туе оештырдылар...

Ләкин тормыш сабан туеннан гына тормый шул. Бигрәк тә өйрәнелмәгән җирдә, Себердә. Торак йортлар өлгергәнче, безнең якташларга, җир идәнгә басып, палаткаларда яшәргә, яр буена таган асып, учакта аш пешерергә, йолдызлар астында төн уздырырга туры килә...

Исхак башка бер фотоны сузды миңа. Яр буена үзйөрешле баржа килеп туктаган. Баржадан, кечкенә күтәрү краны ярдәмендә, кирпеч бушаталар. Ә җирдәге кирпеч өемнәреннән поселок ягына таба, «тере» чылбыр булып, балалар тезелеп киткән. Һәммәсе ялан өс, трусиктан гына. Кулларында — кирпечләр. Рәсемгә карап, шул кирпечләрнең күчеп баруын тоясың.

— Балалар өмәсе, — диде якташым, — Татарстаннан килгән семьялар өчен торак йортлар төзегәндә, бөтен Марково халкы ярдәмгә килде...

Ә өченче рәсемдә Исхакның үзен һәм Владимир Чернозубовны танып алдым. Алар кулларына балта тотканнар, салынып ята торган агач йортның икенче катында бүрәнә юналар. Рәсемнең астында: «Вахтадан соң бил язу» — дип язып куелган. Мин Владимир язган почеркны таныл:

— Мондый фотолар күпме аңарда? — дип сорадым.

— Бер кочак. Ул бит бирегә килгәч, фототүгәрәк оештырып җибәрде. Иркенләбрәк карарбыз әле, бүген түгел...

Кембри токымнары белән көч сынашырга ашкынып килгән Татарстан бригадаларына беренче көннән үк үзләре теләгән, яраткан эшләренә тотынырга туры килми. Сары чәчле, ай кебек түгәрәк йөзле, урта яшьләрдәге инженер — Лена экспедициясе начальнигы Шалагин картадан аларга ике нокта күрсәтә. Берсе — Лена аръягында, таш кыя итәгендә. Икенчесе — нефтьчеләр поселогыннан биш километр ераклыкта, тайга эчендә. Безнең якташлар менә шушы урыннардан кембри нефтенә юл ача башларга тиеш булалар. «Ягез, кемгә кайсы нокта?»

— Икесе дә авыр участоклар, — ди Шалагин. — Лена аръягына, вахта алмашынган саен, «амфибия»ләргә төялеп чыгарга, төзү материалларын баржалар белән китерергә туры киләчәк. Көз көне, елга өстенә шуга калка башлагач, боз ныгып өлгергәнче, семьяларыгыздан аерылып яшәргә туры киләчәк.

Ә бу яктагы «нокта»га килгәндә, аның юлын агым су түгел, миллион яшьлек тайга урманы бүлеп үтә. Кул тимәгән, аяк басмаган тайга эченнән юл ярып үтәргә кирәк. Димәк кембригә юл агач кисүдән башлана.

— Ни булса, шул булыр, — ди, бервакытта да аптырап калмый торган Чернозубов, — әйдә шобага тотышыйк!

Шобага саласы көнне бригада членнары, аларның семьялары, экспедиция җитәкчеләре — һәммәсе контора ишек алдына килеп җыела. «Болельщик»лар ике төркемгә бүленә: Чернозубов һәм Травин яклылар. Әлбәттә, Лена аръягы бәхетлерәк булачак. Аңа юл саласы юк. Кыш җитсә, елга өсте бозланып ката. Тракторыңны да, әллә ниеңне дә күтәрә. Тамаша карарга җыелган бала-чага да:

— Безгә Лена аръягы! Лена аръягы! — дип кул чәбәкләп тора.

Владимир, озын тал чыбыгы тотып, Александр янына килә. Йодрыклар алмашынган саен, тал чыбыгы аска төшә бара. Һәм менә мастер Травинның йомарланган кулы — иң өстә...

Травин бригадасы Лена аръягында бораулларга тиеш булып чыга.

Сөйләшеп утыра торгач, Исхак икенче як бүлмәдән тагын фоторәсемнәр алып килде.

...Чылбырлы зур тракторларның, бульдозерларның тайгага һөҗүм

иту моменты. Танкка охшаган трактор юан наратны «җилкә»се аша аударып җибәргән. Икенчеләре дә шулай иткәннәр. Бульдозерлар агач төпләрен актарып-актарып ташлаганнар. Монда кулына балта-пычкы тоткан кеше күренми дә. Разведчиклар кулына куәтле техника бирелгән.

— Кирюша Марков, мәңгелек йокысыннан уянып, бу хәлләргә бер күз салса, мөгаен исе-акылы китәр иде,—ди Исхак, үзе дә гаҗәпләнеп.— Ышанасызмы, унбиш көн эчендә тайганы штурмладык та куйдык!

Җиргә борауны батырганчы, буровойның үзен төзи-төзи дә өч-дүрт ай чиләнергә туры килә безнең якташларга.

— Әлмәт буровойларын сагынган чаклар еш була, — дип куйды Исхак, җилкәсен кашып, — беләсез инде, анда бер скважинаны бораулап бетермисең, сиңа, табада пешкән пәрәмәч шикелле, икенчесе әзер булып тора. Күч тә, дөбердәтеп бораулый башла. Ә монда елына бер скважина бирә алсаң, анысына да шөкер...

Әлмәттән китүенә үкенә, ахры, дигән уй туды миндә якташым турында. Аларның анда иң үзәктә, техника йорты янында гына өч бүлмәле квартиралары калды. Газы, җылы ваннасы... Өстәвенә, Исхак кечке нефть институтында укый башлаган иде. Сынар өчен генә булса да, бу турыда сорап та куйдым.

— Сагынуын сагындыра, ләкин китүемә үкенмим, — диде ул, бераз кырысрак тонга күчеп, — һөнәрем буенча мин бораулаучы. Җир байлыгын ачучы-разведчик. Бу нәрсә минем каныма сеңгән...

Исхак куен кесәсеннән таушала башлаган блокнот чыгарды, блокнот арасыннан парлап төшкән ике малай рәсемен алып күрсәтте:

— Менә, — диде ул, елмаюын тыя төшеп, — зурысы Миңлебай нефть мәйданын ачкан чакта туды, Иркен дигән авылда. Шуның хөрмәтенә Ирек дип атадык малайны. Икенчесе Сөләй мәйданын бораулаганда дөньяга килде. Сәлим куштык...

Дулкынланудан ахры, якташымның тавышы калтырана төште:

— Өченчесе кыз булса, Лена исемле кушарга җыенабыз. Лена буйларының бер истәлеге булып, биографиябезгә керсен... Ә җылы ваннага ябышып ятсаң, яңа нефть мәйданнарын ачып булмый бит, туган. Җир шары ул безнең өчен үзе менә дигән квартира. Шагыйрь әйтмешли, яшәү өчен аны җайлаштыра белергә генә кирәк.

Исхакның семьясы Лена буендагы Казарка поселогында яши, иптәше Зәйтүнә анда врач булып эшли икән. Үзе бирегә вакытлыча тулай торакка урнашкан, атнага бер тапкыр Казаркага семьясы янына кайтып йөри. Якташым тиздән үзенең дә шунда бораулау мастеры булып китәчәген әйтте. Институтта укуын да җайлаган. Аны Мәскәүдәге Губкин исемендәге нефть институтына күчергәннәр. Теләсә — берничә ай Мәскәүгә барып укырга, ә производство практикасын бирегә үткәрергә мөмкин икән.

Сөйләшеп утыра торгач, Чернозубовның Татарстаннан истәлеккә алып килгән самоварын тагын бер яңартып алдык. Голомянка балыгын да тагын авыз иттек. Якташым Лена елгасы ягына караган тәрәзәне бөтен иңенә ачып җибәрде. Бүлмә эченә саф һава, эрбет чикләвеге исе, ылыс исе бөркелеп керде.

Исхак, утны сүндереп койкасына авуга, йокыга китте. Минем күземә йокы кермәде. Аның турында уйланып яттым. Колачын бөркет шикелле киң җәеп яшәргә өйрәнгән ул. Бер ул гына түгел, Чернозубов та, Травин да, бирегә килгән башка иптәшләр дә шундый, күрәсең. Алар үзләренең адымнарын Ил адымы белән үлчиләр. «Җир шары ул үзе безнең өчен менә дигән квартира... Бер улым — Миңлебай мәйданын ачканда туды... Өченчесе кыз булса...» Кара син аны!

Девон мәйданнарын яңа ача башлаган чорда Исхак Әлмәттәге бораулау конторасына ат караучы булып кергән. Һич гаҗәп түгел бу. Ул чагында контораның үз конюшнясы булган, бер көтү ат асраганнар. Чөн-

ки вахталарны атка утыртып ташыганнар. Исхак контора директорының кучеры да булып эшләгән икән әле. Асфальт юллар салынгач, атларның кирәге беткәч, аны бораулау бригадасына өйрәнчек итеп алганнар. 1954 елдан башлап ул Владимир Чернозубов белән бер бригадада эшли башлаган. Димәк, күптәнге дуслар.

## ТАЙГА ҚОРИДОРЫНДА

Иртәнге салкыннан калтыранып уянып киттем. Исхакның койкасы буш, үзе юк, ә чалбары белән күлмәге урындык башында эленеп тора иде. Ачык тәрәзә янына килүгә, якташымны өй алдында күреп алдым. Ул трусиктан гына физзарядка ясый, бронзадай тәнендә мускуллар уйнап тора.

— Өйгә карак кергән бит, малай, — диде Исхак, мине күрүгә елмаеп, — бер песи йөри монда, табада калган голомянка башларын гына ашап чыккан, зыян юк алай.

— Ике аяклы карак булмагач, анысына түзәрбез инде.

— Андыйлар монда йөрми, — диде якташым, җирдә яткан ике потлы герне уң кулына алып, — аларны бик тиз таныйлар бирәдә. Ә менә дүрт аяклы каракларның хәтәрләре бар.

Герне бер күтәреп, бер төшереп маташкан арада, ул сөйләп тә алды:

— Узган ел кар иртә яуды. Йокыга китәргә өлгермәгән аюлар, тайгада азык беткәч, колхоз фермасына «визит» ясадылар, бозауларны ботарлап киттеләр. Көпә-көндез безнең ашханәгә дә килеп йөрделәр.

Мин эчемнән генә санап торам: герне инде ул егерме биш тапкыр җирдән алды, кызарына-бүртенә башлады, сөйләвеннән дә туктады. Тик ахырдан, бераз хәл җыйгач кына әйтеп бетерде:

— Марково этләре җәнҗал куптардылар, чалыш аякларның эзләре суынды аннары...

Иртәнге зарядкасын тәмамлау белән, Исхак Лена елгасына төшеп чумды, ерактан ук әйләнеп бер йөзеп килде.

Ул иртәнге сәгать тугыздан вахтага басарга тиеш икән. Без Лена елгасы буйлап, тар сукмактан буровойга таба юл тоттык. Елга өстеннән ак томан күтәрелеп килә. Ә күк йөзе аяз, зәп-зәңгәр. Кояш нурларыннан күз чагыла. Ләкин аларның әле бер нинди җылысы юк. Иртәнге коры, янгыравыклы салкын.

Берничә йөз метр үтүгә, сукмак уртасына футбол тубы сыман түгәрәк җан иясе чыгып утырды. Күзләре, такси сигналы шикелле, яшелле-зәңгәрле. Ябалакныкына охшаган башы йөнтәс гәүдәсенә сеңеп бетә язган. Ничектер, миңа шомлы, куркыныч булып китте. Якташым җиргә тибеп:

— Пр-с-с! — диюгә, йөнтәс шар яшен тизлегендә юкка да чыкты.

— Бүген безнең хәлебезне белеп йөргән «әүлия» шул инде, — диде Исхак, серле елмаю белән. — Марково кешеләре аны изге песи дип йөртәләр. Моннан ике ел элек поселокны янгыннан коткарган, имеш...

— Янгыннан?!

— Әйе. Сөйләсәң — тарихы дилбегә буе. Иркенләп бер сөйләрмен әле. Ул тарих беренче номерлы кембри скважинасы белән бәйле. Тиздән күрербез аны.

Сукмак безне, елга күренешләреннән аерып, уңга алып китте; ул киңәя-киңәя, соры тузан, ком каплаган юлга әйләнде. Поселок кырыена килеп чыктык. Анда Лена экспедициясенең машиналар паркы урнашкан икән: зур танк кадәрле тягачлар, коры җирдә дә йөри, суда да йөзә торган амфибияләр, бульдозерлар, әллә ничәмә тонна йөк сыйдырышлы самосваллар — бер көтү!

Паркның нәкъ уртасында нефть скважинасы утыра. Аны ике яктан юан-юан нарат агачлары белән кыстырганнар да, бүрәнә башларын

шундый ук юан, таза баганаларга беркеткәннәр. Дөресрәге, бу скважинаны, әкияттәге дию шикелле, җиргә бораулап куйганнар.

— Кембри авызы менә шушы инде, — диде Исхак, адымын акрынайта төшеп, — егерме көн буе үкереп фонтан аткан. Без дә бит бирегә шуның тавышын ишетеп килдек.

Якташым, ничектер, һәр күренешне әкият сыман итеп тоя белә. Ләкин серле йомгакның очын гына күрсәтә дә, сүзне башкага борып җибәрә. Калганын инде үзеңә сүтәргә кала. Теге муенсыз песинең, әйтик, беренче номерлы скважинага нинди катнашы бар икән?

Машиналар паркын узуга, тайга коридоры башланды. Ул, аз гына борма ясап, тау ягына таба сузылган. Киңлеге утыз метрлар чамасы булыр. Коридорның алгы очында буровой вышкасы калкып тора. Ул биредә ялгыз түгел. Мондый вышкалар Лена елгасы буенда да күренә.

Коридордан тракторлар йөри, күрәсең. Юл трактор табаннары белән сырланып беткән. Ян-якта — актарылган тамырлар, төпләр өеме. Алар диңгез төбендәге медузалар шикелле, кармавычларын еракка сузганнар. Биек нарат очларында тиеннәр сикерешеп уйный. Ә җирдә аунап яткан ботакларда яшькелт-сары төстәге җәнлекләр — борындыклар йөгерешә. Сызгырырга бик оста икән үзләре.

— Хәзер Мөхсинов Мәхмүт вахтасы эшли, — диде Исхак, буровой ягына колак салып, — нишләптер тынып калганнар... Инструмент күтәргәннәре дә күренми.

Якташларыбыз турында ул кызык кына нәрсәләр сөйләп алды. Башта Чернозубовны искә төшерде.

Владимир, Марково туфрагына аяк басу белән, оркестр оештырырга тотына. Музыка кораллары да, уйнаучылары да табыла. Украинлы Бодайбах дигән бораулаучы үзенең гитарасын, грузин Лепсберидзе чомбуриен кулына ала, Себер егетләре берничә балалайка табып китерәләр. Болар янына тагын якташларыбызның саратский гармоньнары кушыла. Җәйге кичләрдә, Лена елгасы буенда, бүрәнәләр өстенә утырып, көн саен репетиция ясыйлар. Ләкин бу хәл экспедиция начальнигының ачуын гына кабарта.

— Әле клуб салынмаган, бораулый башламагансыз, күңел ачудан тотындыгыз, — ди ул, Чернозубов белән бәхәскә кереп. Владимир якташлары исеменнән туры җавап бирә:

— Без аю өнендә яшәргә килмәдек. Әле Иркутскидан тынлы оркестр кораллары да китертергә уйлыйбыз. Күңелләр уртак җыр, уртак моң тапса, тормышыбыз да алга барачак. Буровой да гөрләп торыр, клубы да тизрәк салыныр.

Чыннан да, нефтьчеләр поселогында яңа клуб Чернозубов инициативасы белән салына башлаган икән. Яше-карты, бала-чагасы дәррәү кубып, өмәгә чыккан. Мөхсинов Мәхмүт кырык километрдагы кирпеч заводыннан, моторлы көймәгә төяп, кирпечен алып кайткан...

Исхак мастер Чернозубовның яратып әйтә торган сүзләрен искә төшерде:

— Башыңа идея кунса, очырып җибәрмә, аягыннан тот. Ычкындырмасаң — ботка пешерергә була аннары.

Владимирның жаны-тәне белән җәмәгать кешесе икәнлеген мин Әлмәттә үк белә идем. Ул икенче бораулау конторасында комсомол комитеты секретаре булып берничә ел рәттән сайланды. Анда үзешчән сәнгать коллективын аякка бастырды, үз квартирасында бораулаучы балалары белән фототүгәрәк оештырып җибәрде...

— Бала туса, исем кушарга Чернозубовны чакырабыз инде, — диде Исхак, көлемсерәп, — үзе дә вакытым юк дип тормый, мулла шикелле, килә дә җитә.

Якташым аннары бораулаучы Мөхсиновка да берничә сүз белән характеристика бирде:

— Кирәк бит чудакланырга, узган ел җәй, кечкенә калибрлы мылтык белән тайгага чыккач, аюга очрый бу. Ерткычның колак тишегенә атып тидерә, миңгерәүләндерә. Аннары пычак белән ташлана аюга. Үгез суярга аны чакыралар, мөгезләреннән тотып, бер үзе ега ул үгезләрне. Бирсгә килгәч, комсомолның Иркутск өлкә конференциясендә катнашты. Мастер булырга әзерләнә.

Мәхмүт турында якташым яратып, горурланып сөйли:

— Чернышевский әсәрләре белән мавыга башлады. Аның Иделдә туып, Лена елгасы буйларында сөргеп елларын кичергән булуын белгәч, Николай Гавриловичның рәсемен табып, рамга утыртты...

Баш очыбыздан гына зур корсаклы, нечкә койрыклы вертолет очып узды. Кешеләре күренеп бара. Вертолет, буровой вышкасы турысына җиткәч, ике тапкыр әйләнеп, зур түгәрәк ясады. «Кунарга» урын тапмады, күрәсең. Җиргә ниндидер төргәк ташладылар. Төргәк дигәнебез сүтелеп, баскычка әверелде, һавада асылынып калды. Вертолет бер урында «таптанып» торган арада, бау баскыч буйлап, ак халатлы берәү төшә башлады.

— Буровойда «ЧП», киттек! — диде Исхак, һәм авыр итекләре белән лап-лоп йөгерергә тотынды.

Ак халат җиргә төшеп, күздән югалуга, баскычны җыеп алдылар. Вертолет үз җае белән генә Лена елгасы ягына очып китте.

Без хәлдән таеп, буровойга барып җиткәндә, культбудка янында бер төркем кешеләр өелешеп тора иде. Җиргә соры юрган җәйгәннәр, юрган өстенә озын, таза гәүдәле берәүне сузып салганнар. Аның кара бөдрә чәчләре маңгаена ябышкан, йөзе ап-ак.

Майлы комбинезон кигән ике ир, авыруның ике ягына тезләнеп, аның кулларын хәрәкәтләндерәләр, ясалма сулыш алдыралар. Ә күктән төшкән ак халатлы хатын-кыз аңын җуйган кешенең муен тамырларын капшап, массаж ясый, борынына дарулы мамык иснәтә...

— Мөхсинов... нидер булган, — диде Исхак, минем янымнан узышлый, борчулы тавыш белән, — бирешмәскә тиеш, нык токымнан...

Әле генә аның турында сөйләнеп килгән идек бит, күп кирәкмени кешегә. Менә сузып та салганнар үзен. Үз-үземә урын таба алмыйча, аптырап калдым мин. Ә врач исә бик тыныч кына эшен дәвам итте, салкын су сорап алды, авыруның маңгаен, иреннәрен чылатты...

Мөхсиновны уратып алган төркем кинәт кузгалышып куйды. Кемдер йөрәк тавышы белән дәште:

— Мәхмүт!

Күзләрен зур итеп ачкан Мөхсинов күк йөзенә карап ята бирде. Аның күзләре зәп-зәңгәр. Әллә аларга күк зәңгәрлеге төшкәнме?

Авыру терсәкләренә таянып, торып утырды. Әле генә аңа ясалма сулыш алдырып маташкан иптәшләренә хәлсезләнгән тавыш белән ул сорау бирде:

— Митя, привентерны яптыңмы?

— Шунду-у-к, — диде тегесе, шатлыгыннан кабаланып, — газ исен тою белән шалт!

Һәммәсе берьюлы җиңел сулап куйды. Мөхсинов торып, аягына басуга, йөзләреннән курку китәргә дә өлгермәгән дуслары шаярта да башладылар:

— Сөйлә, Мәхмүт, нинди төш күрдең?

— Кембри бабай нәрсә диде, нефть була дидеме?

Мөхсинов ничәмә ир арасында бер үзе торган «ак халат»ны күреп алуга, тиз генә корсагын япты, спецовкасын каптырды. Аннары күзен йомды, уң кулының бармагын борын очына тəп-төгәл китерде дә елмаеп әйтте:

— Нервлар тәртиптә, доктор, подшипниклар да үз урынында, китәргә мөмкинме?

Ә доктор, бораулаучыларның һәммәсе белән саубуллашканнан соң, көләч йөзле авыруны култыклап, «вездеход» машинасына таба алып китте. Мөхсинов егетләре дә алар артыннан калмады.

Вахтаны бораулаучы Гыйләҗев һәм аның иптәшләре алмаштырды. Саклык өчен противогаз киеп алган Исхак, идарә пульты янына басып, тормоз рычагына кул салуга, авыр механизмнар берьюлы хәрәкәткә килделәр. Тайга кинлеге өстеннән башын калкыткан буровой вышкасы сизелер-сизелмәс кенә калтырана башлады...

## ҖЕННЕ БУТЫЛКАДАН ЧЫГАРСАҢ

Ике-өч көн эчендә мин Марковоның аркылысын-буен йөреп чыктым, аның һавасы белән сулый башладым.

Лена экспедициясе сала башлаган яңа поселокны интернационал поселок дип йөртәләр. Биредә егерме төрле акцент белән сөйләшәләр, төрле көйләргә моңаялар, ә кайгы-шатлыклары уртак, борчулары бер. Әгәр яңа бораулаңган скважина нефть бирсә, аның өчен һәммәсе шатлык кичерә, бөтен поселок, зур бәйрәмнәрдәге шикелле, тантана ясый.

Марково гынамы? Иң әүвәл Иркутск трестына телеграмма оча, эфирда радио позывнойлары пипелди башлый. Ун минут та үтми, «гаепле» бригаданың мастерын яки соңгы вахтада эшләгән бораулаучыны Мәскәү телефонга чакырып ала. Бераз карлыга төшкән, дулкынланудан калтыранган таныш тавыш ишетелә:

— Кем бу, Георгий Иванович Сокольниковмы? Ә... ялгыштыммыни? Мөхсинов дисез. Тәк-тәк... Бик шат сезнең белән танышуыма. Күпме тирәнлектән бирде нефть? 2160 мегрдан дисезме? Бик яхшы. Кан басымы ничек Кембри картның? Ике йөз атмосфер дисезме? Ох-хо! Менә нәрсә, туганкай, вахтадагыларны минем исемнән кысып-кысып кочаклагыз. Марковога тиздән үзем киләм...

Владимир Чернозубов бораулаган тәүге скважина шатлык китергәннән соң, нәкъ шундый сөйләшү булып ала. Фәннәр докторы, академик Сенюков үзе кушкач, Мөхсинов инде анысын гына үти: боксер перчаткасыдай куллары белән иптәшләренең кулларын кыса, кабырга сөякләре шытырдаганчы, күзләреннән яшь китергәнче кочаклый аларны.

Ә менә хәзер машиналар паркы уртасында калган беренче скважина фонтан биргәндә кичерешләр башкачарак була. Шатлыгын да, кайгысын да, дөнья кадәр мәшәкатьләрен дә бергә җыйнап китергән ул. Егерме көн, егерме төн үкерә ул беренче кембри фонтаны. Поселок өстендә егерме тәүлек рәттән алсу куе нефть яңгыры койган. Җил аны төрле якка боргалап йөрткән, Лена өстенә яудырган, тайганы нефть белән коендырган. Ялгыш кына ялтырап киткән металл чаткысыннан тирәюньне ут вулканы чолгап алырга әзер торган. Янгын сүндергеч бомбалар аскан самолетлар, вертолетлар тәүлекләр буе Марково күгендә очып йөргәннәр. Яңа поселокта яшәүчеләр, йорт-кураларын ташлап, Лена аръягына күченгәннәр...

Себер бораулаучысы Георгий Сокольников миңа беренче кембри фонтанының тарихын бөтен ваклыклары белән сөйләп бирде.

1962 елның 18 март иртәсе — Советларга сайлаулар көне. Марково өстендә ал байраклар җилферди. Лена экспедициясе янындагы буровой башына да байрак элгәннәр. Ул, текә кыя өстендәге учак телләредәй, ерактан калкып күренә.

Лена елгасы буйлап җил исә. Яңа эзләр салынсын өчен кичәге юлларны, сукмакларны себерә җил. Ул сайлау участогына ашыгучыларның битләрен кытыклый, колакларын чеметкәли. Кароттаж отрядының техник операторы Виталий Ефименко бу көнне гадәттәгедән иртәрәк уяна, Мәскәүдәге Наташасы яраткан ак күлмәген кия, ефәк галстугын буа.

Сайлауга ул беренче булып килә, беренче булып тавыш бирә дә күршедәге буровойга юнәлә.

Георгий Сокольников вахтасы эшли бу вакытта. берсеннән-берсе таза ирләр скважина коесына инструмент төшерәләр. Идарә пульты янында кабарып торган кара мыеклы, киң кашлы ир уртасы кеше — Сокольников үзе була. Буровой күперенә аяк басу белән, Виталий аңардан:

— Әллә бензин белән маташтыгызмы? — дип сорый.

— Андый нәрсә булганы юк, — ди тегесе, бәйрәмчә киенгән операторга сәлам биреп, — үзем дә аңламыйм, баш чатный, тын кысыла башлады.

Оператор Ефименко үзе белән йөртә торган махсус прибор ярдәмендә скважинаның хәлен тикшереп, нәтиҗәсен белдерә:

— Андый-мондый гына ис түгел бу, иптәшләр...

Ул, сүзен дәвам итә алмыйча, шатлыгыннан елмаерга, көләргә тотына.

— Нефть газы бу, туганнар, кембри төбеннән күтәрелә...

Ефименко вахтадагыларга сак булырга куша, культбудкага кереп, экспедиция җитәкчеләренә шалтырата. Сокольников вахтасы трубалар төшерүне дәвам иттерә.

Оператор бер читкә китеп, уйга кала. Әгәр чыннан да нефть чыгып куйса? Бүгенге бәйрәмгә тагын бер ямь өстәлә? Булыр микән андый бәхет?

Ул менә ничә ел инде, Себер разведчиклары белән бергә, тайга киңлекләрен айкап йөри. Байкал әйләнәсен капшап чыктылар, Тайшетта, Ангара буйларында булдылар. Жигаловода, Георгий Сокольниковның туган җирендә, ике скважина бораулап карадылар. Сазлыклар аша үзләре юл салдылар, үзләре вышка кордылар. Йокысыз төннәр булды, машиналарга төялгән буровой җиһазлары сазга батып ятты. Тәнгә ябырыла, күлмәк аша әллә кайларга үтеп керә торган гнуслардан — хәшәрәт черкиләрдән талаттылар үзләрен. Мәрмәрен, руда катлауларын, доломит плиталарны тишеп үттеләр, җир куышларына барып чыктылар, өч мең метрга кадәр тирәнлеккә төштеләр... Әмма, дүрт күз белән көткән кембри нефте урынына, тозлы су фонтаны гына бәреп чыкты.

Аннан, баржаларга төялеп, Лена буйлап, Осетровога килделәр. Шундый ук шартларда дүрт скважина борауладылар... Аларына да кул селтәп, тагын күчenделәр. Марково туфрагына килеп аяк бастылар. Бар микән соң ул — кембри нефте? Бәлки, ул Сенюков шикелле дуамал галимнәрнең фантазияседер?!

Мәскәүдә калган җылы почмагыннан, семьясыннан читтә биш ел буе ул «аю тормышы» белән яшәде. Аюларга нәрсә, алар шулай яратылган, тиреләре калын, тырнаклары үткен. Себер салкыннары житсә, агач тамырлары астына өн казып керәләр дә, кыш буе табаннарын суырып ята бирәләр. Илле градуслы әче салкыннар да үтми аларга. Ә нефтьчеразведчиклар кышын да, җәен дә аяк өстендә үткәрәләр. Виталий үзе өчен генә борчылмый. Менә бораулаучы Георгий Сокольников белән инде биш ел буе бергә, бер кашыктан диярлек ашап йөриләр. Аның хатыны, дүрт баласы бар хәзер. Алар да Георгийның язмышын уртаклашалар, чегән тормышы белән яшиләр. Сокольников — утлар-сулар кичкән кеше, кат-кат яраланып, кат-кат сугышка кергән. Туган ил аның күкрәгенә алты орден кадаган. Гвардия старшинасы, разведчик Георгий Сокольников погоннарын салгач та антына туры кала: ул иксез-чиксез Себер буйлап разведкага — байлык эзләргә чыга.

Виталий, уйларыннан айнып, Сокольниковның күзләренә карый. Дустының көләмсерәп торган соры күзләре арыганнар, аларда бер моңсулык бар...

Забойда хәзер алтмыш труба. Тагын унны төшерәсе бар. Ә бензингә

охшаган ис һаман борынны кытыклый, баш әйләнгәндәй була. Алмашка атаклы бораулаучы Иван Фандеев вахтасы килеп житә. Газ белән агуланмас өчен, чиратлап эшли башлыйлар. Ун минут саен вахталар алмашынып тора. Туя белмәс скважина авызы соңгы трубаларны йота. Тагын өчәү генә калган... Шушы микән инде бәхет капкасы! Кеше белән бәхет арасы менә шулай якыная торгандыр инде. Чыннан да, беренче булып, кембри нефтенең пробасын алу нинди зур бәхет булыр иде. Виталийлар, Сокольниковлар гына түгел, моның шулай булуын һәммәсе тели. Марковоның штансыз малайларыннан алып, чал картларына кадәр — һәммәсе, һәммәсе. Академик Сенюков студент чагыннан башлап, бөтен гомерен Себер нефтен эзләүгә багышлаган. Әгәр мондый бәхет килсә, Виталий Мәскәүгә ике телеграмма бирәчәк. Берсе — академик Сенюковка, икенчесе сөйгән хатынына.

Менә соңгы труба забойга төшеп утыра. Хәзер цемент кудыра башларга кирәк. Кинәт скважинадан җил сызгырган аваз ишетелә, аннан ул давыл улавына әйләнә, паровоз шикелле үкерергә тотына... Көчле газ басымы тоз һәм балчык эремәләрен җир астыннан кире куып мендерә. Ике километр тирәнлектәге забой эченә тулган барлык сыекча фонтанга әйләнеп, һавага атыла. Буровойдагылар кайсы кая читкә сибеләләр...

Виталий улакларга күз төшерә. Эремә өстендә тимгел-тимгел май таплары... Урра, май таплары! Нефть тамчылары!

Фонтан көчәйгәннән-көчәя бара. Буровой эчендәге корыч канатлар, кайнар учак көленә төшкән елан шикелле, үрле-кырлы сикерешәләр, якякка сугылалар. Биек вышка бөтен гәүдәсе белән калтырана, верховой сәндерәсенең такталары һавага оча...

Нефть! Виталий учак янына атыла, куе алсу сыекчаны бүреге белән чумырып ала да кире йөгерә. Ул аны тиз генә шешәләргә бушатып, кароттаж будкасына озата. Проба тагын кирәк, тагын... Монысы лаборатория өчен. Аннан Иркутскига җибәрү өчен, Мәскәү өчен...

Икенче тапкыр керүендә Виталий үз аяклары белән чыга алмый. Ул көчле фонтан ташкынына эләгә. Аны Сокольников табып алып чыга.

Һавага әчкелтем йод, бром исләре тарала. Нефть карны яндыра, үзенә канаулар ярып, Лена елгасына омтыла. Мондый әкәмәтне гомергә күрмәгән Марково этләре, койрыкларын кысып, тайга эченә чабалар, кешеләр Лена аръягына күченә башлый. Ләкин разведчикларга чигенергә ярамый.

Җирне бораулау, нефть фонтаны ачуга караганда, аны ябу хәтәррәк икән. Гарәп әкиятләрендәге шикелле, ахыры ни белән бетәрен сизмичә, җенне бутылкадан чыгарсаң... Ә бу соң бутылкадагы җен генәме?! Ул сыек атомнар, биш йөз миллион ел буе җир кабыгы эчендә, таш капчыкта ятып, әзме энергия туплаганнар!

Аңын җуйган Виталий Ефименконы Лена аръягындагы медицина пунктына озаталар. Сокольников та хәлсезләнә, аның таныр лык җире калмый. Марково халкы башына килгән бөтен бәлаләр өчен, нигәдер, ул үзен гаепле итеп сизә. Сокольников вахтасы чыгарды бит бутылкадагы җенне... Хәле ничек икән соң оператор дустының?

Бу тарихны, башта әйткәнемчә, Георгий Сокольников үзе сөйләде миңа. Ул аны бүленә-бүленә сөйләде. Без аның квартирасында утырдык.

Георгийга дүрт яктан дүрт баласы килеп сарыла. Ике малае аның кулларына килеп асылына, өченчесе җилкәсеннән кочаклый. Ә иң кечесе, кыр казлары тәпи алып килгәнче шуышып йөрергә тиешле нәни кызы, гел әтисенең алдында булды, әтисенең мыегы белән мавыгып утырды.

— Фонтанны ничек яптыгыз соң? — дип сорадым мин Сокольниковтан.

— Хәйләсен таптык инде, — диде ул, артык исе китмәгәндәй генә, — тик башта обсад трубасына арматурасын кидерә алмый азапландык. Нефть ташкыны һич якын китерми, арматураны бәрә дә җибәрә. Иркут-

скидан махсус җайланмалар ясап китергәнче шактый вакытны югалттык.

Минем тел очымда гына тагын бер сорау тора. Әйтсәң дә уңайсыз кебек. Теге муенсыз песинең ничек итеп Марковоны һәлакәттән коткаруы турында инде. Шулай да сорарга булдым.

Сокольников һәм табын әзерләп йөрүче хатыны Анастасья икесе берьюлы елмаешып куйдылар.

— Эш бит менә нәрсәдә, — диде аннары Георгий, мыегын сыпыргалап, — скважинадан газ бәрә башлагач, ыгы-зыгы арасында, эшләп утырган электр движогын сүндерергә онытканбыз. Тагын берничә секунд үтсә, мотор очкыныннан газ шартлап, зур янгын чыгачак иде. Будка эчендәге движок, нindидер тылсымлы көч белән, үзе сүнде. Соңыннан кереп карасалар, сез күргән әнә шул «әүлия»ны табып алдылар. Мескен, куркуыннан чабып кергән дә будкага, шүрлектәге тартмаларны җимереп төшергән, үзе дә кысылган шунда...

Сокольников башын аска иеп, тынып калды.

— Менә Виталийны һич оныта алмыйм, — диде ул, йөзен яшерергә тырышып, — исеме инде халык теленә күчте, урам исеменә, теплоход исеменә әйләнде. Ә үзе, гел тере шикелле, менә шушы төштә, йөрәк түрендә басып тора...

## ЛЕНАНЫҢ ЯШЬЛЕГЕ

Яр буендагы ак палатка эчендә берәү моңаеп гитара уйный. Аңа кушылып, кемдер акрын гына украинча җырлый: «Ой, Днепро, Днепро...»

Зур елга ул хыял шикелле. Уйларыңны үз агымына ияртеп, әллә кайларга алып китә. Аның дулкыннарына карап, бер моңаясың, бер елмаясың. Чит җирдә булсаң, кылт итеп туган якларың искә төшә.

Безнең якташларыбыз да Ленага карап, Иделне сагына торганнардыр. Бу ике елга кай яклары беләндер бер-берләренә охшыйлар.

Буровойда булган вакыйгадан соң берничә көн үткәч, Мөхсинов Мәхмүтне мин Лена ярында очраттым. Ул елгага карап тора иде. Шакмаклы соры костюмын иңенә салып, бөеренә таянган да, нидер көтә. Үзе авыз эченнән генә бер көй мыгырдый.

Янында гына аяк тавышын ишетүгә, Мөхсинов сискәнеп китте. Ләкин шунда ук үзен кулга алды, елга причалы ягына ишарә ясап, көлеп куйды:

— Күрәсезме?

Яр читендәге причалга моторлы паром килеп туктаган. Аңа ашыгаашыга йорт җиһазлары, мал-туар төйиләр. Тавыклар кытаклашкан, казлар каңгылдашкан тавышлар ишетелә. Этләре, песиләре дә ияргән. Озын чыбык тоткан бер хатын паромга кызыл сыерын куып кертә алмыйча азаплана.

Кешенең күңеле шат булса, юк-бар нәрсәдән дә кызык таба, бармак күрсәтсәң дә көләргә әзер тора, дип уйладым эчемнән. Күрәсең, Мәхмүтнең дә бу минутта шайтаны кытыклыйдыр. Ә минем, ничектер, аңа кушылып көләсем килми.

— Эвакуация башланды, — диде Мәхмүт, ярым житди, ярым шаяртып, — безнең бәхет җиңсә ярар иде...

— Нинди эвакуация?

Ул миңа аңлатып бирде. Поселокта яшәүче жирле халыклар, яңа бораулана торган скважина нефть вәгъдә итә башладымы, тоталар да теге як ярга күченәләр икән. Атна буена өйләренә кайтмыйлар. Беренче кембри фонтаныннан, күрәсең, тәмам куркып калганнар.

— Болай итүегез әйбәт түгел, — дидем мин дә ярым шаяртып, — алар сезгә рәнҗи торганнардыр.

Мөхсинов елмаеп җавап бирде:

— Безгә рәнҗергә хаклары юк, иптәш. Яңа скважина нефть бирергә тора. Моңа барыбыз да шатланырга тиеш. Кембри фонтанына азынып-

га ирек куймабыз бу юлы. Без девон фонтаннарының авызын томалап өйрәнгән, иптәш.

Мин сорашуымны дәвам иттем:

— Сез килеп Лена буйларын айкый башлагач, җирле халыклар гына түгел, хәтта таулар да сагаеп калгандыр? Җәнлекләр дә качып беткән.

Бу сүзләрдән соң Мәхмүтнең йөзе кинәт җитдиләнде.

— Сез туристлар күзлегеннән карыйсыз, иптәш, — диде ул, бераз уйланып торгач. — Әгәр баскан җирем башка планета булса, җир шарын, өф-өф итеп, уч төбендә генә йөртер идем мин. Ә без бит бирегә яшәргә килгән, иптәш, экскурсиягә түгел.

Мөхсиновның хаклы икәнен болай да сизеп торганлыктан, бәхәсне тирәнгә җибәрәсем килмәде. Кыргый җәнлекләр өркеп кача дип, илгә кирәкле хәзинәдән баш тартмассың ич.

Күп тә үтмәде, елга борылышыннан юан морҗалы буксир пароходы күренде, гудок тавышы ишетелде. Монсу, салмак аваз таш кыяларга бәрелеп, кабат-кабат яңгырады. Аннан тайга аны үзенә йотты.

Буксир берьюлы ике баржа таккан иде. Алар артыннан тагын ниндидер суднолар тезелгән.

— Лена флотилиясе килә! — диде Мәхмүт, шатлыгыннан колачын җәеп. — Күрәсезме, ни чаклы йөк кайта Марковога...

Баржалар караваны акрын гына безнең якка таба хәрәкәт итә. Яр буена төркем-төркем халык агыла башлады. Вахтадан бушаган разведчиклар, экспедиция җитәкчеләре, ак халатлы поварлар, медицина эшчеләре, бәби күтәргән яшь хатыннар... Бала-чагасын әйткән дә юк.

Биредә һәр елны шулай була икән: сентябрь ахырына таба, Лена флотилиясе килеп, тау-тау буровой җиһазлары, яңа машиналар, кышка житәрлек азык запасы бушатып китә. Ә октябрь аенда инде елга өсте кар белән каплана, навигация туктала. Поселок кыш уртасына кадәр, Лена бозы машиналарны күтәрерлек хәлгә килгәнче, транспорт элемтәсеннән мәхрүм кала. Тик зур корсаклы вертолетлар гына, газета-журналлар белән бергә, сагынычлы сәлам хатлары тапшырып китәләр икән...

Яр читенә моторлы көймә борынын төртте. Маякчы, ихлас күңелдән елмая-елмая, безнең янәшәбезгә килеп басты.

— Драсте, Махмуда, — диде ул, якташыма ихтирам белән баш иеп. — голомянка надо? А деньга не надо...

— Голомянкадан баш тартмабыз...

Мөхсинов күрешергә теләп, ике кулын сузды. Ә эвенк карты: «Ай-яй-яй, бульна будет» дип, бер читкә тайпылды. Мәхмүтнең кул кысуына күпләр чыдамый икән. Аны мин бүген үзем дә сынадым, тик сер бирмәскә генә тырыштым.

Мөхсинов ни өчендер дулкынлана, чабышка китәсе ат шикелле тынычсызлана, бертуктаусыз йөренә башлады. Үзе, кулын әледән-әле маңгаена куеп, баржалар килгән якка карый.

— Баш тартмабыз! — дип кабатлады ул, үзе дә сизмәстән, кул чабарга тотынып. Аның артыннан бала-чага кул чабарга кереште, йөзләрен бозып, әче итеп сызгыру дисеңме, «ура» кычкыру дисеңме...

Мөхсиновның шатлыгы күзләренә чыккан, хәтта башыннан ашкан дияргә ярый иде.

— Мин бит бирегә килгәч, мастерлыкка имтихан тоттым, иптәш, — диде ул, минем якка нелә төшеп. — Яңа буровой җиһазлары кайту белән, бригаданы кабул итәсең, диделәр. Әнә, күрәсезме, буровой насослары, яңа дизельләр төялгән баржаны! Флотилия киләсен ишетеп төштем мин.

Һәркемнең үз хыялы, үз шатлыгы була. Ул хыяллар, ул шатлыклар, саф чишмәләр шикелле, кешеләр күңелендә аерым-аерым яшәсәләр дә, соңыннан барысы берьюлы зур агымга килеп тоташалар, тыелгысыз көчкә әвереләләр. Моның шулай икәнлеге Марково бораулаучылары

арасында аеруча нык сизелә. Мөхсинов кенә түгел, эвенк карты да шуның белән янып, дәртләнеп йөри. Чөнки аның туган якларына зур үзгәреш килә.

Баржалар караваны салмак кына, үз җае белән генә ярга якынлашты. Әлегә тыныч кына агып яткан Себер елгасы кинәт ярдан-ярга чайпалырга, котырынып дулкынланырга тотынды.

Буксир трабыннан ярга беренче булып юантык гәүдәле, яшел кожан кигән кеше сикереп төште. Мөхсинов эре-эре атлап, аның каршысына юнәлде, ике кулын сузып исәнләште:

— Исәнмесез, иптәш капитан! — диде ул, хәрбиләрчә честь биреп, — көтә-көтә арып беттек.

Елгачы киеме кигән кеше көлеп, Мәхмүтнең иңбашына сукты да әйтеп куйды:

— Беләбез, шельма, нәрсә көткәнеңне. Сиңа дигән буровой җиһазлары, әнә, өченче баржада...

Еракта килгән йөкләрне бушату өчен бөтен Марково халкы кузгалган. Берсе дә әйткәнне көтеп тормаган. Әлмәттәге элекке күршем Рәшидә апа, страховой эшләрен калдырып, үзе белән бер төркем хатын-кызларны ияртеп төшкән. Ул:

— Я-а-а!.. Никадәр байлык! — дия-дия, бот чабып, баржа эченә үк кереп китте. Кемдер шаяртып, артыннан кычкырып калды:

— Рәшидә апа, трактор дип белеп, үзеңне күтәрү краны эләктереп алмасын...

Яр буйларына авыр-авыр буровой җиһазлары, өстәл зурлыгы тартмалар, унар тонна йөк сыйдырышлы машиналар, өр-яңа тракторлар төшеп утыра. Буй-буй булып бораулау трубалары, тимер юл рельслары тезелә...

Мөхсиновны йөк бушатучылар арасында күрдем. Ул өч-дүрт кеше күтәрә алмастай авыр ящикларны җилтерәтеп кенә җилкәсенә ала да, яр өстенә илтеп куя.

Заводтан килгән машиналар, күтәрү краннары ярдәмендә, ярга төшеп утыруга, моторлар гөрли башлады. Кузовларга бер-бер артлы бала-чага менеп төялде. Тракторлар, тягачлар да хәрәкәткә килде.

Көн кичкә авышканда баржалар бушатылып бетте. Яр буенда калган хәрәкәтсез йөкләрне зур, авыр брезентлар белән ябып чыктылар.

Еракта ук исәнләшеп, минем янга Исхак Гыйләҗев килеп басты. Йөзе шатлыктан балкыган. Ул шунда ук сүзгә керешге:

— Малай белән котлый аласыз мине, Марковода тагын бер бораулаучы артты. Исеме — Ленар!

Шунда гына торган Мәхмүт, тагын берничә нефтьче Гыйләҗевне төрле яктан эләктереп алып, гөрләшә-гөрләшә һавага чөяргә тотындылар. Ата кеше моңа һич каршылык күрсәтмәде, киресенчә, кулларын җәеп кенә җибәрде. Талпыну рәхәтеннән хәтта күзләрен йомды.

— Космоска кадәр, космоска кадәр! — дигән тавышлар ишетелеп торды. Исхакның үз семьясы янына кайтыр алдыннан сөйләгәне хәтеремә килде: «Монысы кыз булса, Лена дип кушабыз...» Малай тугач та югалып калмаганнар...

Кояш ал пәрдәсен бөркәнеп, биек таулар арасына посты. Тайга өсте кара-кучкыл төскә керә башлады. Якындагы буровой вышкаларында электр лампалары кабынды...

Себер елгасының ике як ярына тезелеп утырган Марково поселогы үз дөньясы, үз шатлыгы белән артка чигенә барды. Биек буровой вышкалары, мәңгелек тайга урманнары өстеннән башларын калкытып, елга борылмасына җиткәнче озатып калдылар.

— Сау булыгыз, Лена маяклары!

**Марково поселогы — Әлмәт.**



# Кхмерлар илендә

*Ю. Седых,*
Казан аэропорты инженеры.

*Очерк*

●

Самолет, Пном-Пень өстеннән бер әйләнде дә, шәһәр читендәге аэропортка юнәлде. Ниһаять, без ерак экватордагы якын дусларыбыз — кунакчыл кхмерлар — илендә, күптән түгел генә милли бәйсезлек яулап алган Камбоджада. Безне — совет белгечләренең Камбоджага килгән чираттагы төркемен — бик җылы каршыладылар. Әле бик иртә булуга да карамастан, аэропортка күп кеше килгән: аэропорт эшчеләре, очучылар, төрле оешмаларның һәм Камбоджадагы совет илчелегенең вәкилләре, кхмерлар. Шул минутта ук алар безне урап та алдылар. Безнең белән күптәнге танышлардай исәнләшәләр, хәл-әхвәл сорашалар — ерак юлдан килгән пассажирларның күңелләрен күтәрергә тырышалар. Каршыларга килүчеләрнең берсе, безнең кулларлагы «Французча-русча сүзлек»не күргәч, аннан түбәндәге юлларны табып күрсәтте: «Мин сезнең белән танышуыма шатмын...» Юк, бу бер кхмер егетенең генә теләге, аның үз хисләре генә түгел иде. Әле соңгы елларда гына колониализм коллыгыннан котылган талантлы кхмер кешеләре совет иленнән, социализм җиреннән килгән һәркемне шул ук сүзләр белән каршылый: «Без сезнең белән танышырга бик шат. Рәхим итегез!»

Бераздан, машиналарга утырып, шәһәргә юнәләбез. Тигез юлдан машина алга оча. Юл читләрендә төз пальмалар, кокос агачлары, исемнәре безгә билгесез булган башка тропик агачлар тезелгән. Ерактарак эреле-ваклы күлләр, дөге басулары күренә, бензин колонкалары артта кала. Иртәнге сәгатьләр генә булса да, көн инде эссе, бөркү. Ә күк йөзе шундый биек, шундый зәңгәр... Бер генә болыт кисәге күренсен икән.

Әнә шәһәр дә күренә инде. Берничә минуттан автобус «Мондиаль» гостиницасы каршына килеп тә җитә. Без шунда торачакбыз. Үзәк урамнарның берсендәге бу гостиницада безнең өчен зур, якты бүлмәләр калдырылган. Урамда түзә алмаслык эссе — бүлмәләрдә салкынча, рәхәт. Һәр бүлмәгә көчле һава алмаштыргычлар куелган, алар кайнар һаваны урамга куалар, салкынча, дымлы температура саклыйлар. Бүлмә стеналары һәм идәннәр буйлап, безгә аз гына да игътибар итмәстән, кәлтәләр йөгерешә. Ерак көньякның безне гаҗәпләндергән әйберләреннән тагын берсе әнә шул кәлтәләр булды.

Килеп аз гына хәл алуга урамга җыенабыз. Тизрәк шәһәрне, аның кешеләрен күрәсе иде. Нинди икән ул Пном-Пень? Бу ил турында барысын да беләсебез килә.

## ПНОМ-ПЕНЬ — КАМБОДЖАНЫҢ ЙӨРӘГЕ

Пном-Пень илнең политик, административ һәм культура үзәге. 500 мең кешелек бу зур шәһәрнең төп халкы кхмерлар. Алардан башка монда тагын французлар, японнар, вьетнамлылар, кытайлар күп икән. Пном-Пень башка Көнчыгыш шәһәрләреннән әллә ни аерылмый диярлек. Шәһәр уртасында өсте ябулы зур базар тора. Базар мәйданыннан төрле якларга урамнар сузылган. Урамнарның күбесенә асфальт җәелгән, кайберләре бик озын, иkenчеләре исә артык кыска.

«Пном-Пень» — тау өстендәге шәһәр дигән сүз. Һәм, чыннан да, шәһәр калкулык өстендә тора. Бу борынгы шәһәрнең салына башлавы, тарихы турында халыкта күп легендалар саклана. Аларның берсе шундый. Чама белән XIV гасыр ахырларында кхмер империясе көчсезләнә, таркала башлый. Илгә өзлексез рәвештә чамнар, сиамлылар һөҗүм итеп тора. 1352 елда сиамлылар илнең ул вакыттагы башкаласы Ангкорны камап алалар. Шәһәр бер ел буена камалышта яши, әмма бирелми. Ахыр чиктә, төрле хәйләле юллар белән, дошманнар шәһәргә керәләр. Басып алучылар борынгы культура шәһәре Ангкорны хәрабәгә әйләндерәләр: сарайларны, гыйбадәтханәләрне җимерәләр, яндыралар, алардагы байлыкны талыйлар. Патша сарае даирәләренең исән калганнары башта Уддонга кача, соңрак Меконг, Тонле-Сап, Бассак елгалары бергә кушылган җиргә, ягъни Камбоджаның хәзерге башкаласы салынган урынга күчеп килә.

Риваятьләргә караганда, нәкъ шул вакытларда Пень фамилияле бай хатын, Меконг елгасы янындагы калкулыкта үзенә бер сарай салдырып, шунда яши башлый.

Көннәрнең берендә әлеге хатын елга буена чыга. Яңгырлар сезоны башланып, күлләрдә һәм елгаларда су бик нык арткан чак була бу. Ташу карап торганда, агым уңаена түбәнгә төшеп килүче зур бер әйбергә күзе төшә моның. Ныклабрак караса, әлеге әйбер галәмәт зур бүрәнә булып чыга. Пень шунда ук күршеләрен, тирә-юньдәге кешеләрне дәшә.

Көймәләр белән елга уртасына кереп, бүрәнәне ярга чыгаралар. Каткан балчыклардан һәм комнардан чистартып, агачны ярып карасалар — шаккаталар. Бүрәнә эченнән 5 будда сыны килеп чыга. Гәүдәләрнең 4 есе бронзадан коелган, ә берсе исә таштан эшләнгән икән. Пень ханым бүрәнә ярга чыгарылган урынга сарай салырга боера. Будда сыннарын вакытлыча әлеге сарайга урнаштырып торалар. Бераз вакыттан соң крепостнойлар көче белән шул тирәгә зур тау, кхмерларча әйтсәк, пном өяләр. Тау өстенә зиннәтле сарай салып, будданың бронзадан коелган сыннарын шунда күчерәләр. Таштан ясалган сынны яр кырыена куялар. Бу урынга монахлар чакырыла. Алар анда матур гыйбадәтханә салалар. Ул әле хәзер дә исән. Ват-Пном-Пень дип атап йөртәләр аны.

Пном-Пень борынгы шәһәр, чуар шәһәр, контрастлар шәһәре. Монда борынгылык һәм хәзерге заман, Көнбатыш һәм Көнчыгыш, иске һәм яңа стиль, байлык һәм хәерчелек бергә яши. Кайчандыр кхмерлар агач йортларда гына торганнар. Шәригать законнары буенча, таш йортларда аллалар, изге кешеләр генә яшәргә тиеш булган. Камбоджада гыйбадәтханәләр күп. Аларны «пагода» дип йөртәләр. Һәм аларның барысы да диярлек таштан салынган. Бу матур архитектура корылмаларының стеналары күп төрле рәсемнәр белән бизәлгән.

Хәзер шәһәр үзәгендә таштан яки тимер-бетоннан салынган йортлар байтак. Бу йортларның күбесен француз капиталистлары төзеткән, аларда француз колонизаторлары яшәгән. Бүген инде бай кхмерларның да байтагы таштан яки тимер-бетоннан эшләнгән йортларга күчкән. Бездәгедән аермалы буларак, Камбоджа шәһәрләрендә һәм авылларында йортларны биек свайлар өстенә салалар. Яңгырлар башлангач, илнең күп өлешен су баса. Әгәр шул свайлар булмаса, йортлар су астында калыр иде. Йортлар тирәсенә бананнар, пальма агачлары утырткaннар. Аларның киң яфраклары халыкны көньяк кояшының рәхимсез нурларыннан саклый.

Йөри торгач, шәһәрнең үзәк урамы — Народомга килеп чыкканбыз. Урам, Пном тавыннан башланып, Бәйсезлек һәйкәленә кадәр сузыла. Кичләрен, прожектор утлары кабынгач, һәйкәл аеруча мәһабәт, матур күренә диләр. Архитектура сәнгатенең бу гүзәл үрнәген талантлы кхмер осталары әле соңгы елларда гына төзегән. Народом — чиста, киң урам. Монда тыныч, хәрәкәт бөтенләй юк диярлек. Биек-биек йортлар.



Пном-Пеньдә король сарае.

Шәһәрнең бу районында власть органнары, төрле учреждениеләр урнашкан, Камбоджадагы СССР илчелеге бинасы да шул урамда.

Народом шау-шусыз, тыныч булса, Монвинг исә аның нәкъ киресе. Монда өзлексез хәрәкәт, зур җанлылык хөкем сөрә. Кичләрен урам реклама утлары белән тула. Рекламалар сезне ательеларга һәм магазиннарга, ашханәләргә һәм сыра залларына, гостиницаларга, кинотеатрларга чакыра. Рекламалар сигаралар һәм папирослар тартырга, тәмле сулар эчәргә өнди. Рекламалар, рекламалар... Алар чакыра, өнди, вәгъдә итә... Зур ательелар һәм магазиннар, кинотеатрлар һәм рестораннар, отельләр һәм парикмахерлар урамы ул Монвинг. Урамда баш әйләндергеч хәрәкәт. Автомашиналар, велорикшалар, меңнәрчә, ун меңнәрчә рикшалар. Рикшалар чабыша, узыша, пассажир эзли. Аларның җитезлегенә, кыюлыгына гаҗәпләнми мөмкин түгел. Чыпчык сыярлык кына аралыклардан рикша юл таба. Зур тизлек белән килгән машина алдыннан узып китү алар өчен, әйтерсең лә, берни дә тормый инде. Соңыннан рикшалар тормышы белән без якынрак таныштык. Авыр тормыш, мохтаҗлык аларны шулай чабышырга, узышырга мәҗбүр итә икән. Рикшаларның күбесе — авыл ярлылары. Зур шәһәргә алар эш эзләп, бәхет эзләп, әллә нинди хыяллар, зур өметләр белән килгәннәр. Юан корсаклы байларны, нәзберек бай хатыннарны һәм әрсез туристларны төяп чабучы менә бу рикшаларны шәһәр бәхетле итә алмаган. Пассажирларның күбесе рикшалар белән артык тәкәллефләнеп маташмый. Күперенгән, кабарынган әфәнде сүзсез генә арбага менеп утыра, сүзсез — кул ишарәсе белән генә — кая барырга икәнен аңлата. Килеп җиткәч, борылып та карамыйча, сүзсез генә рикшага тиеннәр төртә һәм китеп бара. Әйе, авыр, мәсхәрәле ул рикша хезмәте. Мау исемле рикша белән озак кына сөйләшеп тордык.

— Элек мин авылда яшәдем. Балык тота, иген үстерә идем, — ди Мау. — Тормыш бик начарлангач, монда килдем. Ә хәзер, күрәсез, башкалада... кеше йөртәм...

Пном-Пеньгә Мау да бәхет эзләп килгән. Тик тапмаган. Мау Советлар Союзы турында күп сорашты, бездәге тормыш, халыкның ничек яшәве белән кызыксынды. Мин аңа барын да сөйләдем. Сүз дә юк, Советлар иле, бездәге тормыш аңа бик тә, бик тә ошады. Әңгәмә ахырында Мау:

— Сезнең илдә дә рикшалар бармы? Алар ничек яшиләр? — дип сорады. Кхмер дустыма туган илебездәге такси машиналары, шоферлар, аларның тормышы һәм хезмәт хаклары турында аңлатып бирдем. Камбоджада рикша хезмәте кадерсез, рикшаларның эш хаклары бик түбән. Бер батон сатып алырлык акча эшләү өчен рикша

2,5 км юл үтәргә тиеш. Әйтик, ул 1 кг ветчина алырга уйлады ди. Моның өчен инде рикша кимендә 125 км юл үтәргә тиеш. Пном-Пень урамнарында җиңел машиналар һәм йөк машиналары бик аз күренә. Хәзергә Камбоджаның андый машиналар чыгара торган заводлары юк әле.

Соңгы елларда илнең башкаласы шактый матурланган, төзекләнгән, яңарган. Шәһәр үзәгендә биек, яңа йортлар арткан. Бүгенге стильдә салынган торак йортлары, учреждение биналары күбәйгән. Шундый йортлар арасыннан, иң элек, Камбоджага Совет хөкүмәте салып биргән госпиталь бинасын атап әйтергә кирәк. Кечкенә генә елга буенда төзелгән бу бина матурлыгы, монументальлеге белән Пном-Пеньдәге күп корылмалардан аерылып тора. Госпиталь каршында зур бакча бар. Анда гаҗәп матур чәчәкләр, күп төрле гөлләр үсә. Иң яңа медицина җиһазлары белән тәэмин ителгән бу госпитальдә тәҗрибәле совет врачлары эшли. Безнең врачларның авторитеты искиткеч зур монда. Дөрес, баштарак әле госпиталь төзелеп кенә килгәндә, кхмер врачлары больницадагы төп эшләрне үзләре башкарырга планлаштырган булганнар. Үтә җитди операцияләр вакытында гына совет белгечләренә мөрәҗәгать итәрбез дип уйлаганнар алар. Әмма кхмер врачларының көчсезлеге бик тиз күренгән. Франция университетларында укыган медицина эшчеләре җитәрлек тәҗрибә дә алмаганнар, осталыкка да өйрәнмәгәннәр икән. Хәзер алар бик теләп совет медицина фәне тупланган бай тәҗрибәне үзләштерәләр. Безнең врачларның шифалы кулына авырулар да бик тиз ияләшкән. Госпитальнең регистрация бүлмәсендә: «Мине рус врачына языгыз. Тазартса, ул гына тазартыр», — дигән сүзләрне еш ишетеп була.

Камбоджада инженерлар, техник белгечләр әзерли торган уку йортлары булмаган. Инженер булырга теләгән кеше чит илләргә, күбрәк Франция, Япония уку йортларына киткән. Чит илгә барып белем алу исә теләсә кемнең хәленнән килми. Эшче һәм крестьян балаларына ул турыда хыялланып та торасы юк, билгеле. Әнә шул кыенлыкларны күздә тотып, Камбоджа хөкүмәте илнең үзендә техник белгечләр әзерли торган уку йорты ачарга уйлый. Һәм хөкүмәт, бу эштә ярдәм күрсәтүләрен үтенеп, Америка Кушма Штатларына мөрәҗәгать итә. Америка империалистлары Камбоджа кебек экономик һәм культура үсеше ягыннан артта калган илләргә мондый ярдәм күрсәтүне үзләре өчен файдалы дип тапмыйлар. Билгеле, монополистлар ярдәм итүдән баш тарталар. Капиталистлар белән эш чыкмагач, принц Нородом Сианук социализм лагере илләренә, аерым алганда, Советлар Союзына мөрәҗәгать итәргә була. Безгә, совет кешеләренә, кхмерларның хәле якын, таныш, билгеле. Кайчандыр, эксплуататорлардан властьны тартып алганда, Россия дә артта калган аграр ил иде. Һәм Совет дәүләте Камбоджага ярдәм кулын суза. Хәзер әнә Пном-Пень шәһәрендә тагын бер мәһабәт бинаның стеналары үсеп чыккан. Тиздән Камбоджаның да үз милли инженерлары, техник белгечләре булачак.

Госпиталь дә, әле төзелеп кенә беткән училище да совет кешеләренең артта калган илләргә туганнарча ярдәме турында сөйләүче, СССР һәм Камбоджа халыклары арасындагы эчкерсез дуслык турында сөйләүче җанлы фактлар. Юк, Совет дәүләте экономик үсеш ягыннан артта калган илләрнең халыкларын матур вәгъдәләр, коры сүзләр белән генә сыйламый. Дөньяның бик күп почмакларында, күптән түгел генә колониализм коллыгыннан котылган күп илләрдә совет кешеләре төзеп биргән завод-фабрикалар һәм электр станцияләре, училищелар һәм госпитальләр бар... Артта калган илләрнең халыклары безнең бу ярдәмне онытмыйлар, Совет дәүләтенә, совет кешеләренә тирән рәхмәтләрен белдерәләр. Әнә шуңа күрә дә дөньяның күп илләрендә совет кешеләрен ачык чырай, якты йөз белән «Исәнме, рус!» дип каршылыйлар.

## КЕШЕЛӘР ҺӘМ ТРОТУАРЛАР...

Офыкта алсу яктылык беленеп килә, таң ата. Бервакыт, тын урамнарны һәм тыкрыкларны яңгыратып: «Га-то-о-о! Га-то-о-о!» дигән тавышлар ишетелә. Бу — пирожки сатучылар. Ул да булмый, урамнарда кәрзиннәр күтәргән җиләк-җимеш сатучылар күренә. Шәһәр йокыдан уяна, яңа көн башлана. Сәгать бишләрдә инде урамнарны машиналар гөрелтесе, велорикшалар, рикшалар шавы баса. Бер-бер артлы кибетләр ачыла, бананнар, апельсиннар, мандариннар ташучы йөкчеләр күбәя. Әнә шулай Пном-Пень яңа хезмәт көнен башлый.

Пном-Пень илнең башкаласы гына түгел, ул зур диңгез порты да. Иртәнге сәгатьләрдә үк портта зур җанлылык хөкем сөрә. Яр чите анда-монда йөгерүче йөк бушатучылар, пароход карарга җыелган халык белән тулы. Товарларның ниндиләре генә юк монда! Әнә бер читкә зур-зур кәрзиннәр белән апельсиннар, ананаслар, бананнар өйгәннәр. Кояшта янып бронза төсенә кергән грузчиклар дөге, кипкән балык, шикәр камышы төйиләр. Монда крокодил һәм юлбарыс тиреләре, фил сөякләре, хәтта тере филләр дә күрергә мөмкин.

Шәһәрнең нәкъ уртасында зур җимеш базары бар. Базар мәйданы гөрләп, гөжләп тора. Прилавкаларга тау-тау балык, яшелчә, җиләк-җимеш өелгән. Бу базарда дөньяның төрле почмакларында үскән, күп илләрдән китерелгән җиләк-җимеш, азык товарлары сатыла. Пном-Пеньдәге барлык рестораннар да француз яки кытай байлары кулында. Шәһәр рестораннарында милли кхмер ашлары булмый. Әгәр сезнең кхмер ашларын авыз итәсегез килсә, әлеге базарга рәхим итегез. Монда озын чыбыкларга тезеп балык кыздыралар, клеветок әзерлиләр. Базарда хуш исле үләннәр, борыч белән тәмләндерелгән балык ашлары сатыла, парда пешерелгән дөге һәм аерым ысул белән тозланган прахом балыгы бирәләр.

Пном-Пеньдә сату-алу, сәүдә эше киң җәелгән. Урам читләре буйлап кибетләр тезелгән. Парфюмерия һәм галантерея, хатын-кыз һәм ирләр күлмәкләре кибетләре, сәгать һәм уенчык кибетләре, китап кибетләре... Кибетләрдә дөньяның төрле илләреннән китерелгән товарлар очрый. Иң күбе Америка, Франция һәм Англия товарлары. Кызганычка каршы, бу кибетләрдә Камбоджа товарларын гына табып булмый: хәзергә илнең үз промышленносте юк. Франция өчен Камбоджа чимал, арзанлы эшче көчләр чыганагы гына булып саналган. Колонизаторлар илнең промышленностен торгызу турында кайгыртмаганнар, әлбәттә.

Китап кибетләре детектив әсәрләр белән тулган. Төрле зурлыктагы, төрле форматтагы китап тышлары пистолетлар һәм кинжаллар, асылынган, суелган яки агуланып үлгән кеше рәсемнәре белән чуарланган. Кхмер халкының тарихы, культурасы, тормыш-көнкүреше, илнең экономик һәм политик хәле турында язылган китаплар күренми. Камбоджа халкының төп массасы китаптан, матур әдәбият әсәрләре укудан бөтенләй мәхрүм. Чөнки китап бәяләре артык кыйммәт. Камбоджаның борынгы сарайлары турында язылган кечкенә форматлы бер китап, мәсәлән, 10 кг апельсин бәясе кадәр тора. Мондый бәягә, билгеле, теләсә кем китап сатып ала алмый. Пном-Пеньдә кыйммәтле мехлар, асылташлар, бриллиантлар, алтын-көмеш савытлар сата торган кибетләр дә күп. Боларының хуҗалары да, сатып алучылары да — байлар. Тыштан караганда, бу илдә чыннан да сәүдә киң җәелгән. Һәркайда кибетләр, лареклар. Урам чатлары, базар мәйданнары кечкенә кибетчекләр, җәяүле сатучылар белән тулган. Әмма табышны зур кибетләрнең хуҗалары гына җыя. Күпчелек сатучыларның хәле шактый мөшкел... Без яшәгән гостиница янына сигаретлар сатучы кхмер карты йөри иде. Гостиница янында аның үз урыны бар. Иртәдән кичкә кадәр ул шунда тора. Арыса, ятып йоклап ала. Көне буе утырып Сман Сок карт бик аз тәмәке сата. Әйе, картның хәле шәптән түгел. Картлык көнендә хөкүмәт аны пенсия белән тәэмин итмәгән.

Көн урталарында һава нык эсселәнә, кояш рәхимсез кыздыра башлый. Урамнар, тротуарлар тынып кала. Эсселеккә чыдый алмыйча, кешеләр йортларга, күләгәле урыннарга поса.

Көн кичкә авышып, кояш түбәнәя башлагач, урамнар тагын җанлана, тагын шау-шуга күмелә.

Кибет ишекләреннән француз, кытай, япон, кхмер көйләре агыла. Тротуарларда җыр тавышлары, балалар чыр-чуы көчәя. Урам халык диңгезенә әйләнә. Нинди кешеләрне, кемнәрне генә очратмыйсың монда. Әнә бер кырыйда багучы утыра. Алдында такталар, карталар, тагын әллә нинди кораллар ята. Багучыны йөкле хатыннар, яшь егетләр, кызлар сырып алган. Һәркем киләчәген, язмышын «белергә» ашыга. Багучы, алдындагы карталарга карап, йөкле хатыннарга туачак балаларының кызмы яки малаймы буласын «әйтеп бирә», төрле киңәшләр «өләшә». Егетләр кемгә өйләнәчәкләрен, кызлар исә кайчан кияүгә чыгасыларын «белеп китәләр». Багучы яныннан бер-ике адым читтә, урам врачлары очрый. Алар шунда ук авыруларга ашыгыч ярдәм күрсәтәләр. Әйтик, кинәт кенә сезнең тешегез сызлый башлады, ди. Әгәр

чыдарлыгыгызга ышансагыз, рәхим итеп, урам врачларына барыгыз. Ул, бернинди өшеткечләр җибәреп азапланмыйча гына, авыру тешләрегезне суырып та бирә. Шунда ук пирожки һәм пирожный сатучылар, бәйрәм маскалары һәм лотерей билетлары сатучылар... Ә бер читтә, тротуарга шакмаклар сызганнар да, шахмат уйныйлар. Алар янына бер көтү тамашачы җыелган. Бездәге кебек, ерак Камбоджада да шахмат уенын яраталар һәм беләләр икән. Тик шахмат сөючеләр өчен бездәгедәй шартлар гына тудырылмаган. Бераздан караңгы төшә, һава тагын да салкыная. Урамнарда, кибет витриналарында меңнәрчә лампочкалар, реклама утлары кабына. Урамнар, тротуарлар тагын да матуррак, серлерәк төс ала. Утлар кабынуга, тротуарларга өстәлләр чыгарыла, «урам ашханәләре» эш башлый. Шәһәр урамнары тәмле аш исләре белән тула. Бу — Пном-Пеньдә кичке аш вакыты җитте дигән сүз. Тротуарларда ук туй мәҗлесләре, туган көн һәм искә алу кичәләре уздырыла. Сәгать уннардан соң шау-шу басыла төшә. Шәһәр төнге йокыга әзерләнә башлый. Бик күпләр урам почмакларында, тротуарларда ук төнге йокыга да кала. 4—5 сәгатькә кадәр шәһәр тынып кала. Ләкин бу тынлык күпкә бармый. Тын урамнарда кабат: «Га-то-о-о! Га-то-о-о!» дигән тавышлар яңгырый. Яңа көн туа, шәһәрдә тагын бер яңа эш көне башлана.

## СУ БӘЙРӘМЕ

Камбоджада ел вакытлары бездәгегә охшамаган. Ел анда яз, җәй, көз, кыш айларына бүленми. Иң салкын декабрь аенда да эсселек 25 градустан ким булмый. Иң эссе ай — апрель. Кхмерлар елны ике сезонга бүлеп йөртәләр. Яңгырлы сезон май аеннан октябрьга кадәр сузыла. Ноябрь аеннан майга кадәр — коры, яңгырсыз сезон. Һәр елның ноябрь урталарында су бәйрәме була. Бу — кхмерларның иң зур бәйрәмнәре. Аңа озак әзерләнәләр, бу бәйрәмне көтеп алалар, бик тантаналы итеп уздыралар. Бәйрәм көннәрендә барлык кеше көймәләргә утыра, су өстенә чыга. Илнең барлык почмакларыннан башкалага кунаклар җыела. Кичен ачу иң югары ноктага җиткәч, король Камбоджа елгаларына кирегә ага башларга «приказ бирә». Билгеле, елгаларның агымы үзгәрүдә король фәрманы хәлиткеч роль уйнамый. Әмма ни генә булмасын, 16—18 ноябрь тирәләрендә елгаларның агымы үзгәрә — алар кирегә ага башлыйлар. Гаҗәеп күренеш, кызыклы күренеш! Ахырдан безгә бу хикмәтле күренешнең серен дә аңлаттылар. Эш менә нәрсәдә икән. Камбоджа территориясе буйлап Азия материгындагы иң зур елгаларның берсе Меконг үтә. Яңгырлар сезоны башлангач, Меконгның суы арта башлый. Бик аз ара эчендә елгадагы су 8—10 метрга күтәрелә. Меконг котыра, дулый башлый, ярларыннан чыга. Менә шул чагында Пном-Пеньнән 200 км чамасы төньяктарак урнашкан Тонле-Сап күле кешеләргә ярдәмгә килә. Меконгта су бик нык күтәрелгән бер вакытта, Тонле-Сапта суның биеклеге шактый түбән була. Һәм әлеге күл, Тонле-Сап исемле икенче бер кечерәк елга аша, Меконгның артык суларын үзенә җыя башлый. Шул моменттан башлап Меконг Көньяк Кытай диңгезенә таба түгел, ә кирегә Тонле-Сап күленә карап ага башлый. Тонле-Сапны кхмерлар «Бөек күл» дип атап йөртәләр. Һәм, чыннан да, мәрхәмәтле, бөек күл ул.

Кичле яңгырлар туктап, коры сезон башлануга Меконг елгасындагы суның күләме кими, елга элекке ярларына кайта. «Бөек күл» элек җыйган су запасларын яңадан Меконгка кайтара. Тагын бер мәртәбә елгаларның агымы үзгәрә. Тонле-Сап сулары Меконгка ага башлаган вакытта кхмерлар әлеге су бәйрәмен уздыралар да инде.

Елгаларның агымы үзгәрү кхмерлар тормышында зур роль уйный. Меконгта су күтәрелгәч, Пном-Пень зур диңгез портына әйләнә. Меконг буйлап шәһәргә океан пароходлары күтәрелә. Тонле-Сапта су кими башлагач, уңдырышлы ләм утырган гаять зур җир массивлары кала. Дөге үстерү өчен шуннан да уңайрак шартлар тагын кайда бар?!. Камбоджа балыкка бай илләрнең берсе. Балыкчылык белән илнең барлык өлкәләрендә шөгыльләнәләр. Әмма Тонле-Сап күлендәге кадәр балык дөньяның бүтән бер суында да юктыр.

Су чигенгәндә Тонле-Сап бассейнында искиткеч зур балык запаслары кала. Су азаеп, урманнар җир өстендә кала башлагач, балыкчылар ясалма урманнар утырталар. Балык күләгәле, үсемлекле урыннарга җыела икән. Соңыннан ясалма урманнар-

ны бамбук ботакларыннан үрелгән җәтмәләр белән әйләндереп алалар. Күлдәге су тагын да саеккач, әлеге ясалма урманнарда бик күп балык җыелып кала. Ташып кына өлгер!

Балыкчылар хикмәтле балыклар турында искиткеч мәзәкләр сөйлиләр. Имеш, көчле яңгырлардан соң агач ботакларында, төпләрдә әллә никадәр балык була икән. Инде моңа гына шаккатмасаң, «безнең Тонле-Сап күлендәге балыклар агач башларында да үрмәли алалар», дип җибәрәләр. Берәр урынга кичтән чокыр казып калдырсаң, иртән килүгә анда балык була, диләр крестьяннар. Белмим, бу мәзәкләрнең күпмесе дөрестер. Әмма балык күп, бик күп анда. Кхмер малайлары балыкка бездәге кебек озын саплы кармаклар белән йөрмиләр. Аларның барлык кораллары — бер метрлы гади таяк. Яр читенә йөзеп килгән балыкларны әлеге таяклар белән сугып тоталар. Уңайлы да, җиңел дә.

Илдә балык күпме генә тотылмасын, шулай да балыкчыларның тормышы да әллә ни мактанырлык түгел. Балык запаслары байлар кулында, табыш та алар кесәсенә керә. Балыкчының көнлек хезмәт хакы — бер кәрзин балык. Илдәге балыкның күплеген, арзан булуын да исәпкә алсаң, бу бик аз, әлбәттә.

## ДЖУНГЛИЛАР ҖЫРЛЫЙ

Матур иртәләрнең берендә автобус безне илнең көньягына — Сиануквиль провинциясенә алып китте. Эреле-ваклы күлләр, урман массивлары, иген басулары, авыллар очрый. Бездәге колхоз амбарларын хәтерләтә мондагы авыллар. Аерма бары шунда гына: өйләр биек свайлар өстенә салынган, йорт тирәсенә агачлар утыртылган. Һәр йорт каршында кечкенә генә җир участогы. Камбоджа крестьянының бөтен байлыгы әнә шулар: бер йорт, кечкенә генә җир участогы.

Табигать рәхәт, бай яшәү өчен кешегә бөтен шартларны тудырган монда. Тибет һәм Гоби таулары Камбоджаны салкын төньяк җилләреннән саклый. Океаннан искән көчле муссоннар илгә мул явым-төшем китерә. Тау битләре яшел тропик урманнар белән капланган. Ил көтүлекләргә, сулыкларга бай. Уңайлы климат шартлары күп төрле авыл хуҗалыгы культуралары үстерергә, алардан мул уңыш алырга бөтен мөмкинлекләрне бирә.

Ә халык хәерче яши, авыр яши. Илдә 4 миллион гектардан артык чәчүлек җир бар. Ул җирләрнең дә шактые буш ята, чәчелми. Кхмер крестьянының бар курыкканы — налог. Монда өй һәм өй каршындагы агач өчен дә, җир участогы һәм һәрбер баш терлек өчен дә бик күп налог салына. Шуңа да крестьян иң кирәген генә, ачтан үлмәслек кенә иген үстерә, булган җир мәйданнары да тиешенчә эшкәртелми. Камбоджа аграр ил, әмма авыл хуҗалыгы да анда бик артта калган.

Җирне үтә примитив алымнар белән эшкәртәләр, машиналар бөтенләй кулланылмый. Хәзер Камбоджа хөкүмәте илнең экономикасын һәм авыл хуҗалыгын күтәрү, халыкның тормыш-көнкүреш дәрәҗәсен яхшырту юлында күп эшләр башкара. Берничә урында хөкүмәт фермалары оештырылган. Алдынгы техника, көчле машиналар белән тәэмин ителгән бу хуҗалыкларда җирне прогрессив алымнар белән эшкәртәләр, мул уңыш алалар. Ләкин мондый хуҗалыклар әле бармак белән генә санарлык.

Камбоджада төп авыл хуҗалыгы культуралары булып дөге, кукуруз санала. Мондагы табигать шартларында дөгедән бик иркенләп ике уңыш алып булыр иде. Кхмерлар берсен дә көч-хәл белән генә үстерәләр. Уңыш бик аз алына: гектардан нибары 11 центнер тирәсе. Кхмерлар ике төрле кукуруз үстерәләр. Ак кукурузны кечкенә мәйданнарга гына чәчәләр, ул киң таралмаган. Аның каравы, Камбоджада үстерелә торган кызыл кукуруз дөнья базарында яхшылардан санала. Франциядә һәм дөньяның башка күп кенә илләрендә Камбоджа кукурузын бик теләп алалар. Соңгы елларда кукуруз игү үсә, киңәя бара. Кхмерлар тагын фасоль һәм соя борчагы, тәмәке, борыч һ. б. үстерәләр. Боларның күбесе чит илләргә чыгарыла. Мамык үстерү өчен дә шартлар уңай. Ләкин хәзергә мамык түбән сыйфатлы, бу өлкәдә Камбоджа башка илләр белән ярыша алмый. Камбоджа көтүлекләргә бай. Илдә 1 миллион баштан артыграк мөгезле эре терлек бар. Аларны нигездә ит өчен асрыйлар. Сыер монда — изге терлек. Сыерларны саварга да, сөтләрен эчәргә дә ярамый.



Король сарае ишек алдында фил.

Матур болыннар һәм көтүлекләр, елгалар һәм күлләр, кечкенә-кечкенә авыллар аша узып, автобус Сиам култыгына да килеп җитте. Эссе һава, ерак юл шактый талчыктырган, сусаганбыз. Тизрәк арыган тәннәргә хәл кертергә кирәк. Безне алдан ук, су кергәндә күлмәкләрне салырга ярамый дип, кисәтеп куйганнар иде. Без игътибар итеп тормадык. Бүген көн болытлы бит, нәрсә булсын, янәсе. Бу юләрлегебез шактый кыйммәткә төште. Төне буе авырып, әрнешеп чыктык — без тәннәрне пешергәнбез. Ярый инде, икенче юлы акыллырак булырбыз.

Пном-Пеньгә башка юл белән, джунглилар аша кайттык. Бала вакытларда ук күпме китап укыдык без бу урманнар турында. ...Менә нинди икән джунгли! Мәңге яшел, калын урман стеналары. Агач араларын әрсез лианалар сырган. Джунгли кошларга, ерткыч җәнлекләргә, төрле хайваннарга бик бай. Көтү-көтү маймыллар, ерткыч юлбарыслар һәм пантералар очрый, диләр. Һәм, әлбәттә, филләр дә күп. Халык тормышында монда фил зур роль уйный. Филләр белән йөк ташыйлар, аларга утырып йөриләр, аларны чит илләргә саталар. Камбоджада фил асрау, кыргый филләрне кулга ияләштерү киң таралган. Монда бөтен ил күләмендә атаклы аучылар бар. Шундый аучыларның берсе белән без дә таныштык. Йөзен җыерчыклар баскан, кечкенә гәүдәле бу картка карыйсың да гаҗәпкә каласың. Ничек инде шундый бәләкәй карт көчле филләрне буйсындыра икән?..

Карт аучы филләр, фил аулау турында бик кызык нәрсәләр сөйләде. Филләр көтү-көтү йөриләр, ди. Көтүнең зурлыгы төрлечә була. Көтүдәге яшь филләрне дә, ата филләрне дә ана фил саклый: куркыныч булса, хәбәр итә, кирәк икән, башлап сугышка ташлана. Аучылар, фил көтүләрен саклап торалар икән дә, вакыты җиткәч, яшеренгән урыннан чыгып, көтүне таркаталар һәм аннан кирәкле филне аерып алалар. Аерып алынган филгә каршы махсус өйрәтелгән ау филен җибәрәләр. Ике фил үзара сугыша башлый. Әнә шул чагында аучыларның берсе кыргый филнең аягына элмәкле бау кидерә. Бауның икенче очын юан агач кәүсәсенә бәйләп куялар. Шуны гына көтеп торган аучылар, мылтыклар шартлатып, көтүне джунглиларга куып җибәрәләр. Тозакка эләккән фил алай тартыла, болай тартыла, әмма ычкына алмый. Ике-өч көннән соң филне авылга алып кайталар һәм кулга ияләштерәләр. Фил аулауның башка төрле юллары да бар икән. Яңгырлар башланып, елгаларда су арткач, аучылар фил көтүләрен суга куып төшерәләр дә, үзләре көймәләргә утырып, куа чыгалар икән. Яшь филләр озак йөзә алмый, арыйлар. Арыган фил артта кала башлый. Аучыларга шул гына кирәк тә... Көтүдән аерылган филгә шунда ук бау бәйлиләр һәм ярга өстерәп чыгаралар...

Монда килгәч, без беренче мәртәбә «джунгли жырлый» дигән сүз ишеттек. Дөрес сүз икән. Чыннан да джунгли җырлый икән. Төнге джунгли җыры аеруча матур була. Бу мәңгелек урманнарда күпме кош, күпме җәнлек бар! Һәрберсенең үз тавышы, үз җыры бар. Әнә шул меңнәрчә кош һәм җәнлек авазлары барысы бергә җыела да көчле симфониягә әйләнә. Кайбер туристлар ерак Камбоджага төнге «джунгли җырын» тыңлау өчен генә киләләр икән.

— Джунгли җырлый. Әмма ул төрлечә җырлый,— диде безгә Тон исемле кхмер кешесе.

Япон оккупантлары килгәч, джунгли урманнарында снарядлар ярылган, атыш тавышлары яңгыраган, бик күп кхмерларның каны коелган. Ул вакытларда да джунгли җырлаган, ләкин аның җыры башка, кайгылы булган.

— Без тыныч джунгли җырын яратабыз, — диләр кхмерлар. Алар дөрес әйтә. Тыныч джунгли җырына ни җитә?!

## БОРЫНГЫ ҺӘЙКӘЛЛӘР ИЛЕ

Һәр халыкның истәлекле урыннары, борынгы культура хәзинәләре бар. Мисыр үзенең пирамидалары, Италия Колизей хәрабәләре, Һиндстан матур сарайлары һәм гыйбадәтханәләре белән мактана ала. Борынгы кхмерлар да безнең заманда бик күп сәнгать әсәрләре: мәһабәт сарайлар, искиткеч архитектура корылмалары калдырганнар. Шуларның иң зурысы — борынгы Ангкор шәһәре. Ангкор — кхмерларның мактанычы, кхмерларның элекке башкаласы. Мондагы архитектура корылмалары, искиткеч сарайлар һәм гыйбадәтханәләр турында күпме генә сөйләсәң дә, аларның матурлыгын һәм гүзәллеген барыбер аңлатып бирү мөмкин түгел. Бу искиткеч сәнгать әсәрләрен үзең карарга кирәк.

Борынгы Ангкорның иң гүзәл корылмаларының берсе, һичшиксез, Ангкор-Ват сарае. Бу сарай чама белән XII йөзнең урталарында салынган. Ангкор-Ватның салынуы турында шундый легенда сөйлиләр. Борын-борын заманнарда Камбоджа җирендә чибәрлеге, сылулыгы белән һәркемне һуштан яздырырлык яшь принц яшәгән, ди. Бервакыт бу егетне Индра алла күреп алган һәм шунда ук гашыйк та булган. Шуннан алла чибәр егетне күккә, үзе янына алдырган. Күк осталары принцка гаҗәеп матур сарай корып биргәннәр. Егеткә күк тормышы да, әлеге сарай да бик ошаган. Әмма чибәр егеткә тынычлап яшәргә ирек бирмәгәннәр. Күк биючеләре Индра аллага егет өстеннән жалобалар белән килә башлаганнар. Имеш, алар җир кешесе исен яратмыйлар, имеш, аларга күктә почет бетте һ. б., һ. б. Аптырагач, Индра алла принцны җиргә китәргә үгетли башлый. Ә егетнең һич кенә дә әлеге сарайдан аерыласы килми икән. Башка чара калмый, Индра принц өчен җирдә шундый ук сарай салдырырга була. Легендаларга караганда, Ангкор-Ватны әлеге егеткә Индра алла төзетеп биргән, ди...

«Г» хәрефе формасында салынган бу корылма зур мәйданны били тора. Сарай тышкы яктан 3 метр биеклектәге таш стена белән әйләндереп алынган. Таш стенаның гомуми озынлыгы 10 км дан артыграк сузыла. Сарайга көнбатыш һәм көнчыгыш яклардан зур юллар килә. Керү юлында өч ишек — өч галлерея ишеге. Һәр галлереянең түренә зур будда сыны куелган. Корылма күп санлы манарадан һәм галлереялардән тора. Һәр манара, һәр галлерея зур корылманың, бөтен бер ансамбльнең аерылмас кисәге дә. Барлык манара һәм галлереяләрнең стиле корылманың гомуми идеясенә буйсындырылган. Әнә шулай, меңнәрчә вак кисәкләр берләшкән дә, бер зур сәнгать әсәре туган. Кхмер осталары, бу корылманы салганда, цемент, известь кебек әйберләр кулланмаганнар, диләр. Бу күпме дөрестер, анысы башка нәрсә. Әмма бернәрсә бәхәссез: инде ничә йөз ел үткән, Ангкор-Ват җимерелмәгән. Димәк, кхмер ташчылары үз эшләренең чын осталары булганнар.

Камбоджа җиреннән күп сугышчылар узган. Борынгы заманнарда кхмерлар иленә өзлексез рәвештә чамнар, сиамлылар һөҗүм итеп торган.

Камбоджа шәһәрләре күп мәртәбәләр дошман кулында калган. Басып алучылар ул шәһәрләрне җимергәннәр, бик күп архитектура корылмаларын яндырганнар, юк иткәннәр. Хәзер Ангкордагы күпчелек һәйкәлләр хәрабә хәлендә.

Бүгенгә кадәр сакланган корылмалардан тагын Байон сарае аеруча матур. Байон Ангкордагы башка корылмалардан, шул исәптән Ангкор-Ваттан, соңрак төзелгән. Бу вакыт эчендә чамнар кхмерлар иленә тагын бер тапкыр һөҗүм итәргә өлгергәннәр. Аларның бу һөҗүме уңышсыз чыккан. Байон басып алучыларны илдән куып чыгаргач төзелеп беткән. Кхмерлар белән чамнар арасындагы соңгы сугыш турында Байон стеналарыннан күп нәрсә укырга була. Сарай стеналары төрле сугыш картиналары белән бизәлгән. Бу сарайда гына түгел, Ангкордагы башка корылмаларның стеналарына да матур бизәкләр, төрле рәсемнәр төшерелгән. Сарай стеналарында кобра еланнары рәсеме аеруча күп очрый.

Рәсемнәрнең бик күбесе тыныч тормыш күренешләренә багышланган.

Җир сөрүче, ашлык җыючы, балык тотучы крестьяннар, бала караучы аналар, уйнап утырган сабыйлар, төрле хайван, кош-корт сурәтләре стеналарны чуарлап бетергән. Ул рәсемнәрдә кхмер халкының бөтен тарихы язылган. Якты хыялларын, киләчәккә булган өметләрен дә халык шул рәсемнәрдә белдергән. Аларга карап Камбоджаның үткәнен, бүгенгесен, киләчәген аңларга була. Кхмер халкы үзенең бу истәлекләре белән хаклы рәвештә горурлана, аларны күз алмасыдай саклый. Ангкор — Камбоджаның рухи башкаласы, рухи үзәге.

* * *

Санаулы вакыт тиз үтә. Китәр көннәр дә җитте. Ерак илдәге дусларыбыз белән җылы итеп саубуллашабыз да самолетка ашыгабыз.

Сау булыгыз, кунакчыл кхмерлар! Сау бул, Камбоджа. Сезгә эшегездә уңышлар телибез. Камбоджаның яңа җиңүләр яулаячагына без шикләнмибез.


# Ф. Абдуллин фоторәсемнәре күргәзмәсе

*Шушы елның июль аенда, «Татарстан» кинотеатрында, «Советская Россия» газетасы фоторепортеры, безнең якташыбыз Фоат Абдуллинның фоторәсемнәре күргәзмәсе оештырылды. «СССР халыкларының тугандаш семьясында» дип исемләнгән ул күргәзмәгә авторның 114 фоторәсеме куелган иде.*

*Ихтимал, РСФСРда фоторепортер Ф. Абдуллин аяк басмаган һәм ул рәсемгә төшермәгән почмак юктыр. Менә шуңа күрә дә Ф. Абдуллин фоторәсемнәренең тематикасы бик күп төрле һәм «Татарстан» кинотеатрына килгән тамашачылар аның рәсемнәрен кызыксынып карадылар. Журналыбызның бу санында без Ф. Абдуллинның күргәзмәгә куелган дүрт рәсемен урнаштырабыз һәм якташыбызга киләчәктә тагын да зуррак уңышлар теләп калабыз.*



Яңадан — туган якларда.



Ә заман үзгәрә.



Кое янында.



Казан. Елга порты.

# БҮГЕНГЕ РОМАННАРЫБЫЗНЫҢ ЖАНР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Совет романы, бер яктан, үткәндәге бөек реалист язучыларның иң яхшы традицияләрен дәвам иттерсә, икенче яктан, ул чын-чынлап яңа, новаторлык сыйфатларына байый бара. Әгәр совет әдәбияты узган зур юлга әйләнеп карасак, без, җәмгыятебез үсеше белән бергә, роман жанрының да даими рәвештә алга хәрәкәтен, яңаруын күрербез. Яңа эчтәлеккә, чорның яңа идея-эстетик таләпләренә ятышлы төстә, халыкның тарихы, тәҗрибәсе һәм милли традицияләренә бәйләнештә яңа формалар, яңа алымнар барлыкка килә. Татар романының үсеш тарихы да бу фикернең дөреслеген раслап тора.

Әдәбияттагы бүтән жанрлар кебек үк, роман да конкрет бер милли туфракта шытып чыга һәм үсә. Бу безнең әдәбиятта да шулай булган. Әмма, шул ук вакытта, татар романы рус һәм дөнья романистикасы белән тыгыз бәйләнештә үсте һәм үсә бара. Һәм татар әдәбиятында роман жанрының зур, шактый үзенчәлекле үсү юлы, тарихы бар.

Октябрь революциясеннән соң проза жанрында киеренке сюжетка корылган, тирән психологик, җанлы, пластик хикәяләү формаларын үзләштерү шактый озакка сузылды. Ул вакытта күп кенә яшь прозаиклар иҗатында лирик, патетик хикәяләү, образларны гәүдәләндерүдә схематизм хакимлек итә иде. Г. Ибраһимов, Ш. Камал кебек тәҗрибәле проза осталарының гына әсәрләре үзләренең сюжетлы, образларның реаль булулары, геройларны психологик гәүдәләндерүнең ачыклыгы белән аерылып тордылар. Беренче татар реалистик романнарының XIX гасыр ахырларында ук язылган булуларына карамастан, роман жанрының үсеше сизелерлек артта иде әле. Егерменче, утызынчы һәм кырыгынчы елларда романистика тәҗрибәсен үзләштерү, күп планлы, киң колачлы тарихи-революцион социаль-проблематик роман тудыру буенча эзләнүләр дәвам итте. Шул елларда язылган «Юшкын», «Мөһәҗирләр» (М. Галәү), «Өч нарат» (Ф. Сәйфи-Казанлы) кебек романнар нәкъ әнә шул турыда сөйли. Утызынчы елларда язылган романнар арасында Ш. Камалның «Матур туганда» әсәре бу жанр үсешендә зур яңалык, алга китеш иде.

Милли һәм дөнья әдәбиятлары, бигрәк тә рус классик һәм совет романистикасы традицияләрен һәм тәҗрибәсен тирәнтен өйрәнү, художество осталыгын камилләштерү һәм, иң мөһиме, халыкның яңа рухи күтәрелеше, иҗади кадрларның идея ягыннан үсеше нәтиҗәсендә татар совет әдәбияты сугыштан соңгы елларда прозада, аерым алганда роман жанрында, зур казанышларга иреште. 1917 елдан алып сугышка кадәр чорда бары 16 роман басылып чыккан булса, сугыштан соңгы елларда 28 роман язылды. Дөрес, эш арифметикада түгел, шулай да ул күп нәрсә турында сөйли.

Сугыштан соң прозаикларыбыз, формасы буенча да, эчтәлеге буенча да, күп төрле романнар иҗат итәләр. Алар арасында социаль-психологик романнар да, хәрби, тарихи һәм тарихи-революцион романнар да бар. К. Нәҗми, Ә. Фәйзи, Г. Бәширов, И. Гази, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, А. Расих һәм баш-

каларның сугыштан соң иҗат ителгән романнары Татарстанда һәм республикабыздан читтә дә зур популярлык казандылар. Болар барысы да, әлбәттә, прозаның реалистик җитлегүен, аның бөтен татар совет әдәбиятын яңа үрләргә әйдәвен ачык күрсәтә.

Бүгенге прозабыз турында сөйләгәндә, аның төрлелеген, тарих һәм хәзерге заман картиналарын эпик киңлектә кыю тасвирларга омтылышын күрмичә китү мөмкин түгел. Шактый зур тарихи чорны эченә алган, Татарстан җирләрендә Октябрь көннәрен, гражданнар сугышы вакыйгаларын сурәтләгән, «революция һәм халык», конкретрак әйткәндә, «революция һәм татар крестьяннары» проблемасын сәнгатьчә яктырткан «Онытылмас еллар» романын, Бөек Ватан сугышы чорындагы халык героизмын, аның какшамас көчен, җиңүгә ышануын күрсәткән «Саф күңел» романын һәм эшчеләр сыйныфына багышланган, коллективизм һәм интернационализм идеяләре белән, иҗади хезмәт пафосы белән сугарылган «Сүнмәс утлар» романын искә төшерегез. Аларда эпик киңлек, тулы канлы характерлар бар, халык тормышында барган тарихи үзгәрү, революцион аң үсү процессларының дөрес чагылышы бар. Сәнгатьчә эшләнешләрендәге аерым кимчелекләренә карамастан, мондый әсәрләр безнең прозаның олы юлга нык аяк басканлыгын, социалистик реализм әдәбиятының новаторлык көчен тагын бер тапкыр раслыйлар.

Прозабызның тематик диапазоны һаман киңәя баруын да уңай бер күренеш, дип әйтеп үтәргә кирәк. Моңарчы безнең әдәбиятта авыл тематикасы төп урынны алып килде, эшчеләр тормышы тематикасына җитәрлек игътибар бирелмәде. Моның тора-бара әдәби-иҗат эшендә бертөрлелек, тарлык тудыруы мөмкин иде. Һәм бу хәл, бик хаклы рәвештә, барыбызны да борчый башлаган иде. Соңгы елларда чыккан әсәрләр, минемчә, бу кимчелекләрнең бетә баруын, әдәбиятыбызның тематикасы һәм проблематикасы сизелерлек киңәюен күрсәтәләр. Татар халкының революцион көрәше, үткән тарихы белән кызыксыну, татар авылында барган яңа иҗтимагый процессларны сәнгатьчә тикшереп сурәтләү, совет эшчеләр сыйныфының героик хезмәте, бөек көрәштә рухландыручан көче, яңа яшь буынның чыныгып үсүе, Татарстан нефтьчеләре тормышы һәм башка бик күп темалар, күпкырлы, катлаулы реаль чынбарлыкның төрле яклары, төрле катлаулары бүгенге язучыларыбызның игътибар үзәгендә торалар һәм бүгенге әдәбиятыбызның тематик колачын билгелиләр. Монда мәсьәләләрне яңача куеп, яңача хәл итү тенденциясенең көчәюен дә аерым әйтергә кирәк.

Форманың баюы процессы, һичшиксез, романның эчтәлек сферасы киңәюе белән, иҗтимагый тормыштагы яңа күренешләрне, яңа фактларны тирәнтенрәк аңларга һәм чагылдырырга тырышу белән бәйле. Кеше язмышына игътибарның көчәюе, тарихи-социаль фонның киңәюе романнарыбызның характерлы сызыкларыннан берсе булып тора. Герой характерын катлаулы, күпкырлы, нык ихтыярлы итеп иҗат итү проблемасы прозаикларыбызны юкка гына тирән дулкынландырмый. К. Нәҗми, Ә. Фәйзи, И. Гази, М. Әмир, Г. Бәширов һәм Г. Әпсәләмов романнарында, минемчә, социаль вакыйгаларны эпик планда гәүдәләндерү, хикәяләүдә җитдилек, икенче төрле әйткәндә, монументаль прозага омтылыш ачык сизелә. Бу тенденция А. Расих, Г. Ахунов, С. Рафиков, Н. Фәттах романнарында да бар. Ф. Хөсни, Ә. Еники, Г. Минскийлар һәм Р. Төхфәтуллин, А. Гыйләҗев кебек талантлы яшь прозаиклар иҗаты кешеләр арасындагы шәхси мөнәсәбәтләрне сурәтләргә омтылу, лирик алымнар куллану белән характерлы. Бер-берсен тулыландыра торган бу иҗат төрлелеге, бу индивидуаль үзенчәлекләр роман һәм повестьлар үсешендәге киң мөмкинлекләр турында сөйли.

Романның жанр үзенчәлекләрен билгеләү хәзерге романнарыбызны классификацияләүне, билгеле бер типларга бүлүне таләп итә. Бу юнәлештәге тикшеренүләрнең тео-

ретик яктан гына түгел, практик яктан да зур әһәмияте бар. Беркем өчен дә сер түгел: күп кенә прозаиклар, бигрәк тә яшьләр, жанр үзенчәлекләренә тиешле игътибар бирмиләр һәм, күп вакытта, роман формаларының жанр бердәмлеген тәэмин итә торган эчке мөмкинлекләрне (композиция, сюжет, характер һ. б. лар) файдалана белмиләр. Мисал өчен яшь һәм талантлы прозаик Э. Касыймовның нигездә уңышлы язылган «Гомер ике килми» әсәрен алырга була. Әсәрне автор *«роман»* дип атаган. Ә аны, үзенең эчтәлеге һәм эчке структурасы нигезендә, «повесть» дип әйтергә кирәк иде. Бу әсәрне «лирик повесть» дип атавы белән Ф. Хөсни хаклы.

Совет әдәбияты романның төрле формаларына бай. Роман характерын нинди дә булса аерым бер үзенчәлегенә карап кына билгеләү һич тә дөрес һәм фәнни булмас иде. Бу берьяклы караш булыр иде. Жанрның асылын бары тик әсәрнең морфологик төзелеше нигезендә генә билгели торган формалистик эстетика принцибын совет әдәбияты инде күптән кире какты. Жанр спецификасын, формалар төрлелеген бары тик эчтәлек һәм форма берлеген алга сөргән марксистик принцип җирлегендә генә, индивидуаль стиль үзенчәлекләрен истә тотып, әсәрнең идея-мәгънә һәм структура бердәмлеге, үзара бәйләнеше нигезендә генә билгеләргә мөмкин. Роман, бүтән жанрлар кебек үк, әдәби әсәрнең аерым бер төгәл формасы, художество структурасының конкрет бер тибы. Ләкин бу форма конкрет эчтәлектән башка яши алмый. Мәсәлән, прозаик эпопеяның формасы, аның ирекле композициясе, даими үсә бара торган сюжетлы сөйләме, аның сыгылмалы образлылыгы һәм ритмы күпкырлы, тирән эчтәлек белән сугарылган.

Әйткәнебезчә, һәр әдәбиятта аерым типтагы романнар милли традицияләр, милли тәҗрибә, халыкның рухи үсеше җирлегендә акрынлап формалаша. Татар прозасының үсеш тарихына күз ташласак, реалистик прозаның зур эпик формасы повестьтан, примитив романнан зур социаль-психологик романга кыенлык белән, көрәш аша юл сала баруын күрербез. Совет чорында, бигрәк тә сугыштан соңгы елларда, татар романының чәчәк атуы югарыда инде әйтелде. Безнең көннәрдә татар романының эчтәлеге буенча да, формасы буенча да актив баюы процессы бара. Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Р. Төхфәтуллин, Ә. Еники, Г. Минский, А. Гыйләҗев һ. б. ларның романнарында һәм повестьларында психологик анализның, лиризмның тирәнәя баруы күзгә ташлана. Күп әсәрләрнең композицион структурасы шуның белән әһәмиятле: барлык сюжет сызыклары төп персонаж яки герой шәхесе тирәсенә килеп туплана. Бу — иҗади эзләнүнең бик уңай тенденциясе. Прозаикларыбызның иҗатында, социалистик реализм принциплары нигезендә, бу тенденция тагы да тирәнрәк урын алыр дип ышанасы килә.

К. Нәҗми, Ә. Фәйзи, И. Гази, Г. Әпсәләмов, М. Әмир һәм, өлешчә, А. Расих, Г. Ахунов, С. Рафиков иҗатындагыча, романнарның күп планлы, киң колачлы монументаль формалары — аналитик, киң эпик прозаның куәтле агымы шулай ук бик кызыклы һәм перспективалы.

Г. Ибраһимов һәм Ш. Камал романнарыннан соң социаль-психологик анализ юнәлешенең дәвамы сыйфатында Г. Бәшировның сугыштан соңгы елларда иҗат ителгән «Намус» романын алырга була. Бу роман безнең прозада яңа үсеш этабы булды. К. Нәҗминең тарихи-революцион типтагы «Язгы җилләр» һәм Г. Әпсәләмовның социаль-публицистик-героик пландагы «Алтын йолдыз», «Газинур» романнарына карата да шуны ук әйтергә мөмкин.

Хәзерге татар прозасындагы күп төрле роман формаларын, үзенчәлекле стильләрне тикшергәндә, минемчә, безнең романнарга иң характерлы төп төрләрне билгеләү бик әһәмиятле. Романнарыбызны анализлау шуны күрсәтә: хәзерге татар әдәбиятында романнарның төп өч төре (яки жанры) әкренләп формалашкан һәм ныгыган: социаль-психологик, социаль-публицистик (аны

кайвакыт, документаль-публицистик, дип тә атыйлар) һәм тарихи-революцион романнар. Әлбәттә, эчтәлекләренә карап, бүтән төр романнарны да (мәсәлән, производство, колхоз, крестьян һ. б.) әйтергә мөмкин. Ләкин хәзерге әдәбият белемендә инде романнар, утызынчы еллардагыча, профессиональ-тематик планда бүленмиләр. Мондый романнарның кайберләре, үзләренең структуралары буенча, ул заманда ук инде андый тышкы бүленеш рамкаларына сыймый иде. Ул заман романнарында һәм повестьларында да социаль, мораль, этик проблемалар куелган булуын беркем дә инкарь итә алмастыр (Ф. Сәйфинең «Өч нарат» романы, М. Әмирнең «Агыйдел», И. Туктарның «81 штольня», И. Газиның «Бригадир кыз» повестьлары һ. б.).

Безнең көннәрдә авыл һәм шәһәр тормышында яңа үсеш процессы, шәһәр белән авыл арасындагы аерманың якынаюы процессы бара. Бу катлаулы тормыш процессы хәзерге роман характерына да йогынты ясый. Хәзер «саф» производство яки крестьян романы юк инде. И. Газиның «Гади кешеләр», Г. Ахуновның «Хәзинә», Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романнарын кем производство романы дип кенә әйтә алыр?!. «Гади кешеләр», «Хәзинә» романнарының композиция, сюжет төзелеше нигезендә тормыш каршылыкларының, шәһәр һәм авыл кешеләре арасында иҗтимагый һәм шәхси, психологик мотивларның тыгыз үрелеше, халыкның төрле катламнары арасындагы бәрелешләр ята. И. Гази да, Г. Ахунов та авылдан килгән нефтьчеләрнең эшләрен, омтылышларын, тормышларын сурәтләргә, яңа кешенең, замандашыбызның туу, аякка басу процессын күрсәтергә, аларның рухи дөньясын, каршылыкларын һәм алар алдындагы кыенлыкларны аңларга телиләр. «Сүнмәс утлар», «Гади кешеләр», «Хәзинә» кебек романнарда социалистик хезмәт һәм социалистик җәмгыятьтә шәхеснең формалашуы, чәчәк атуы проблемасы нигездә социаль-психологик планда чишелә.

Сугыштан соңгы прозада социаль-психологик роман буларак иң характерлы һәм сәнгатьчә эшләнешләре белән бөтен булган әсәрләргә, безнеңчә, Г. Бәшировның «Намус», Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел», Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар», А. Расихның «Ике буйдак», Г. Ахуновның «Хәзинә» романнарын кертергә була.

Романнарның мондый төре нәрсә белән аерылып тора соң? Социаль-психологик, психологик романнарда тасвирлы сурәтләү принцибы, психологик анализ, индивидуаль детальләр аша гомуми сыйфатларны ачу принцибы өстенлек итә. Мондый очракта герой үзенең хәрәкәтләре, эйләнә-тирәгә мөнәсәбәте, язмышы, характер үсеше белән әсәрнең сюжетын әйдәп бара. Авторның фикере, уйланулары геройныкы булып әверелә. (Әлбәттә, бу авторлар бүтән төр роман алымнарын файдаланмыйлар, дигән сүз түгел.) Психологик романнарда сюжет үзгәндә һәрвакыт шәхес тора, сюжетны, композицияне актив оештыручы ролен төп герой яки төп геройлар башкара. Бу төр романнарның пейзажны сурәтләү, хикәяләүнең үзенчәлекле ритмы, лирик проза алымнары (эчке монологлар һ. б.) белән тыгыз бәйләнеше турында әйтеп тә торасы юк. Г. Бәширов, Ф. Хөсни романнарына бу сыйфатлар аеруча хас.

Г. Бәшировның «Намус» романын һәм андагы вакыйгаларны, гомуми атмосфераны хәтерегезгә төшерегез. Язучы бер дә көчәнмичә, бик табигый рәвештә һәм салмак кына безне вакыйгалар эченә, үз геройларының реаль дөньясына алып керә, аларның катлаулы мөнәсәбәтләрен, эчке дөньяларын ача. Романдагы вакыйгалар драматизмы, үзәк герой Нәфисә драматизмы тышкы фактларда гына түгел, эчке логиканың эзлеклелегендә, психологик пландагы художестволы анализ аша ачыла. Әсәрнең сюжет үсешендә хисләр, мәхәббәт мөнәсәбәтләре дә зур урын алып тора. Безнең психологик романнарыбыздагы характерлы үзенчәлекләрнең берсе шул: аларның үзәгендә милли үзенчәлекле, үзендә халыкның иң гүзәл сыйфат-

ларын туплаган әдәби образ тора. «Намус» романында Нәфисә, «Җәяүле кеше сукмагы»нда Сәфәргали, «Ике буйдак»та Рәхим — шундыйлар. Бу романнар композиция һәм сюжет бөтенлекләре белән дә аерылып торалар.

Сугышка кадәрге чорда язылган күп кенә проза әсәрләренең композицион структурасын һәм сюжет төзелешен драматик вакыйгалар һәм кискен сыйнфый көрәш билгели иде. Сугыштан соң, бигрәк тә партиянең XX съездыннан соңгы елларда, әхлакый якка игътибар, иҗтимагый күренешләрнең һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең психологиясен тирәнтенрәк аңларга омтылу шактый зур урын алды. Әлбәттә, бу иҗтимагый вакыйгаларга игътибар кимеде, дигән сүз түгел. Үзләренең эчтәлекләре һәм стильләре белән төрле дәрәҗәдә торган «Ике буйдак», «Гомер ике килми» әсәрләре, Г. Минский, Ә. Еники, А. Гыйләҗев повестьлары моның ачык мисалы булып тора. Соңгы вакытларда дөньяга чыккан әсәрләрдән мисалга Фатих Хөснинең «Утызынчы ел» романын алырга мөмкин. Безнең прозада ул әсәр житди тарихи-иҗтимагый проблемалар нигезендә психологизмның тирәнәя баруы, тасвирланган чорның психологиясенә үтеп керергә омтылу тенденциясенең көчәюен күрергә дә ярдәм итә.

«Утызынчы ел» — социаль-психологик роман. Ф. Хөсни үзенең «Җәяүле кеше сукмагы» романы белән башланган матур иҗади тәҗрибәсен бу романында да уңышлы дәвам иттерә, роман жанрының чиксез киң мөмкинлекләреннән файдаланып, халык тормышының яңа сәхифәләрен ача. «Утызынчы ел» романын укыганда каршылыклы драматизм белән тулы утызынчы елгы авыл сулышын тоясың, бөтен авыл халкын аякка бастырган, һәркемнең язмышын үзгәрткән колхозлашу хәрәкәтенең яңартучан көчен күрәсең. Язучы, үткән вакыйгаларга бүгенге ноктадан карап, шул еллардагы хәлләрне һәм колхозлашу юлына баскан авыл кешеләренең эчке рухи дөньяларын, уй-тойгыларын аңларга, төрле-төрле язмышларны яңадан күз алдыннан кичерергә тырыша. Юк, Ф. Хөсни Әтәчле авылы колхозының тарихын язмый, аның ничек оешуы турында бәйнә-бәйнә сөйләп тормый. Аны, барыннан элек, җанлы кешеләр, аларның шатлыклары һәм күз яшьләре, аларның язмышлары кызыксындыра. Ф. Хөснидә үз геройларына әхлакый мөнәсәбәт нык сизелә. Роман үзәгендә — шәхес язмышы, кешелеклелек, кеше бәхете идеясе. Шуңа күрә дә, социаль-психологик романнарга хас булганча, язучы колхозлашу чорындагы авыл кешеләренең катлаулы, каршылыклы кичерешләрен, көрәш эчендә туып килгән яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләрне философик планда ачарга омтыла. Кулак семьясында туган, ләкин совет кешеләренең яңа тормыш өчен янып яшәүләрен күреп, үзенең дә шулар рәтендә булырга теләге уянган һәм соңгы чиктә инде җәмгыятьтә үз урынын тапкан Нажия, элекке ярлы хатыны, күп кимсетүләрне күргән, әмма рухы сынмаган көчле характер иясе Гайния кебек образлар нәкъ әнә шул планда ачылалар. Әсәрдәге төп геройларның берсе Котдус Вафин образы да революцион хәрәкәттә, рухи үсү процессында сурәтләнә. Без аның уңай эшләрен, романтик ашкынуларын да, яшьлек, тәҗрибәсезлек аркасында ясаган ялгыш адымнарын да күрәбез. Кыскасы, романда тормышның, кеше язмышларының катлаулы каршылыкларын ачу бар, җанлы кешеләр бар, алар турында уйлану, борчылу бар. Ф. Хөсни романында искитәрлек нечкәлек белән тасвирланган авыл, табигать күренешләре, авыл халкының көнкүреш, гореф-гадәтләренә бәйле әдәби детальләр дә әсәрнең эмоциональ көчен арттыралар. Ф. Хөснидә пейзаж аерым яшәми, художество тукымасында актив функция үти. Әсәрнең ничек башланып китүен генә хәтерләгез: «терлекләрне тинтерәтә торган салкын җилләре, явымсыз-чәчемсез кырыс болытлары белән крестьянны тәмам аптыратып узганнан соң, январь аеннан кинәт карлы-буранлы, сулышка җиңел һәм күзнең явын ала торган йомшак ак кыш» күренеше,

«авылга буранлы төн хуҗа булып» торуы һәм шул төндә «тау башындагы мәктәп бинасының тәрәзәсендә күренә торган бер ут кына, авылның борын-борыннан килгән шул иске гореф-гадәтләре белән бәхәскә кергәндәй, төн урталарына кадәр җемелдәп» януы... Өстән караганда тын гына яшәгән бер авыл кебек, ләкин чынында ул алай түгел икән, авыл кешеләре колхоз турында уйланалар, ә кулак Галләм хаҗи, «дөньялар үзгәрүен» сизеп, каты борчылуга төшкән. Ерткыч өнәнә халыкның нәфрәт давылы килеп житкән икән. Язучы, әсәрнең башыннан ук, укучыны кискен драматик хәлләр эченә алып кереп китә.

Ф. Хөснинең иҗат уңышы, новаторлыгы бигрәк тә яңа образлар, үз чоры өчен характерлы типлар тудыруында, аларның тормышчан һәм дөрес бирелешендә күренә. Аеруча Нажия һәм Гайния образлары үзенчәлекле, сәнгатьчә көчле һәм мәгънәле итеп эшләнгән. Нажия образы әсәрнең башыннан ахырына кадәр дәвам итә. Язучы тарафыннан яратып, мавыгып тасвирланган образ бу. Аның тышкы матурлыгы белән эчке рухи гүзәлләге табигый һәм бер бөтен. Язучы бу образ аша безнең илдә саф күңелле, халыкның зур идеалларына каршы төшмәгән һәр кеше үз бәхетен табарга мөмкин, дигән бик мөһим фикерне чын сәнгать чаралары белән хәл итә. Ф. Хөсни сурәтләгән вакыйгаларына, образларына зур идеаллар яктылыгында карый һәм шул нигездә социалистик гуманизм принцибын яклый. Нәкъ шуңа күрә дә, бу әсәр, утызынчы еллар турындагы хәлләр турында сөйләсә дә, бүген дә актуаль яңгырый, укучылар күңеленә хуш килеп, матур хисләр уята. Нажия — Котдус линиясе романның композициясендә һәм сюжет җепләренең үрелешендә үзәк урынны алуы да язучының әнә шул төп фикере белән бәйләнгән. Монда Нажиянең үзенчәлекле, индивидуаль характерын да истән чыгармаска кирәк. Әйе, Нажия — кулак кызы, ләкин атасы Галләм хаҗиның ерткычлыгын, гаделсезлеген күрә башлаган һәм үги ана җәберен татыган нечкә күңелле, яшьлек һәм мәхәббәт хыяллары белән янучы бер кыз. Ул авылның бөтен яшьләре белән бергә җәмәгатьчелек эшенә катнашырга, өйдәге кыргый гореф-гадәтләрдән котылып, иркле саф һавага чыгарга омтыла (китапханәгә йөрү, Бафин белән очрашулар, спектакльдә катнашу, комсомолга керергә теләү, чәчен кистерү һ. б. эпизодлар). Яшь Нажиядә искелеккә каршы протест уянуы психологик яктан да бик нечкә күзәтүләр аркылы ачыла бара. Минемчә, язучы бу образны, яшьлек, мәхәббәт хисләре сферасыннан иҗтимагый «эш» сферасына да күчереп, активрак бер натура итеп биргән булса, ул тагын да көчлерәк һәм мәгънәви күләмлерәк төс алыр иде шикелле. Аның логик үсешендә кулак атасына каршы кискен конфликтка керү ихтималы да юк түгел. Ләкин язучы моңа бармаган. Нишлисең, язучының үз сиземләве бар бит. Нәрсә һәм ничек иҗат итәлгән — шул турыда сөйләү урынлы булыр. Һәр язучы образларын реаль тормыш нигезендә тудыра, үз иҗатына хас «ачкычны» куллана. Әйтик, В. Лацис «Яңа ярга» романында төп геройны — кулак малае образын, тормышка актив мөнәсәбәттә күрсәтеп, сыйнфый көрәшнең үзәгенә куеп, кулакларга каршы юнәлтелгән конфликт-ситуацияләр эчендә сурәтләгән. Мин моны Ф. Хөсни романына нииндидер күләгә төшерү өчен әйтмим, икенче бер подход, икенче тәҗрибәнең дә әдәбиятта барлыгын искә төшереп үтәргә генә телим.

Безнең тәнкыйтьтә «Утызынчы ел» романының төп җитешсезлеге — авылдагы сыйнфый көрәшнең бөтен кискенлеге, тирәнлеге белән ачылып бетмәүдә, дип күрсәтелгән иде. Моның белән килешеп булмый. Романның эчке төзелешендә, образлар бирелешендә шушы чор өчен характерлы сыйнфый көрәш, бугазга-бугаз килү, бәрелешләр бернинди роль уйнамыйлар, кеше язмышына йогынты ясамыйлар, дип әйтү зур хата булыр иде. Әсәрне игътибар белән укыган кеше моны әйтмәс. Нажия, Котдус, Шамкина, Гайния, Сәүбән, Хәллә, Гайфул һ. б. язмыш-

лары, бөтен кичерешләре Этәчле авылында барган сыйнфый көрәш шартлары (еш кына, бик астыртын төстә), колхозлашу хәрәкәте белән турыдан-туры бәйләнгән. Сюжетның үзәген, әсәрнең композициясен дә ике капма-каршы лагерьның көрәше, искелек белән яңаның көрәше билгели. Бу көрәшнең эчке пружинасын, эчке иҗтимагый психологиясен язучы тирәнрәк аңларга омтыла һәм, тышкы күренешләр белән артык мавыкмыйча, схемага бирелмичә, истә калырлык психологик портретлар, типлар иҗат итүгә ирешә. Совет дошманы, колхоз дошманы кулак Галләм хаҗи тибына да мин шулай ук бәя бирер идем. Юк, Ф. Хөсни монда да схемага, штампка бирелмәгән.

Нәҗия үзенә карата укучыда җылы мөнәсәбәт уятса, аның атасы — кулак Галләм хаҗи исә нәфрәт хисен, чиркану тойгысын тудыра. Бер тәнкыйтьче әйткәнчә, Галләм хаҗи «җылыда мырауларга яратучы бохар мәчесе генә булып» калмый. Бу зәһәрле «бохар мәчесенең» күп еллар буена «алла исеменнән» авыл халкының канын эчеп, халык хисабына баеп яшәгәнлеген язучы бик оста фаш итә. Галләм хаҗи тыштан бик диндар, «рәхимле», «изге» кеше булып күренә, ә чынында ул — ерткыч, комсыз, бозык холыклы кулак. Дөресрәге — агулы елан ул. Кулакларга, иске тормыш калдыкларына совет чынбарлыгы нинди хөкем чыгарганлыгын ул бик тиз сизә һәм моңа каршы чаралар эзли башлый. Юк, ул көрәшсез бирелергә теләми. Авыл кешеләренә элек-электән сеңдерелгән иске гореф-гадәтләрне, динне, мәчетне, крестьяннардагы хосусый милекчелек тойгыларын файдаланырга тырыша, кулына корал алудан да тартынмый. Галләм хаҗиның бу «эшләре» романда шактый тулы ачылган. Менә ул мәчет картларын җыя, өйләренә йөреп үгетли. Менә ул берсенә икмәк бирә, икенчесен аракы белән сыйлый һәм өченчесенең кулына револьвер тоттыра. Авыл «агайларының» шактый өлеше (урталар һәм бер төркем ярлылар да) бу «изге» кешенең явызлыгын, дошманлыгын тиз генә аңлап җиткермиләр, авылдан куылгач та әле, кайберләрендә икеләнү бетми, хәтта укытучы Шамкина да башта бик нык ялгыша һәм бу гамьсезлеге аны авыр хәлгә төшерә. Галләм хаҗиның астыртын, мәкерле кулак булуы романда ышанырлык итеп күрсәтелгән. Мондый типлар, соңыннан колхоз эченә кереп, аны эчтән дә җимерергә маташтылар. Галләм хаҗи кебекләр Бөек Ватан сугышы елларында, М. Әмирнең «Саф күңел» романында күрсәтелгәнчә, котoчкыч өрәк булып кайтып, совет дошманы Хәтерле Фәхрүшкә әйләнделәр.

«Утызынчы ел» романында төп образлар булсын, ярдәмче персонажлар булсын, һәркайсы үзенчәлекле характерлары, холыклары, эчке дөньялары белән сурәтләнәләр. Образлар кабатланмыйлар, бер-берсенә охшамыйлар. Язучы һәр характерның үзенә хас детальләр таба белә. Шуңа күрә Хәтерсез Хәллә дә, Бытбылдык Әхмәтҗан да, Мүкләк Гайфулла да, эшендә һәм шәхси тормышында буталып беткән, дөрес юлдан язган Сәүбән дә күз алдына тере кешеләр булып килеп басалар. Ә бу, һичшиксез, язучының осталыгы турында сөйли.

Хезмәт иясе хатын-кыз образларыннан иң уңышлысы, әйткәнебезчә, ярлы тол хатын Гайния. Яшьлеге әле сүнмәгән, усал сүзле, кызу холыклы бу матур хатын, кайчак үзен тупас тотуына да карамастан, кешелеклелеге, турылыгы, тырышлыгы һәм гомумән эш өчен януы, башкалар турында кайгырта белүе белән бездә соклану, хөрмәт тойгысы уята. Ялгызлык, фәкыйрьлек, шуның өстенә кимсетү сүзләрен ишетүләр Гайнияне рухи газаплыйлар, хурландыралар. Ләкин ул бирешми, ак күңелле кешеләрдә, колхоз активы һәм коммунистлар арасында үзенә таяныч таба. Гайниянең аякка нык басу, рухи яктан үсү процессы романның идея-эстетик кыйммәтен көчәйткән иң әһәмиятле якларыннан берсе, дип әйтергә кирәк.

Әсәрнең романтик пафосы, тормыштагы яңалыкны яклау дәрте, эчке ялкыны яшьләр образларында

нык сизелә дисәк, ялгыш булмас. Нажия образы турында әйткән идем инде. Монда авыл яшьләрен оештыручы һәм колхозлашу хәрәкәтендә алгы сафта булган, комсомолец һәм яшь коммунист Котдус Вафин образын да өстәргә кирәк. Язучы аны алгы пландагы уңай герой итеп бирергә тели. Ләкин бу образга тирәнлек, рухи үсешендә бөтенлек, эзлеклелек җитми. Тормышка кайчан җиңелчә каравы, дорфа кыланышлары Вафинның әле җитәкчелек эшенә җитлегеп өлгермәгән кеше икәнлеген күрсәтәләр. Ләкин образның әһәмияте анда түгел. Вафин образындагы бу йомшаклыкны язучы үзе дә сизгән булса кирәк. Колхозга тәҗрибәлерәк яңа җитәкчеләр килгәч, Вафинның аннан китүе дә ят бер нәрсә түгел. Моның эчке логикасы, сәбәпләре дә бар. Вафин Нажиягә гашыйк, Нажия дә аны ярата. Ләкин тормыш хәлләре бу ике яшькә бәхетле булырга мөмкинлек бирми. «Ә Вафин, моңа хәтле тик кешедән ишеткән, китаптан укыган акыл белән генә яшәгән беркатлы Вафин, бу минутта, менә бу ачылып калган юллар алдында, ниһаять, үз акылын җигеп, үзенчә уйлап карамыйча, чынлабрак уйлап карамыйча кала алмады. Аның кеше кайгысы белән тулган башы, кургашын тутыргандай, авыр иде, шулай да бер сорау аңарга тынгы бирмәде: «Нишләргә соң хәзер миңа?»

Язучының Вафинга биргән характеристикасы, аның кичерешләрен күзәтүе бик дөрес. Ахырда Вафин Коми ягына эшкә, дөресрәге, сөйгән кызы Нажия артыннан китә. Волком секретаре Батталов та моңа каршы килми, егетнең хәлен аңлый. Колхозда эшләр иң кызган чакта Вафинның болай китүе дөрес адыммы, аны аклап буламы? Әлбәттә, аклап булмый. Язучы моңа туры җавап бирмәсә дә, үз мөнәсәбәтен комсомолец Латыйп сүзләре аркылы сиздереп үтә шикелле. Котдуснең читкә китәргә теләвен ишеткәч, Латыйп аңа: «Син волкомнан сорама, син иң әүвәл үзеңнең күңелеңнән сора: күңелең кушамы шундый бер чакта безне ташлап китүне?» — ди.

«Мәхәббәтнең үз законы бар», диләр. Дөрес сүз. Вафинның да мәхәббәтенә турылыклы булып калуын гаепләп булмый. Ф. Хөснине «ни өчен Вафинны кулак кызы артыннан җибәрдең», дип шелтәләү урынсыз булыр иде. Хикмәт анда түгел. Минемчә, бу очракта язучыны Вафинның Нажиягә баштарак игътибарсызлык күрсәтүенең һәм соңгы адымнарының сәбәпләрен, иҗтимагый мәгънәсен тирәнрәк ачуга, сәнгатьчә анализлауга игътибар итеп җиткермәве өчен тәнкыйтьләргә кирәк. Романның мәхәббәт сызыгындагы «конфликт» авылдагы зур иҗтимагый вакыйгалар белән тагын да тыгызрак бәйләнештә бирелгәндә, әсәрнең реалистик көче, иҗтимагый мәгънәсе тагын да ачыла төшәр иде. Шуңа күрә дә Вафинның кыз артыннан китүе, ничектер, бер «казус» рәвешендә тәэсир итә. Билгеле, әдәби әсәрдә мондый «казусларның» булуы бик мөмкин. Әдәби әсәр тормышның күчермәсе түгел бит. Бу «казусны», В. И. Ленин әйткәнчә, конкрет образның үзенчәлекле характерына, психикасына карап кына аңларга мөмкин.

Ф. Хөсни сәнгатьнең җанын үтерә торган схематизмга, тормышны бизәп күрсәтүгә каршы. Ул тормышның каршылыклы, күңелсез, авыр якларын да ачып салырга курыкмый. Яңа белән искенең көрәше алдан хәзерләнгән тип-тигез, такыр юлдан гына бармавын яхшы аңлый.

«Утызынчы ел» романы авылны социализм юлына бору, авыл тормышын үзгәртеп кору җиңел генә килмәве турында сөйли. Халык тормышыннан алынган, лиризм белән тулы реаль картиналары, җанлы образлары белән кадерле безгә бу әсәр. Дөрес, романның әдәби яктан эшләнеше тигез түгел. Романның ахырында композицион бөтенлек җитми, төп образларның логик үсеше, үзгәреше кайчак артык «җиңеләйтеп» күрсәтелә, әсәрне ничек тә «очларга» ашыгу сәнгатьчә фикернең төгәллегенә дә зарар иткән. Колхозлашу хәрәкәтенә, кулакларны авылдан сөрүгә, авыл яшьләре, комсомоллары тормышына багышланган романның баштагы өлеше (романның иң зур өлеше) тулырак,

әдәби яктан көчлерәк бирелгән. Монда Ф. Хөсни үзен иркен сизә, руслар әйткәнчә, судагы балык шикелле йөзә. Ә менә вакыйгалар Коми якларына күчкәч, аның каләмендә, ничектер, кыюлык, иркенлек йомшый башлый, тасвирлар да сүрәнләнә, үткән әдәби детальләр дә кими. Ник болай? Чөнки язучы үзе якыннан белмәгән башка шартларга килеп керде, иҗат фантазиясенең дә реаль җирлеге тарайды. Ә бу хәл, билгеле, үзен сиздерми калмый. Монда Нажия белән Вафин образларын сурәтләгәндә дә баштагы пафос, романтик хыял, омтылышлар тоныкланып китә. Шатлыклы, якты тонда язылган эпилог та роман ахырындагы сүрәнлекне каплап бетерә алмый.

Гомумән, укучы романны бөтен килеш кабул итә, һәм безне дә аның көчле, уңышлы яклары дулкынландыра.

Сугыштан соңгы прозабызда психологик анализ тенденциясенең көчәюе хәзер инде һәр кемгә аңлашыла булса кирәк. Сугыштан соңгы зур прозабызда Г. Бәшировның «Намус»ы белән башланган бу тенденция хәзер инде «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел», өлешчә, «Хәзинә» романнарында һәм А. Расихның «Язгы авазлар» белән «Ике буйдак» романнарында тагын да үстерелде, камилләштерелде.

Роман типлары турында сөйләгәндә, әлбәттә, без теге яки бу тип романны башка төрләрдән өстен итеп куярга теләмибез. Социалистик реализм әдәбияты, бердәм иҗат методы нигезендә, әдәби иҗат формаларының байлыгын, төрлелеген яклый. Һәм безнең бөтен әдәбият тарихы да шуны раслый. Һәр язучының үз иҗат манерасы, почеркы, үз эзләнүе һәм табышы бар. Һәр чын талант әдәбиятка яңалык өсти. Ә аның бу үзенчәлекле табышы, иҗади ачышы тормыш чынлыгын дөрес аңлауга комачауламый, киресенчә, тормышның катлаулы булуын, кыскасы, тормыш хакыйкатен тулырак күрергә ярдәм итә. Шушы мәсьәлә уңае белән совет әдәбиятының атаклы язучысы Фадеев бик туры җавап биргән иде: «Тормышыбызны һәм иртәгесе көнебезне классик реалистик романнарга хас форма белән дә, ягъни көнкүреш нигезендә дә, шулай ук «Фауст»ка яки «Демон»га тартым формада да, ягъни романтик формада да, яки әкият алымы белән дә, ягъни шартлы рәвештә дә, гомумән, дөреслекне күрергә мөмкинлек бирә торган һәр формада сурәтләргә мөмкин» («Литературная газета», 29 сентябрь, 1955 ел).

Яңа роман материалын, формасын табу җиңел эш түгел — ул «өске катламда» күренеп ятмый. Монда язучының хәзерлекле булуы, иҗтимагый тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе, позициясенең ачыклыгы хәлиткеч роль уйный. Халык тормышына, кеше язмышына югары идеаллар ноктасыннан карап иҗат иткән романчы гына чын халыкчан әсәрләр иҗат итә ала. Үкенечкә каршы, безнең кайбер яшь романчыларыбыз моңа житди игътибар биреп бетермиләр, шуның нәтиҗәсендә уңышсызлыкка да очрыйлар. Мин мисалга М. Хәсәновның «Саф җилләр» романын күрсәтер идем. Социаль-психологик планда язарга уйланылган бу романда 'автор, тормыштагы яңаны ачу юлы белән бару урынына, еш кына әдәби схемага, башкалар тарафыннан инде сурәтләнгән образларны, әзер сюжетны файдалануга бирелеп китә. Димәк, язучы тормыштагы яңалыкны үзенчә ачу өстендә җитәрлек эшләми. Катлаулы тормыш яңалыгы исә — «мин күргән», «үземчә күргән» яңалык — үзенчә формалаштыруны да, үзенчә әдәби калыпка салуны да таләп итәчәк.

«Саф җилләр» турында матбугатта ачык фикер әйтелгән иде инде. Яңадан кабатлауның кирәге юк. М. Әмир дә, Ф. Мусин да һ. б. бу турыда яздылар инде. Бирәдә яшь тәнкыйтьче Ф. Мусинның дөрес бәясен искә алып китәсе килә. М. Хәсәнов романның «икенче өлешендә инде ул тормыш логикасыннан бигрәк автор ихтыяры буенчарак яктыртыла. Авылда һәртөрле яңалыкка, иҗадилыкка каршы торган, шәхес культы гадәтләрен алга сөргән көчләр — Борһаннар һәм Хаҗилар бик

тиз җиңеләләр. Геройлар арасында конфликтлар, тормышта һәм кешеләр аңында яңа белән искенең көрәше бетә. Язучы игътибары характерлар бәрелешен, үсешен сурәтләүдән хуҗалык мәсьәләләрен хәл итүгә күчә... Җыеп әйткәндә, язучының монда төп кимчелеге — тормышның, кеше рухының үсешен конфликтлардан башка чагылдыруда» («Совет әдәбияты», № 1, 1965 ел, 128 бит). Ә менә бу исә роман формасының тәгәллегенә дә зыян итә, роман ахырга таба композиция һәм сюжет ягыннан да (чөнки характер логикасы җимерелде!) сыеклана, җегәрсез була бара. Эчке тормыш логикасын, характерлар үсеше логикасын йомшарту аркасында романның формасы да «җимерелә» бара. Билгеле, бу яшь романчының тәҗрибәсезлегеннән дә туган хәл. Ләкин, башка жанрлар кебек, роман кебек зур эпик жанр да язучыдан аеруча зур таләпчәнлек, сизгерлек, киң караш һәм иҗади кыюлыкны сорый.

Социаль-психологик роман тибы, әлбәттә, төрле язучыларда төрлечә иҗат ителә. Һәр язучының талант үзенчәлеге, стиль үзенчәлеге бар. Н. Г. Чернышевский сүзләре белән әйткәндә, «Психологик анализ төрле юнәлеш алырга мөмкин: бер шагыйрьне характер сызыклары күбрәк кызыксындырса, икенчесен — характерларга иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең һәм көнкүреш бәрелешләренең йогынтысы, өченчесен — хисләрнең хәрәкәтләр белән бәйләнеше, дүртенчеләрен — кеше кичерешләрендәге киеренке моментларны анализлау кызыксындыра» (Н. Г. Чернышевский, Сайланма әсәрләр, рус телендә, III том, 422 бит).

Характерларны психологик планда, төрле юнәлештә сурәтләү, характер үсеше белән аерылгысыз бәйле сюжет төзү — мондый үзенчәлекләр безнең язучыларда да бар. Г. Ибраһимов, Ш. Камал, хәзерге прозада Г. Бәширов һ. б. әсәрләрендә «характерларга иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең һәм көнкүреш бәрелешләренең йогынтысы» төп роль уйный, геройның эчке дөньясын ачканда да алар шул яктан карап эшлиләр. «Кичерешләрдәге киеренке моментларны анализлау» нигезендәге романнар өчен дә ул ят түгел. Әмма шулай да бу төр әсәрләрдә төп игътибар «кичерешләрдәге киеренке моментларны анализлау»-га юнәлтелгән була. Бу сыйфат бигрәк тә Ф. Хөсни әсәрләре һәм Ә. Еники повестьлары өчен характерлы.

Шуның белән бергә, теләсә нинди психологизм дәрәслекне, образның көчен һәм тирәнлеген ачарга ярдәм итмәгәнлеген дә әйтергә кирәк. Социалистик реализм иҗтимагый тормышка, халык тормышына ят булган берьяклы, рухи ярлы кешеләрнең вак хисләрендә казынуга, рухи гариплек эстетикасына каршы. Билгеле булганча, классик реализм һәм социалистик реализм әсәрләрендәге тирән психологизм зур дәрәслекне, чын халык рухы дәрәслеген художестволы итеп ачып бирергә хезмәт итә, ачык фикер белән сугарылган була, кешенең көчен һәм гүзәллеген алга сөрә.

Соңгы вакытта әдәби тәнкыйтьтә еш телгә алынган, дөресен әйткәндә, артык урынсызга күпертелгән «лирик проза» турында да әйтеп үтү төп мәсьәләдән безне читкә алып китмәстер. Хәзерге татар романы турында фикер алышу тәртибендә Р. Мостафин, И. Нуруллин һәм Н. Юзиевнең тәнкыйть мәкаләләре басылып чыккан иде. Бу иптәшләрнең чыгышлары, үткен тәнкыйть сүзләре бүгенге романнарыбыздагы җитди кимчелекләрне ачулары турында мин элекке бер мәкаләмдә язган идем инде. Аларның күп сүзлелеккә, максатсыз тасвирлауларга каршы чыгулары, роман язу осталыгына (композиция, архитектоника, сюжет төзеклегенә һ. б.) өндәүләре бик яхшы, урынлы. Ләкин шул ук вакытта, минемчә, мәсьәләнең куелышында берьяклылык та сизелеп үтте. И. Нуруллинның тәҗрибәле әдипләрне романны ничек язарга, җөмләләрне ничек төзергә «өйрәтүләрен» җитди нәрсә, дип әйтеп булмый. Атаклы рус әдибе Константин Федин әйткәнчә, романның ничек язылганын, нинди роман булуын өйрәнеп, әйтеп булса да, роман-

ны ничек итеп язарга өйрәтеп булмый (сүз биредә дәреслекләрдәгечә гади аңлату турында бармый, әлбәттә).

Кайбер мәкаләләрдә «лирик проза» әсәрләрен башкалардан өстен куюы, башка төр, башка стильдәге әсәрләрнең үзенчәлегенә игътибар биреп җиткермәү тенденциясе дә чагылып үткән иде. Атаклы америка язучысы Хемингуэй стилен күз алдында тотып, бер тәнкыйтьченең «айсберг методы» белән язарга өндәве дә шуның белән бәйле булса кирәк. Һичшиксез, экспрессив-лирик проза төрләре, стиле дә үсәргә, бу юлда да яңа эзләнүләр алып барылырга тиеш. Әмма нинди дә булса бер жанрны алга сөрү, бер стильне генә законлаштыру ялгыш адым булыр иде. Совет әдәбияты төрлелекне, иҗади байлыкны яклый бит. Ә «лирик проза»ның исә шактый чикле булуын искәртеп үтәргә кирәк. Лирик прозага хас булган беренче заттан язу, эчке монолог, хат, көндәлек, истәлек-чигенешләр кебек алымнар белән артык мавыгу роман кебек зур эпик жанрда язучының мөмкинлекләрен шактый чикләве күптән билгеле. Мондый әсәрләрдә герой еш кына хәрәкәтсезлеккә дучар була, көрәш, драматизм үткенлеге кими, хикәяләү темпы сүрәнләнә. Мәсәлән, Э. Касыймовның «Гомер ике килми» исемле әсәрендә нәкъ шул йомшаклык нык сизелә дә.

Роман яки зур җитди повесть тормышны объектив рәвештә сәнгатьчә анализлауны, М. Горький әйткәнчә, эпик-пластик сурәтләүне таләп итә. Шул ук вакытта эпопея лирик-романтик элементларга да һич каршы килми. Классикларның тәҗрибәләре дә, хәзерге язучыларыбызның (И. Гази, Г. Бәширов, М. Әмир, Г. Әпсәләмов һ. б.) практикасы да моны ачык раслый. Типиклаштыру, кешенең эчке рухын ачу, социаль-психологик романнарга хас булган башка сыйфатлар, әлбәттә, бүтән төр романнарга да ят түгел.

Социаль-публицистик һәм тарихи-революцион романнар киң колачлы, эпик әсәрләр булып торалар һәм алар җәмгыятьне тулысы белән үз эчләренә алалар. Социаль-публицистик романнарга документальлек, тормыш фактларын тикшерү, киеренке сюжет, тарихилык хас. Публицистик романда еш кына берничә сюжет сызыгы була, әсәрнең композицион структурасын билгеләүдә вакыйгалар өстенлек итә. Мондый романда геройлар, психологик роман белән чагыштырганда, сюжетны оештыруда ул кадәр зур роль уйнамыйлар.

Социаль-публицистик романның иң характерлы мисалларын без Г. Әпсәләмов иҗатыннан таба алабыз. Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», «Газинур», «Мәңгелек кеше» романнары эчтәлекләре белән дә, формалары белән дә, татар прозасына яңа агым алып керде, аны социаль-публицистик яки документаль-публицистик романнар белән баетты. Образлы публицистик стиль Г. Әпсәләмовка үз әсәрләрен романтик буяулар белән сугаруга һич тә комачауламый. Аның сугыш турындагы роман һәм повестьларындагы кырыс, реалистик образлар героик романтика белән сугарылган. Г. Әпсәләмов шулай ук бүтән пландагы роман да иҗат итте. Аның «Сүнмәс утлар» исемле социаль-психологик романы бүтән әсәрләреннән бик нык аерылып тора.

Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы, аерым образлары (Гөлшаһидә һәм Мансур) психологик пландарак эшләнсә дә, төбендә социаль-публицистик (яки документаль-публицистик) романнар характерында язылган. Язучы художестволы публицистиканы монда да мул итеп һәм оста кулланa.

Публицистик роман турында сөйләгәндә без образлы типиклаштыруның классик язучылар тарафыннан ук тудырылган (мәсәлән, Герцен, Салтыков-Щедрин, Чернышевский) үзенчәлекле бер формасын күз алдында тотабыз. Рус әдәбиятын тикшерүчеләр И. Эренбург, К. Симонов, П. Павленко, Б. Горбатов, В. Кожевников, Б. Полевой, А. Бек һ. б.лар иҗатында хәзерге заманда бу төр романның үзенчәлекле үсеш алуын күрсәтәләр.

Минемчә, М. Әмирнең «Саф

күңел» әсәре дә бу төр романнар рәтенә керә. Әлбәттә, романның беренче кисәге («Ялантау кешеләре») икенче кисәгеннән бик нык аерылып тора. Анда автор сугыш чорындагы искиткеч кыенлыклар, совет кешеләре кичергән зур сынаулар, алардагы патриотик хисләр, бердәмлек көче, совет халкының рухи бөеклеге турында сөйли. Бу, үз чиратында, бик табигый, романның структурасын, эчке пафосын билгели. М. Әмир күренешләрне чынбарлыктан турыдан-туры күчереп алмый, ә аларны типиклаштырып һәм гомумиләштереп, ул вакытлардагы булган бөек вакыйгаларны киң эпик планда документаль төгәл итеп гәүдәләндерергә омтыла. Шунлыктан романның стилендә еш кына публицистика калкып чыга.

М. Әмир романының беренче китабында геройларның психологиясенә ул кадәр тирәнтен үтеп керү юк иде. Анда патриотизм, дуслык, совет кешеләренең бердәмлеге идеяләре, алар арасындагы мөнәсәбәт бик күп катлаулы вакыйгалар аша ачыла. Әмма персонажларның, геройларның индивидуаль үзенчәлекләре романның икенче кисәгендә көчлерәк һәм тулырак. Аның «Саф күңел» дигән исеме дә җисеменә бик туры килә.

Татар романнарының өченче төре — тарихи-революцион, тарихи романнар — сугыштан соңгы татар әдәбиятында зур гына урын алды. Бу төр романнарның үсеше — яңадан тууы дисәк тә була — безнең прозабызда җитди әдәби вакыйга, новаторлык булды. Мин монда бу жанрда Г. Ибраһимов традицияләрен дәвам иттергән «Язгы җилләр», «Тукай», «Онытылмас еллар» романнарын күз алдында тотам.

Ә. Фәйзинең «Тукай» романы (М. Галинең Каюм Насыйри турындагы язылып бетмәгән әсәрен искә алмаганда) татар әдәбиятында беренче чын тарихи, дөресрәге, тарихи-биографик роман. Ә. Фәйзи романының үзегендә — тарихи шәхес. Бөек шагыйрьнең балалык һәм яшүсмер елларын сурәтләгәндә, Ә. Фәйзи шул чордагы халык тормышы картиналарын киң гәүдәләндерә. Романның төп фикере Тукай характерын формалаштырган халык чыганакларына, революцион-демократик поэзия чыганакларына юнәлдерелгән. Роман хроникаль-биографик планда язылган. Бу нәрсә кайвакыт эпик хикәяләүдә, чорның иҗтимагый-политик тормышын бөтен катлаулылыклары белән сурәтләүдә авторның мөмкинлекләрен чикли. Романның икенче китабы — җитлеккән шагыйрьне гәүдәләндергән кисәге — икенче пландарак булырга тиеш кебек иде. Ләкин, кызганычка каршы, ул язылып бетмәде — Ә. Фәйзи вакытсыз арабыздан китте. Шуңа да карамастан, романның беренче кисәге яшь Тукай турында төгәл әсәр булып кабул ителә. Ә. Фәйзинең онытылмас тәҗрибәсен һәм иҗатын дәвам иттерүче романчылар табылыр дип ышанам. К. Насыйри, Г. Тукай, Х. Ямашев, Г. Ибраһимов, М. Вахитов, М. Җәлил һәм халкыбызның башка күренекле улларының үлмәс образлары зур эпопея әсәрләренә лаек.

Тарихи-революцион роман үсешенең ныклы милли традициягә, зур тәҗрибәгә ия булуы бәхәссез, аның зур перспективасы бар. И. Газиның күп планлы һәм киң колачлы «Онытылмас еллар» романының ике кисәге басылып чыгу факты да шуны расламыймыни?

«Онытылмас еллар» — киң колачлы эпик әсәр. Аны, безнең уебызча, халык тормышында илдә булган кискен бер тарихи чорны, тарихи-революцион борылыш чорын чагылдырган роман-эпопеяләр рәтенә куярга мөмкин. Язучының аны «повесть» дип атавы моңа һич каршы килми. И. Гази монда «повесть» төшенчәсен киң мәгънәдә, М. Горький һәм Г. Ибраһимовлар үзләренең кайбер әсәрләренә карата кулланган мәгънәдә алган. Билгеле, романда тарихи хроникальлек сыйфаты булуы да аны «повесть» дип атау фикерен тудырган булса кирәк. Әдәбият тарихында андый фактлар аз түгел («Клим Самгин тормышы», «Чапаев», «Тимер ташкын» һ. б.). Кыскасы, «Онытылмас еллар»ны эчтәлегенә һәм структурасына карап,

һич икеләнмичә, роман дип бәяләргә нигез бар.

Минем уемча, автор бу капиталь хезмәтнең өченче кисәген, йомгаклау өлешен дә язар әле. Чөнки икенче кисәктә күп кенә тәмамланмаган, әйтелеп бетмәгән, логик үсешне һәм чишелешне таләп иткән нәрсәләр күп. Эш сурәтләнә торган чорның дәвамын үстерүдә һәм яңа персонажлар кертүдә түгел. Автор вакыйгалар агышына тирәнтен үтеп керергә, романның төп геройларына (Якубка, Хәлимгә һ. б. га) тулырак ачылырга мөмкинлек бирергә тиештер кебек. Ул вакытта романның философик-әдәби концепциясе тагын да ачыграк һәм төгәлрәк булыр иде.

Тарихи-революцион роман үсеше, роман-эпопеянең үзенчәлекләре турындагы мәсьәлә махсус яктыртуны сораган зур мәсьәлә булганлыктан, без биредә аны якын киләчәккә калдырып, гомуми бәя белән генә чикләнәбез.

Безнең әдәбиятта роман жанрының төрләре киләчәктә тагын да киңәер, классика, совет әдәбияты һәм милли әдәбият традицияләре нигезендә яңа типтагы романнар туар әле, дип ышанабыз. Ни өчен, мәсәлән, безнең прозаикларыбызга философик роман, фәнни-маҗаралы роман, көнкүреш, мәхәббәт-семья романы, сатирик роман һ. б. төрләр турында да уйланмаска? М. Ю. Лермонтовның бер идеягә буйсындырылган повестьлар «бәйләме» рәвешендәге роман тибы яки хәзерге Украина язучысы О. Гончарның новеллаларга корылган «Тронка» романы тибындагы әсәрләр формасы да бик кызыклы, үзенчәлекле. Бу форма бигрәк тә Ф. Хөсни, Р. Төхфәтуллин, Ә. Еники, А. Гыйләҗев, Э. Касыймов талантлары, стильләре өчен бик хуш килер иде шикелле. Кыскасы, роман формасы иҗади эзләнү өчен киң мөмкинлек бирә.

Татар романы үсешендә кызыклы һәм әһәмиятле процесслар бара. Бу процесслар романчыларыбызның үз әсәрләре өчен геройларны сайлауларында, киң эпик колачка омтылуларында, композицияне яңа элементлар белән баету формалары буенча эзләнүләрдә күренә. Ул, һичшиксез, роман эчтәлеге сферасының киңәюе, реализм, халыкчанлык һәм югары идеялелек принципларының үсеше, тирәнәюе белән бәйле.

■

# Театр

## «БЕРТУГАН ТАҺИРОВЛАР»

Кайчан булгандыр, вакытын тәгаен генә хәтерләмим инде. Шулай, Татар академия театры фойесында йөргәндә, очраклы рәвештә генә, шактый олы яшьтәге бер ханымның зарын ишетергә туры килгән иде миңа.

— Шушы да театр булдымы инде?! — ди бу, А. М. Горькийның «Дошманнар» исемле, һәммәбезгә мәгълүм классик әсәрен яратмыйча. — Ни көе, ни биюе юк. Көлим дисәң — көләрлек, елыйм дисәң — еларлык түгел. Болай икәнен белсәм, килеп тә йөрмәгән булыр идем...

Ахырдан, безнең театр сәхнәсендә күз яше агызу нияте белән язылган мелодрамалар, уен-җыр, төрле комик номерлар хисабына чамадан тыш «баетылган» музыкаль комедияләр белән күпләп очраша башлагач, еш кына «Дошманнар» спектакленнән зарланган ханымны искә төшерә идем. Бу спектакльләр, мөгаен, аңа ошар иде. Болары нәкъ менә аның зәвыкларына яраклаштырылган, тамашачыны елата һәм көлдерә торган спектакльләр бит инде. Теләсә нинди юллар белән театрга тамашачы тарту, «киң массаны» китерү өчен эшләнгән бу спектакльләр үзләре үк Горький әсәрләрен «юкка чыгаручы» ханымнарны тәрбияләделәр, тамашачының зәвыгын боздылар, татар совет театр сәнгатен артка сөйрәделәр.

Узган сезонда театр Фатих Хөсниненең «Бертуган Таһировлар» драмасын сәхнәгә чыгарды. Башка күп кенә спектакльләрдән аермалы буларак, әсәрдә арзанлы мелодраматизм да, көлке номерлар да, уен-җыр да юк. Ә спектакльне җәмәгатьчелек җылы каршылады, тамашачы драманы бик теләп һәм яратып карады, тамаша залы һәрвакыт тулы булды. Чөнки бу инде башка характердагы драматургия — кыю фикерләр, актуаль проблемалар күтәргән драматургия иде, чөнки бу инде зур, чын сәнгать иде.

Әсәр «Бертуган Таһировлар» дип исемләнгән. Кемнәр, нинди кешеләр соң бу Таһировлар?

Иң өлкәне, Закир — колхоз председателе. Авыр сугыш елларында колхоз хуҗалыгын үз җилкәсендә сөйрәп чыккан кеше ул. РСФСРның атказанган артисты Хөсәен Уразиков башкаруында Закир катлаулы характерлы, каршылыклы образ булып хәтердә кала. Артист һәр урында үз героеның кайчандыр әйбәт кеше булуын сиздереп бара, образның шул ягына басым ясый. Әмма еллар буена Закир бозылган, характерындагы күп кенә әйбәт сыйфатларын экренләп югалта килгән. Югарыдан килгән һәр боерыкны ул сүзсез, бик төгәл рәвештә үтәп килергә гадәтләнгән. Шул ук вакытта Закир үз кул астында эшләүчеләрдән дә сүзсез буйсыну, төгәллек таләп итә. Ул хәзер дан, шөһрәт сөя башлаган. Тәнкыйтьне яратмый, үзеннән түбәндәгеләр белән кырыс, хәтта тупас мөгамәләдә. Ул инде әнә партия оешмасы секретаре белән дә санашырга теләми. «Парторглыкка мин аны үзем күтәрдем», дип кенә җибәрә. Кыскасы, кайчандыр әйбәт, булдыклы булган кеше хәзер кечкенә бер культ кисәгенә әйләнгән. Бүгенге шартларда бу кеше колхоз авылын алга әйди алмый инде. Озак еллар буе өстән күзәтеп, күрсә-

теп, кисәтеп торулар аркасында, Закир үзбаш фикер йөртү сәләтен, кыюлыгын югалткан. Берәр кыен, җаваплы мәсьәлә килеп чыктымы, ул җиңел генә читтә калырга, «райком абый» аркасына ышыкланырга ярата.

Заманалар үзгәрүен, аяк астындагы җирнең йомшый башлаганын Закир үзе дә чамалый. Ләкин нишләсен? Күпме генә тырышса да, ул инде яңа шартларда җитәкчелек итәрлек кеше түгел. Әнә шуңа холыксызланып, тәртәгә тибеп азаплана да ул.

Уртанчысы, Зариф (РСФСРның атказанган артисты Нәҗип Гайнуллин) — өлгер фән әһеле, башта кандидат, ахырдан авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, кафедра мөдире. Бар нәрсәдән элек үз шәхси мәнфәгатен кайгыртучы бу кеше күбрәк власть, дәрәҗә турында уйлый. Зариф — өлкән абыйсыннан акыллырак, алдан күрүчән, сизгер кеше. Абыйсы Закирны да ул заманга яраклашырга, төс-бит алмаштырырга кирәк дип үгетләп-өйрәтеп карый.

Ниһаять, иң кече Таһиров—Заһид (ТАССРның атказанган артисты Шәүкәт Биктимеров). Монысын инде Таһировлар нәселендә «ала карга» санап йөртәләр.

Заһид, илебез азатлыгын яклап, немецларга каршы сугыша, әсир төшә, әсирлектән кача, тагын эләгә. Инде исән-сау килеш, концлагерьдан әйләнеп, илгә кайткач, Заһидны төрмәгә утырталар...

Менә Заһид, ябылудан чыгып, туган авылына кайтып төшә. Биографиясе бик үк чиста булмаган энекәшләрен өлкән Таһировлар шикләнеп, өркеп-куркып каршылыйлар. Хикмәт шунда, Заһид әле бары срогы тулганга гына кайткан икән. Аның өстендәге кара тап юылмаган әле. Кем белә, эшләр ничек бетәр бит. Акларлармы аны, юкмы? Өлкән Таһировларны канат асларына «шикле кеше» сыендыруда гаепләмәсләрме? Дөрес, бу шик-шөбһәләрен алар Заһидка ачыктан-ачык әйтергә уңайсызланалар. Шулай да, монда кайтып, дәрәҗәле урыннарда утырган агаларын борчып йөрмәсә, аларга тынычрак, җайлырак булыр иде канә. Нишлисең, әнә кайткан бит... Шулай итеп, туган җиргә кайту Заһид өчен куанычлы булмый. Бер карасаң, аңа ачык йөз күрсәтәләр, аны кунак итәләр. Ә менә иң зур хыялын тормышка ашырырга юл куймыйлар — Заһидка үзе яраткан эшне бирмиләр. Заһид, эш эзләп, туган-үскән авылыннан чыгып китәргә мәҗбүр була. Бер заман дөньялар үзгәреп китә, Заһид өчен дә уңай көннәр килә. Аның өстенә ташланган кара тап юып алына, ул үзе яраткан эшенә кайта. Бу үзгәрешләр Закирны да читтә калдырмый. Аңа озак еллар бүе утырган председатель креслосы белән саубуллашырга туры килә.

Күрәсез, начарлык, әшәкелек фаш ителә, гаделлек җиңеп чыга. Әгәр Ф. Хөсни шушы урында нокта куйган булса, әсәр бары әнә шул күптән билгеле хакыйкатьне тагын бер мәртәбә кабатлау өчен генә язылган булса иде, ул чагында автор бу драмасы белән безнең сәнгатькә бернинди дә яңалык өстәмәгән булыр иде. Бәхеткә каршы, әсәрнең идея эчтәлеге күптән билгеле әйберләрне кабатлау белән генә чикләнми.

Әсәрдә Зариф бар бит әле. Бу образга, ул үзе күп урын биләмәсә дә, зур эчтәлек салынган. Менә бу — уртанчы Таһиров инде беркайчан да югалмас, беркайчан да хур булмас. Бу тип шәхес культы елларында рәхәтләнеп яшәде, киемен, төс-битен аз гына үзгәртеп алды да, безнең көннәрдә дә начар яшәми. Аның төп алласы — конъюнктура. Бу — менә дигән бюрократ. Фән, авыл хуҗалыгы мәсьәләләре аны һәрнәрсәдән дә азрак борчый. Аның төп һөнәре — заманга яраклашу, җайлашу. Диктаторлык, баш бирмәскә тырышу кебек начар гадәтләре булса да, Закир табигате белән беркатлы кеше. Зариф исә аннан мең мәртәбә әшәкерәк, күп тапкыр куркынычрак. Шуның өстенә Зариф төсен үзгәрткән, кабык астына яшеренгән ерткыч. Бар, белеп кара син аның кем икәнен, чын асылын. Әсәрдә, беренче карашка, Зариф фаш ителми, аның чын йөзе ачылмый кала кебек. Чынлыкта, автор аны фаш итә, тик сәнгать алым-

нары белән фаш итә. Һәм, минемчә, әсәрнең уңышы да әнә шунда.

Фатих Хөсни, бик талантлы, үзенчәлекле прозаик буларак, укучыларга яхшы таныш. «Бертуган Таһировлар»ы белән ул үзен кызыклы, үзенчәлекле драматург итеп тә танытты. Менә бер генә эпизод:

«З а һ и д. Гөләндәм әйтмәсә, алайса син әйт, Мәхмүт: кайчан да булса, нинди дә булса шаукымга кушылып, син минем турыда «Заһид— немец шпионы» дип башыңа китердеңме? Башыңа китерә алдыңмы?

М ә х м ү т *(сүзсез)*.

З а һ и д. Янган танк эчендә бергәләп таранга барган иптәшең турында? Юк, син миңа күңелеңдә ни бар — шуны әйт: китерә алдыңмы?

М ә х м ү т *(эндәшми)*.

З а һ и д. Дөрес, госпитальдән соң безнең юлларыбыз аерылды. Без бер-беребезне белмәдек.

М ә х м ү т *(Заһидка җавап бирүдән бигрәк, үзе белән үзе сөйләшкәндәй)*. Юк, без бер-беребезне онытырга тиеш түгел идек. Түгел идек! Нәрсә әйтмәсләр безгә? Без шуларның барысына да сукыр килеш ышанырга тиеш булдык микәнни? Кайда иде соң безнең үз башыбыз?»

Күрәсез, кешеләр хәзер үзбаш, мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәнеп киләләр, алар инде гади шөреп кенә булып калырга теләмиләр. Халык аңындагы шушы яңарышны Ф. Хөсни күреп ала белгән. «Бертуган Таһировлар» драмасының кыйммәте, минем уемча, әнә шул заманчалык рухы, тормыштагы яңалыкны күрсәтә белү белән билгеләнә дә.

Инде спектакльнең үзе турында берничә сүз. Тулаем алганда, бу спектакль һәм режиссер Ш. Сарымсаковның һәм театр коллективының, һичшиксез, уңышы. Шул ук вакытта, әсәрне сәхнәгә куюда безнең театрның көчсез яклары да үзен шактый ачык сиздерә. Безнең артистлар кайгыра һәм шатлана, моңлана һәм нәфрәтләнә торган образларны әйбәт уйныйлар. Тик менә у й л ы й д а б е л ә торган образлар иҗат итәргә гадәтләнмәгәннәр. Бәлки, нәкъ менә шуның өчендер дә, «характерлы герой» амплуасына сыеп бетәрлек Әкълимә образы гына (В. Минкина) башкалардан уңай якка аерылып тора. Ә иң кирәкле, үзәк образ — парторг Мәхмүт (артист Әюпов) Әкълимәдән күп сүлпәнрәк, төссезрәк. Әюпов бер дә ялгышмыйча, бутамыйча ятлаган сүзләрен сөйли, образның сурәтен, тышкы рәсемен уйный, ләкин эчке дөньясын, уйлау сәләтен күрсәтә алмый. Ш. Биктимеровның Заһидында да шундый ук кимчелек сизелә. Урыны-урыны белән Заһид-Биктимеров артык нервчан, истерикага бирелүчән, үзен кызгандырырга, җәлләтергә тырыша. Ә бит әсәр буенча, Заһид андый образ түгел, һәм шәхес культы чорының төп корбаны да ул түгел — аның абыйлары. Шәхси дәрәҗәләре, утырган креслолары бәрабәренә хәтта туган энекәшләреннән йөз чөергән Зариф белән Закир.

«Бертуган Таһировлар» спектакле, тагын бер мәртәбә, безнең Академия театрына интеллектуаль культура җитмәүне күрсәтә. Ә шунсыз бүгенге театр сәнгате алдында торган зур, катлаулы, күп төрле бурычларны хәл итеп булмаячак.

**Р. МОСТАФИН.**

■

## Китап күзәтү

# ШАГЫЙРЬ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Чиксез күккә, ерак йолдызларга
Ракеталар ничә очты бездә
Сез, кешеләр — биек йолдызлар бит,
Житә алсам иде күңелегезгә.

Заман сулышы бөркелеп торган бу строфаның кемнеке, кайсы шагыйрьнеке булуы поэзия сөючеләр өчен сер түгелдер... Шушы бер строфада Рәсүл Гамзатов талантының, аның кешеләргә чиксез мәхәббәте тудырган ярсулы, шук, мөлаем лирикасының фәлсәфи тирәнлеге, ягымлы гүзәллеге чагыла.

«Биектәге йолдызлар» — әдипнең Ленин премиясе белән бүләкләнгән шигырьләр җыентыгы. Ниһаять, ул җыентык, Н. Арсланов, Ә. Давыдов, З. Нури, Г. Хуҗиев, Г. Латыйп, М. Хөсәен, Ә. Баянов, Р. Гәрәй, Х. Камалов һәм Н. Мадьяров кебек шагыйрьләребез тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, аерым китап булып чыкты [1]. Җыентык белән танышкач, шул нәрсә сизелә: шагыйрьләр каләмдәшләренә игътибарлы булырга тырышканнар, Р. Гамзатов поэзиясенең матурлыгын татар укучысына җиткерү өчен күп көч куйганнар.

Р. Гамзатов иҗатында тапкыр һәм матур әйтелгән һәрбер шигъри деталь мәгънәне ачыклый, образны тәгәлләндерә бара. Җылы лиризм, кешеләргә тирән мәхәббәт белән язылган ул шигырьләрдә батыр һәм эшчән дагстан халкы белән очрашасың, бик талантлы һәм үзенчәлекле шагыйрьнең үзен күргәндәй буласың. Шагыйрь йөрәгенең кайнарлыгы, егәрлеге аның шигырьләренә күчә.

[1] Р. Гамзатов. Биектәге йолдызлар. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1964 ел.

Менә ир уртасы кавказлы тибын күз алдына китерегез. Чәчләре уң як кашка төшеп тора. Чал. Калынрак гәүдәле. Барлык кешеләрне дә бер очтан кочып алырга теләгәндәй, кулларын җәйгән дә, шигырь укый. Тавышы басынкы, интонацияләр сиздермичә генә үзгәреп тора.

Биек таулар итәгенә
Мендем дә мин, — җан горур, —
Елгалардан йолдыз эчтем
Учлап-учлап, әй хозур.

Чын поэзия үзенең фидакарьлеге, эчкерсезлеге, күңел киңлеге белән укучыны җәлеп итә. Андый әсәрләр белән танышканда нинди милләттән булуыңа, нинди киңлектә яшәвеңә дә карамастан, син үзеңне кешелекнең бер тамчысы итеп тоя башлыйсың, дөнья яктырып, киңәеп китә. Чын мәгънәсендәге менә бу гуманизм Рәсүл Гамзатов иҗатының көчле сыйфаты. Рәсүл Гамзатов «Туган илем турында» шигырендә «чит илләрдә туганнарың бармы?», «әсирлектә булдыңмы?» дигән салкын сорауларны да ала, шук елмаю һәм тирән лиризм белән җавап бирә — бар. Әнә аның туганнары: Стамбулның тар урамнары чатында эш эзләп йөрүче төрек карты. Күр, кыяфәте гел шагыйрьнең атасыныкы инде. Әнә аның әнисенә охшаган Кипр карчыгы — кораб артыннан кул болгап кала. Шагыйрьгә канәфер чәчәкләре бүләк иткән француз кызы аңа сеңелесен хәтерләтә. Ничә еллар салкын төрмәләрдә яткан Манолес Глезос, коллык богауларын өзгән африкалылар... Менә никадәрле аның туганнары!

Шагыйрь «әсирлектә» дә булган. Чехлар аны мәңгелек дуслык белән

әсир иткәннәр, рус солдатларының каберләрен розаларга күмгән болгар халкы да шагыйрь күңелен әсир иткән. Хәер, барысын да санап бетерү мөмкинмени?!.

Әйтерсең, жир иркенәя бара һаман,
Шуңа күрә чын күңелдән горурланам.
Никадәрле тарсынса да жирне дошман,
Арткан саен арта бара безнең дуслар.

*(Г. Латыйп тәрҗемәсе)*

Рәсүл Гамзатовның образлар дөньясы гаять бай һәм күпкырлы. Ул гаҗәп бер киномонтажны хәтерләтә. Шагыйрь өчен искергән образлар юк. Һәрбер образга — традиционмы ул, яңамы — Рәсүл Гамзатов каләме үзенчәлекле төс бирә. Менә «Сандугач жыры» шигыре. Көнчыгыш шагыйрьләреннән Хафиз белән Гомәр Хәйямны гына искә төшерик. Аларда сандугач — мәхәббәт лирикасының аксессуары. Рәсүл Гамзатов исә сандугачны туган ил турында жырлата.

Мөгаен ул Ватан турында
Жырлыйдыр. Югыйсә,
Бик тиз туяр иде сандугач
Икенче жыр булса.

*(Ә. Баянов тәрҗемәсе)*

Рәсүл Гамзатов — мәхәббәт лирикасының зур остасы. Монда аның поэтик арсеналындагы барлык чаралар: телнең афоризмнарга байлыгы, реалистик төзеклек, шигъри бизәкләрнең нәфислеге, формада иркенлек һәм динамик йөгереклек — барысы да мәхәббәтне олылауга, мәхәббәт хисләренең матурлыгын ачуга юнәлдерелгән.

Сигез юллыклар бүлеге Рәсүл Гамзатовның чор һәм кеше турында житди уйлануларын, тормыш куйган барлык сорауларга, шагыйрь һәм гражданин буларак, жавап эзләвен күрсәтә.

Дан! Исәннәргә кагыла күрмә,
Аларны гаять начар беләсең.
Кайчак иң яхшы кешеләрне дә,
Көчлеләрне дә син үтерәсең.
Дан! Үлгәннәргә кирәгрәк син,
Үлгәннәр өчен һич юк зыяның.
Кайнар сулышың белән яңадан
Кайтарасың син гомерен аларның.

*(Н. Мадьяров тәрҗемәсе)*

Горур һәм батыр тау халыкларында гасырлар буе шундый күркәм гадәт яшәп килгән: алар иярләрне, мөгез җамнарны, хәнҗәрләрне, хәтта сабыйлар яткан бишекләрне дә нәфисләп язылган афоризмнар белән бизәгәннәр. Бу язмалар, шулай ук, буркаларга, капкаларга, музыка коралларына һәм таякларга да ясалган. Алар халыкның гасырлар кичкәндә җыйган тәҗрибәсен, акыл көчен, тапкырлыгын чагылдыралар. Рәсүл Гамзатов халык иҗатының бу энҗеләре белән гаять сак эш иткән: оста ювелир сыман, аларга тиешле форма биргән, шомарткан, ялтыраткан. Шулар үрнәгендә үзе дә яңа язмалар тудырган. Бу парчаларның эчтәлеген сөйләү авыр. Аларның кечкенә генә күләмнәрендә гаять киң һәм тирән поэтик фикерләр ята. Берәүләре аның халыкның милли характер сыйфатын чагылдыра, икенчеләрендә кеше гомереңең, яшәүнең мәгънәсе турында сөйләнелә...

Билгеле булганча, авар шигырендә юл азакларында рифма кую системасы түгел. Традицион форма булып юлларда цезуралар, аллитерацион аваздашлык һәм кабатлауларның еш очравы исәпләнә. Строфа гадәттә 12, 11, 9 һәм 8 иҗекле үлчәүләргә корылган. Рәсүл Гамзатов кирәк урында, темага карап, бу үлчәүләрнең барысын да куллана. Ә сигез юллыклар 7 иҗекле үлчәү белән язылган. Бәлки, шигырьнең нинди үлчәү белән тәрҗемә ителүе бәләкәй мәсьәләдер. Бәхәсләшеп тормастан, мисал китерик. Менә «Чибәр кызлар» шигыре:

Куллардагы тамыр кебек безнең дуслык,
Төйнәлгән ул бер төенгә һәм ул бик нык.
Туган илдән еракларда йөргәнем бар,
Кая барма, тоташалар безнең юллар.

*(Г. Латыйп тәрҗемәсе)*

Инде шигырьнең русчасына күз төшерик:

С товарищами дружбою горячею
Я связанный, как жилки на руке,
Обременен нелегкою задачею,
Бывал не раз от дома вдалеке.

*(Я. Козловский тәрҗемәсе)*

Мәгънәдә генә түгел, строфаның төзелешендә дә гаять зур аерма. Та-

тарчасындагы ритмик сурәт укучының тойгысын, ничектер, М. Гафури иҗаты башланган чорга алып китә. Русчасында исә ул заман колоритына буйсына.

Икенче бер мисал:

Йөрәгемә таулар якын,
Мин тауларга илтәм йөрәгемне.
Аста — роза үзәнлеге
Һәм виноградлары Фракиянең.

Бу юлларның тәрҗемәсе тәҗрибәле шагыйрь Г. Хуҗиевныкы булуына һич тә ышанасы килми. Ә бит шагыйрь шул ук «Болгария дәфтәре» циклында гаҗәп матур поэтик бизәкләрне саклый белгән, күп шигырьләрне бик уңышлы тәрҗемә иткән. Тәрҗемәдәге чатаклыкларның күбесе игътибар җитмәүдән килә. «Туган илем турында» шигырен генә алыйк. Лирик герой җир йөзендә яшәүче барлык яхшы күңелле кешеләрне үзенең туганнары дип атый. Әсәрнең төп идеясе шул. Шигырьнең икенче исеме дә бар — «Туганнарым турында» («О моей родне»). Сюжет лирик геройның сәяхәте вакытындагы кичерешләре формасында үсә. Тәрҗемәче, юлда йөрүче геройның хисләрен татарча бирү өчен, фигыль формасын дөрес сайламаган.

Тар урамнар почмагында очрый да ул
Ярлы йортлар тынып калган кичке якта,
Үз улына карагандай карый миңа,
Күңелендә ышаныч һәм өмет арта.

*(Г. Латыйп тәрҗемәсе)*

«Очрый», «карый» булгач, эшнең кабатланып торуы, тәмамланмаган булуы аңлашыла. Ә бит шагыйрь ул картны бер генә кат күреп кала. Монда «очрады», «карады» дигән форма кирәк иде. Русчасына гына игътибар итик.

Где бедной улицы теснина
Утихла на закате дня,
Он, повстречавшись, как на сына,
Взглянул с надеждой на меня.

Аннан соң, урамнар почмагында дип әйтү дә татарча түгел, дөресе — урам чаты, урамнар чаты.

Бәхеткә каршы, җыентыкта мондый кимчелекләр сирәк очрый. Чатаклыкка караганда, уңышлы яклар, матур табышлар күп һәм алар турында сөйләү кызыклы да булыр, урынны да байтак сорар иде. Без язмалар бүлегенең матур тәрҗемә ителүен әйткән идек инде. Укучы, шулай ук, «Дөнья барда» (Ә. Давыдов тәрҗемәсе), «Тау бөркетләре», «Сөям сине, бәләкәй халкым», «Кан һәм күз яше» (З. Нури тәрҗемәләре), «Дагстаным минем», «Әнкәйгә» (Р. Гәрәй тәрҗемәләре), «Безнең авыл елгасы», «Сандугач җыры» (Ә. Баянов тәрҗемәләре), «Вакыт турында» шигырьләр һәм Фидель Кастрога совет кешеләренең кайнар мәхәббәтен чагылдырган «Эчкерсез, саф сөю турында мин» (Г. Хуҗиев тәрҗемәләре), сигез юллыкларны тәрҗемә иткән Н. Мадьяровның тырышлыгын һәм кайбер уңышларын күреп куаныр.

Рәсүл Гамзатов — хәзерге совет поэзиясендә иң талантлы лирикларның берсе. Көнчыгыш, рус, Европаның иң зур акыл иясе шагыйрьләре иҗатыннан, дагстан халыкларының гаҗәп бай фольклорыннан куәт алып үскән бу поэзия бүгенге көн кешесенең рухи дөньясындагы гаять тирән кичерешләрне мул төсмерле һәм нәфис бизәкле итеп сурәтли. Рәсүл Гамзатовның поэзиягә мөнәсәбәте, аның эстетикасы безнең талантлы шагыйрьләребездән Һади Такташ, Хәсән Туфан, Муса Җәлил һәм Сибгат Хәкимне хәтерләтә. Татар укучысына ул якын һәм аңлаешлы. Җыентыкның чыгуы бик урынлы. Өстәп шуны гына әйтәсе килә: әйдә, «Биектәге йолдызлар», рәхим ит укучы күңеленә, үз артыңнан шагыйрьнең яңа тәрҗемәләрен дә иярт.

М. ШӘЙМӨХӘММӘТОВ.

■

# Муса Җәлил юбилеен каршылап



*Муса Җәлил. В. Е. Цигаль* скульптурасы (проект).

*Советлар Союзы Герое, легендар шагыйребез Муса Җәлилнең 60 еллык юбилее якынлаша. Бу зур юбилей бөтен илебездә киң күләмдә билгеләнеп үтәчәк.*

*Журналыбызның бу санында без немец әдибе Франц Лешнитцерның «Моабит дәфтәре» безнең өчен дә язылган» исемле мәкаләсен урнаштырабыз. Франц Лешнитцер Германия Демократик Республикасында яши. Ул Муса Җәлил иҗатын пропагандалауга күп көч куйган, патриот шагыйребезнең шигырьләрен һәм поэмаларын немец теленә тәрҗемә иткән күренекле язучыларның берсе. Аның бу мәкаләсе Берлинда атнага бер тапкыр чыга торган «Зонтаг» исемле әдәби альманахның узган елгы 34 санында басылган. Журналда мәкалә бераз кыскартылып бирелә.*

## *Франц Лешнитцер*

## «Моабит дәфтәре» безнең өчен дә язылган

**Иске бозык гадәт татарларны ерткычлар белән бер дип саный. Татар шагыйре Муса Җәлилнең батыр тормышы һәм иҗат эшчәнлеге әлеге шовинистик явыз уйдырманың көлен күккә очыра.**

...1958 ел. Мәскәү. Без — Андрэ Тиммерманс, аның хатыны, Леон Небенцаль, Эрих Мюллер һәм шушы юлларның авторы — Әминә ханым Җәлил өендә утырабыз. Минем кулда — «Моабит дәфтәре». Карыйм: кечкенә, бик кечкенә битләр. Әйтерсең лә, тәмәке төрү өчен хәзерләнгән нәни кәгазь кисәкләре! Алар пөхтә итеп язылган гарәп хәрефләре белән чуарланганнар. Уйлыйм, бу бит дим, хәзинә, сирәк очрый торган хәзинә. Тагын шунысы күңелне дулкынландыра: фашистлар зинданында үлем көтеп яткан хәлдә дә шагыйрь чын немецлар белән гитлерчылар арасындагы аерманы күрүдән туктамаган. Бу — искитәрлек факт. Чыннан да. Әйтик, Эрих Вейнерт үзенең сугыш башланыр алдыннан язылган бер поэмасында «чын немец» һәм Гитлер иярчененә әверелгән «немец» турында яза икән һәм ул әлеге ике немецны бер-беренә каршы куеп, гыйбрәтле контраст тудыра икән — бу безнең өчен үзеннән-үзе аңлашыла торган нәрсә.

Әмма ләкин әлеге контраст немец төрмәсендә иҗат ителгән шигырьдә — үзенең совет әсире, милләте ягыннан татар булганы өчен фашист албастылар тарафыннан көн-төн әдәм күрмәгән җәзаларга, мәсхәрәләргә дучар ителгән хәлдә язылган шигырьдә чагыла икән — моны инде үзеннән-үзе аңлашыла дип булмый. Бу — тирән эчтәлекле күренеш. Барыннан да элек бу факт Муса Җәлил рухының ленинизм тәгълиматына нигезләнгән интернациональ эчтәлеге ни дәрәҗәдә какшамас нык булуы турында сөйли.

Икенче фикергә дә нигез җитәрлек: тирән газаплар эчендә шагыйрь чын немецларга үзенең дуслык, туганлык хисен багышлаган икән — димәк, Муса Җәлилне тудырган татар халкы бер үк вакытта культуралы да, бөек тә.

Әйтергә кирәк, чын немецларга булган ихтирам һәм хөрмәт Муса Җәлил иҗатында эпизодик күренеш түгел. Әминә ханым Җәлил, татар әдәбияты белгече Роберт Бикмөхәммәтов икърар итүенчә, Муса Җәлил элек-электән үк немец музыкасына, аның олы вәкилләре — Бах, Гендель, Бетховен, Вагнер, Брамс, шулай ук Шёнбер иҗат иткән музыка әсәрләренә гашыйк булган. Шушы тирән мәхәббәт хисе Муса Җәлилне 18 яшьтә үк инде үз иҗатында немец пролетариаты темасына тавыш бирергә этәрә һәм нәтиҗәдә «Фрагментлар» исемле поэма дөньяга килә. 29 яшендә исә, ягъни Германиядә фашистлар түрәлек кылган 1935 елда, шагыйрь яңадан фашизмга каршы көрәш темасына әйләнеп кайтып, үзенең «Джим» исемле поэмасын яза. Шушы әсәрләр рәтендә «Алман илендә» шигыре күптән яңгырагач җырның турыдан-туры дәвамы кебек кабул ителә. Мәгәр шуңа да карамастан, Германия темасына багышланган соңгы шигырь, ничектер, укучыда гаҗәпләнү, искитү тойгысы уята. Әминә ханым Җәлил «Моабит дәфтәре»нең немец телендәге басмасына язган кереш сүзендә бу турыда болай ди:

«Яшермим, «Алман илендә» шигырен беренче мәртәбә укып чыккач, минем исем китте. Ничек дим, бу шигырь узган сугышның ачы нәфрәт, тирән дошманлык белән сугарылган атмосферасында иҗат ителә алды икән».

Әминә ханым Җәлилнең болай гаҗәпләнүе, әлбәттә, табигый. Хәлбуки, факт күз алдында — шигырь язылган. Димәк, дәһшәтле сугыш мөхите Муса Җәлил хыялында тамыр җәйгән чын Германияне — кешелеккә бөек философларын, галимнәрен, тәнкыйтьчеләрен биргән Германияне кысып чыгара алмаган. Нәкъ менә шушы нәрсә — немец тормышындагы алгарышка ия булган якты мирасны ихтирам итү, аны актив рәвештә раслау — «Моабит дәфтәре»н безгә, Германия Демократик Республикасы гражданнарына якынайта да. Әйе, ул безнең өчен дә язылган.

Борыгыз муйнын комсыз карчыганың,
Кояш чыксын Алман җиренә.
Күтәрелсен Тельман трибунага,
Маркс, Гейне кайтсын иленә.

Әйдә, шулай булсын. Шагыйрьнең бу изге теләге Көнбатыш Германиядә дә тормышка ашсын!

Немецчадан кыскартып тәрҗемә итүче —
*Ш. ӘХМӘДУЛЛИН.*

■

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

# КОММУНИСТ БУЛУ— КӨРӘШЧЕ БУЛУ

**Галимҗан Нигъмәти турында кайбер яңа материаллар**

Татарстан китап нәшрияты 1958 елда күренекле әдәбият белгече Галимҗан Нигъмәтинең «Сайланма әсәрләр»ен чыгарган иде. Бу җыентыкта аның бары тик татар әдипләре иҗатын тикшерүгә багышланган тәнкыйть мәкаләләре, монографик хезмәтләре генә тупланып бирелде. Соңгы елларда әдәбият галимнәребезнең һәм тәнкыйтьчеләребезнең аерым мәкаләләрендә дә Г. Нигъмәтинең әдәбият фәне өлкәсендәге хезмәтләренә шактый тулы, төпле бәя бирелде. Ләкин, кызганычка каршы, Галимҗан Нигъмәтинең тормыш юлы һәм иҗтимагый эшчәнлеге турында без бик аз беләбез: «Сайланма әсәрләр»дә аның тормыш юлы турында нибары бер бит материал бирелгән. Галимҗан Нигъмәтинең иҗтимагый эшчәнлеген ныклап өйрәнү аның әдәбият фәне өлкәсендәге хезмәтләрен яхшырак аңлау өчен дә ярдәм итәр иде. Чөнки Г. Нигъмәтинең әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче булып формалашу юлы шактый үзенчәлекле һәм гыйбрәтле.

Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укыганда ук, Г. Нигъмәти Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ш. Бабич, Ф. Сәйфи-Казанлы кебек күренекле әдипләр белән очрашып яши һәм шул вакытлардан башлап әдәби иҗат эше белән кызыксына. Башкорт шагыйре Сәйфи Кудаш белән бергәләп, алар «Парлакъ»[1] исемле кульязма әдәби журнал чыгаралар. Яшь шәкерт Нигъмәти үзенең беренче, өйрәнчек шигырьләрен шул журналда чыгара. Октябрь революциясе җырчысы Шамун Фидаи да (Касыйм Шакирҗанов) «Галия»дә Г. Нигъмәти белән бер чорда укыган. Нигъмәтигә бүләк иткән рәсеме артына ул болай дип язган:

«Галимҗан иптәш! Менә бу рәсем сиңа бөек инкыйлабның көчле дулкыннары арасында гөрләшеп яшәгән, тормыштан риза булмаган, ләкин киләчәккә өмет баглаган Касыйм Шакирҗанның мәңгелек истәлеге.

«Галия»дә сыйныфташлар».

Октябрь революциясен Нигъмәти һичбер икеләнүсез кабул итә һәм революциянең беренче елларыннан ук, җиң сызганып, яңа тормыш төзү эшенә катнаша. Башта, берникадәр вакыт, Г. Нигъмәти Көнчыгыш фронтта 5 Армия каршында чыга торган «Кызыл яу» газетасында эшли. «Кызыл яу» 5 Армиядә татар телендә чыга торган бердәнбер газета була. Газетаның 1919 ел 3 март санында шундый бер хәбәр басылган: «Кызыл яу» идарәсеннән безнең шушы хатыбызга урын бирүен үтенәбез,— диләр аны язучылар.— Революциянең барышында һәм гомумән тарихи үзгәрешләрдә, бигрәк тә хәзер — җир йөзендәге көнкүреш бөтенләй икенче бер юлга салынып, яңа дөнья төзелеп яткан бер дәвердә бер партиянең дөньяга чыгуы, икенче бер партия-

[1] Бу журналның бер саны С. Кудашта саклана.

нең бетүе, яисә ике партиянең берләшүе тарихи вакыйгаларның теләве белән килеп чыккан эшләрдер.

...Иҗтимагый революция юлында сәяси пакьлек белән эшләү намына без, түбәндә кул куючылар, сул эсерлар партиясенең татар-башкортлар оешмасыннан чыгып, коммунист (большевиклар) партиясенә керергә карар бирдек».

Хатка кул куючылар арасында Г. Нигъмәтинең дә имзасы бар.

«Кызыл яу» газетасында эшләгәндә Нигъмәти, политбүлек кушуы буенча, Колчак гаскәрләренә ташлау өчен листовкалар да язып бастыра. Соңыннан аларны аэропланнардан дошман тылына ташлаганнар. Никадәр эзләсәк тә, 5 Армиянең татар телендә чыккан листовкаларын бүгенге көнгә кадәр беркаян да таба алмадык. Бер Г. Нигъмәтинең эшчәнлеген бәяләү өчен генә түгел, шул еллардагы революцион көрәшне өйрәнү өчен дә алар чиксез кыйммәтле документлар була алырлар иде. Бер дә юкка гына ПУР Көнчыгыш фронтының политбүлегенә: «Дошман тылына аэроплан белән сезнең частьлар тарафыннан никадәр әдәбият ташланганын һәм бу эшнең даими яки очраклы рәвештәме икәнлеген ашыгыч хәбәр итегез»[1] дип, телеграммалар җибәрмәгәндер?!.

Бу листовкаларның Колчак армиясен таратуда нинди зур роль уйнаганлыгын тагын бер документ раслый. Көнчыгыш фронтның политбүлек начальнигы Үзәк Комитетка җибәргән хатында: «Дошман ягыннан качып чыккан солдатлар аэроплан белән таратылган «коралларыгызны ташлагыз, бирелегез» дигән листовкаларның бик кирәк икәнен раслыйлар»[2], дип яза. «5 Армия татар-башкорт кызыл яулары арасындагы эшләребез»[3] дигән мәкаләсендә Х. Гайсин шул ук фикерне куәтли: «...Болардан башка тагын Колчак тарафыннан көчләнеп мобилизовать ителгән татар, башкорт егетләрен безнең якка чыгарга өндәп, шуралар хакимиятенең нинди хакимият икәнлеген аңлатып, аны аклар тарафыннан ыргытылган пычраклардан уеп, аның эшче вә крестьяннарның гына файдасын күзәтә торган бер хакимият икәнлеген төшендерергә тырышып, «Өндәү» исемендә үзләренә махсус газета чыгарып, төрле хитабнамәләр[4] язып, фронт аша, аэропланнан ыргыттырды».

Революция казанышларын саклап калу өчен изге көрәшкә күтәрелгән халык армиясе Колчак бандаларын себереп түккәч, Галимҗан Нигъмәти, яңа газета чыгару өчен, Омскида кала.

«19 елның соңгы айларында Колчак, чех-словак ак бандаларын тар-мар, зир-зәбәр китереп баручы 5 Армиянең сәяси шөгъбәсе ул вакытларда Себернең мәркәзе Омск шәһәренә килеп җиту белән байтак кына гыйльми көчләр биреп калдырды, — дип язды 1921 елда «Азат Себер» газетасы. — Шул вакытка кадәр чыгып килгән «Кызыл яу» газетасының идарәсе һәм матбагасы да Омскида калдырылып, Фәхри Әхмәтов, Самат Шәрәфетдинов, Галимҗан Нигъмәти вә башка берничә иптәшләр декабрь числосының ахырларында «Азат Себер» газетасын чыгара башладылар».

Нигъмәти бу газета редакциясендә секретарь хезмәтен үти. 1929 елда, 10 еллык юбилей уңае белән, «Азат Себер» газетасы Г. Нигъмәтине үзенең беренче редакторларыннан санады һәм ул чорда «Совет властеның төзелешен аңлатуда газета зур гына урын тотты»[5], дип билгеләде.

1921 елда Нигъмәти Көнчыгыш хезмәт ияләренең Коммунистик университетына (КУТВ) укырга китә. Бу турыда «Азат Себер» махсус белдерү белән чыга:

«Шәрыкъ телләре, шәрыкъ әдәбияты белән төпле рәвештә таныш, талантлы, көчле каләмгә малик ип-

---

[1] Совет Армиясенең Үзәк дәүләт архивы (ЦГАСА), 106 фонд, 2 опись, 330 эш, 188 документ.

[2] Шунда ук, 14 эш, 201 документ.

[3] «Кызыл Армия» газетасы, 1919 ел, 116 сан.

[4] Хитабнамә — өндәмә, листовка.

[5] «Азат Себер» газетасы, 1929 ел, 96 сан.

тәш Г. Нигъмәтинең шәрыкъ институтында күп мәгълүмат алып, киләчәкнең тагын да көчлерәк, Россиядә генә түгел, барлык шәрыкъның хезмәт иясе булуына нык ышанып калабыз»[1].

Күренекле марксистлардан лекцияләр тыңлау, фән, әдәбият белгечләре белән аралашу яшь журналист Нигъмәти өчен чиксез әһәмиятле булды. Нәкъ шушы елларда Г. Нигъмәти газета-журналларга төрле темаларга караган мәкаләләр яза, татар теленә марксизм-ленинизм әдәбиятын тәрҗемә итә.

1922 елда «Яшь эшче» журналының 1 санында Г. Нигъмәтинең «Карл Маркс безгә нәрсә калдырды?» дигән зур мәкаләсе чыга. Ә 1924 елда дарвинизм нигезләрен аңлаткан «Адәмнәр ничек яратылган?» һәм «Ленин һәм пролетариат революциясе» исемле хезмәтләр яза. Шул ук елны СССР халыкларының Үзәк нәшриятында аның «Коммунизм турында» дигән китабы басылып чыга.

«Коммунизм турында» — татар телендә иң уңышлы марксистик дәреслекләрдән берсе иде. Вакытлы матбугат бу китапка зур бәя бирә. Томск партия мәктәбе укучысы К. Гыйрфанов Нигъмәтинең бу хезмәте турында: «Язучы кыска, ләкин ачык... җөмләләр белән безгә коммунизмның төп нигезләрен, аның тууы өчен кирәкле булган шартларны, аны тудыручы фактларны, күчү дәверен, ниһаять, гыйльми коммунизм назариясенә нигез салучылар, бу назарияне практикада үткәрүчеләр турында, тагын әйтәм, кыска ләкин бик ачык, бик тулы иттереп сөйләп бирә»[2], дип язды.

Г. Нигъмәти вакытлы матбугатта марксистик әдәбият турында күп санлы рецензияләр яза, татар телендә беренче политик сүзлек төзүдә катнаша. Болардан тыш ул «1905 ел» һәм «Көнбатыштагы сыйнфый көрәшләр тарихы» исемле зур күләмле әсәрләр өстендә эшли.

Татар марксистларына мөрәҗәгать итеп, Г. Ибраһимов болай язган иде:

«Башка күп турыларда тәрҗемә белән канәгатьләнергә мөмкин булса да, тарихи материализм юлында эшче-крестьян массасының теләгән тәрҗемә белән генә үти алмабыз. Бу назариянең нигезләре ачык, тулы аңлашылсын өчен... тарихи материализм нигезләрен өйрәнгәндә, өйрәткәндә татар эшче-крестьянының үзенә якын тормыштан мисаллар алынырга, рус, европа марксистлары китергән моментлар белән генә тукталмыйча, безнең массаның тирә-юнендә күренгән Көнчыгыш ислам татар дөньясының мисаллары, фактлары материал итеп тикшерелергә тиешле»[3]. Г. Нигъмәтинең марксизмны пропагандалауда үзенчәлеге әнә нәкъ шулай, эшче-крестьянның үзенә якын тормыштан алынган мисаллар белән оста эш итүендә күренде дә.

20 нче елларда Г. Нигъмәти яңа типтагы совет мәктәпләре өчен дәреслекләр чыгару буенча да күп эшли. Мәсәлән, 1924 елда ул, Б. Мансур белән берлектә, беренче баскыч мәктәпләр, совпартшколалар һәм педтехникумнар өчен әдәбияттан хрестоматия төзергә керешә. Бу хрестоматия «Азат мәктәп» исеме белән 1925 елда Мәскәүдә басылып чыга. Белем дәрәҗәләре дә, яшьләре дә төрле булган укучыларга яраклы хрестоматия төзү авыр эш, әлбәттә. Яңа революцион әдәби әсәрләрнең әле аз булуы, хрестоматиянең күбрәк элеккеге әдәбияттан торуы авторларны бик нык борчый. «Татар әдәбиятының, бигрәк тә яңа революцион әдәбиятның ярлылыгы әсәрне идеальный иттереп чыгарырга мөмкинлек бирмәде», — дип язалар авторлар сүз башында. Г. Сәгъди «Азат мәктәп»не Октябрьдан соңгы бердәнбер әдәби хрестоматия, дип билгеләде[4]. 1928 елда Г. Нигъмәти, С. Шәрәфетдинов

[1] «Азат Себер» газетасы, 1921 ел, 6 сан.
[2] Шунда ук, 1925 ел, 1 сан.

[3] Г. Ибраһимов. Марксистик язучыларыбызга. «Безнең юл» журналы, 1925 ел, 4 сан.
[4] Г. Сәгъди. Октябрьдан элек һәм соң татар мәктәпләрендә әдәбият. Казан, 1927 ел, 12 бит.

белән берлектә, «Җәмгыятьне өйрәнү»нең төзәтелгән, тулыландырылган икенче басмасын чыгара. «Ташкын» исемендәге әдәби хрестоматия дә Нигъмәти катнашында чыга.

Коммунист булу революция идеаллары өчен көрәштән, халык өчен эшләүдән гыйбарәт. Г. Нигъмәтидә шул сыйфатлар көчле иде. Әнә шуңа күрә Һ. Такташ Г. Нигъмәти турында:

«Ул мәсьүл бер эшче. Йоклыйсы йокыларын, ял итәсе минутларын, ниһаять, үзен совет-партия иркенә биргән кеше» [1], — дип язды.

Гражданнар сугышы мәктәбен, Коммунистик университетны һәм 1922—1923 елларда Дәүләт журналистика институтын узу Нигъмәтинең тормыш тәҗрибәсен, марксистик хәзерлеген, әдәбият теориясе буенча белемен тирәнәйтте. Татарстанның ул вакыттагы иң зур ВУЗларыннан берсе — Көнчыгыш Педагогия Институты (ВПИ) ректоратының Нигъмәти белән кызыксынуы очраклы түгел иде. ВПИ ректораты, «Главпрофорб»га һәм СССР хөкүмәте каршындагы ВУЗ эшләре бүлегенә, Г. Нигъмәтине әдәбият кафедрасына доцент итеп билгеләүне сорап, болай дип яза:

«Яңа татар әдәбияты курсын алып бару өчен тәкъдим ителгән ип. Нигъмәтуллин кандидатурасы азчылык милләтләрнең милли ВУЗда яшь фән эшлекләләренә булган ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерә. Ип. Нигъмәтуллин — милләте буенча татар, журналист, әдәбиятчы, татар газеталарында эшләүче, татар әдәбияты буенча күп кенә хезмәтләрнең авторы, партиянең күптәнге әгъзасы — менә бу сыйфатлар барысы да Көнчыгыш Педагогия Институты татар әдәбияты өлкәсендә тулысынча хәзерлекле кадр белән тәэмин ителә дип уйларга мөмкинлек бирәләр» [2].

Шулай итеп, Г. Нигъмәти педагогик эшкә күчә. ВПИ да укыткан вакытта Нигъмәти әдәбият белгечләре хәзерләү буенча күпкырлы эш алып бара. Аның җитәкчелегендә аспирантура тәмамлаган кешеләр соңыннан татар-башкорт әдәбиятын өйрәнүгә зур өлеш керттеләр. Филология фәннәре докторы М. Гайнуллин, филология фәннәре кандидатлары Я. Агишев, Ж. Вәзиева, А. Кудашев, Ватан сугышында һәлак булган әдәбиятчы М. Мамин, Ж. Локманов — барысы да заманында Г. Нигъмәти җитәкчелеге астында аспирантурада укыганнар. Болардан тыш Нигъмәти Себер ВУЗлары өчен дә белгечләр хәзерләгән (Мәсәлән, Мөнзил Исхаков).

Запастагы командир буларак, Г. Нигъмәти җәй саен диярлек территориаль сборга чакырыла. Анда да ул үзенең каләмен ташламый. 1929 елгы сбор вакытында Г. Нигъмәти 57 нче Урал дивизиясенең политбүлеге каршында чыга торган «Красноармеец на боевой учебе» дигән газетаның редакторы була. Авыр маневр шартлары булуга карамастан, газета үз вакытында чыгып бара һәм кызылармеецларны оештыруда зур роль уйный.

«Мондый нәтиҗә, — дип яза командование газетаның соңгы номерында, — редакция һәм типографиядәге личный составның газетаның һәр номерын чыгару өчен армый-талмый зур энергия күрсәтеп эшләве аркасында мөмкин булды. Дивизиянең командованиесе зур энергия белән бик яхшы эш күрсәткәне өчен газета редакторы иптәш Нигъмәтуллинга... рәхмәт белдерә»[3].

1926—1928 елларда Г. Нигъмәти «Кызыл Татарстан» газетасының редакторы да булып эшли. Газетаның бу чорда әдәбият һәм сәнгать эше белән бәйләнеше шактый ныгыды. Нигъмәти озак еллар буенча Татар дәүләт академия театрының художество советы белән җитәкчелек итте. Театрның репертуарын яхшырту, татар сәхнәсендә яңа спектакльләр тудыру буенча аның хезмәтләре аз булмады.

Шулай итеп, Г. Нигъмәти, зур тормыш һәм көрәш мәктәбен узып,

[1] «Азат Себер» газетасы, 1928 ел, 37 сан.
[2] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы, 1487 фонд, 10 опись, 108 эш, 37 документ.

[3] «Красноармеец на боевой учебе» газетасы, 1929 ел, 4 сан (Нигъмәтинең шәхси архивыннан).

әдәбиятка килде, марксизм-ленинизм мәктәбе, дөньяга материалистик карашны пропагандалау аша әдәби тәнкыйть өлкәсенә килде. Шуңа күрә дә, бик тиз бер ара эчендә үзен төпле, эзлекле марксист тәнкыйтьче итеп танытты. Әдәби тәнкыйтьнең шактый каршылыклы һәм буталчык елларында иҗат итүенә карамастан, безгә фәнни һәм практик әһәмиятләрен хәзергә кадәр югалтмаган күп санлы мәкаләләр, монографияләр калдырды.

Иҗатының чәчәк атып килгән чорында, 1937 елның 16 сентябрендә, бер дә гаепсезгә Нәгъмәти кулга алына һәм төрмәгә ябыла. Үзенең бөтен гомерен социалистик җәмгыять төзүгә багышлаган Нигъмәти төрмәдә дә әдәбияттан аерылмаска тырыша. Семьясына язган хатларына караганда, ул татар совет әдәбиятының барышы, яңалыклары белән даими рәвештә кызыксынып торган, язылып бетмәгән хезмәтләре өчен борчылган. «Минем гомер буе эшләгән хезмәтем калды, — ди ул тормыш иптәше Җиһан Нигъмәтуллинага язган хатларының берсендә, — син аны саклый күр» (сүз — Нигъмәтинең архивында бүгенге көндә дә сакланган, ләкин, ни өчендер, әле дә дөнья күрмәгән Тукай турындагы монографик хезмәте турында бара). Лагерь тормышының кырыс шартларында да ул әдәбиятның унышларына куанып яши.

Безнең алдыбызда юка, саргылт кәгазьгә карандаш белән тыгызлап язылган хат кисәге. Бернинди сыкранусыз, ыңгырашусыз. Анда Нигъмәти болай яза: «Шәриф Камал турында укып барам. Карт язучыны котларга катнаша алмадым шул хәзергә. Җамал [1], Хәмитләрнең [2] аның турында мәкаләләре әйбәт кенә. Яратып укыдым.

Милли кадрлар үстергәнсең дип гаепләргә тырышсалар да, миннән укыганнар чын совет кадрлары булып эшлиләр. Бу хәл миңа һәм миндә укучыларга яла ягарга теләүчеләрнең үз пычраклыкларын ача торган факт түгелме? Мөмкин булса, миңа бераз кәгазь һәм каләм җибәрерсез әле, ягъни лагерьга... 1940 ел, 20 февраль».

1958 елда чыккан «Сайланма әсәрләр»дә Г. Нигъмәти 1941 елда үлгән, диелә. Ләкин, соңгы мәгълүматларга караганда, бу дата дөрес түгел. Нигъмәтинең соңгы еллардагы тормышын өйрәнеп, без шуларны ачыклый алдык:

Сталинград янында каты сугышлар барган вакытта, 1942 елның көзендә, 2326 нчы номерлы хәрби госпитальгә бик нык авыру хәлендә бер хәрби кешене кертеп салалар. Госпиталь Дон буендагы Клец Почтовский авылы тирәсенә урнашкан була. Палатадагы санитарка бу авыруның берничә көн буена үзенә игътибар иткәнен сизә. Берничә көннән соң авыру санитарканы чакыртып ала да:

— Сез Казаннан түгелме? — дип сорый. Бу кеше профессор Галимҗан Нигъмәти була (санитарка — ВПИ ректоры, соңыннан ТАССР Мәгариф Халык Комиссары Галә Ходаяровның кызы Хәнифә Ходаярова. Ул хәзер РСФСР Статистика Идарәсенең Татарстан бүлегендә экономист булып эшли).

— Озак сөйләшеп утырырга туры килмәде, — ди Х. Ходаярова, — Галимҗан абый бик нык авыру иде. Ун көнләп ятканнан соң без аны тылдагы госпитальгә эвакуацияләдек. Соңгы хәленә караганда, берничә көн генә яшәрлек иде. Шулай итеп, Нигъмәтинең соңгы язмышы ниндидер юллар белән Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына килеп тоташа. Болардан чыгып без инде Галимҗан Нигъмәти 1942 елның көзендә Сталинград янында Совет гаскәрләре фашистларга каршы җимергеч һөҗүмне җәелдергән көннәрдә фронтта үлгән дигән нәтиҗәгә килә алабыз. Кызганычка каршы, хәрби архивлардан эзләнүләр Нигъмәтинең соңгы көннәре турында берни дә бирмәделәр әле.

**М. МӘҺДИЕВ.**

[1] Җамал Вәзиева — Казан дәүләт педагогия институтының доценты.
[2] Хәмит Ярми — СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән гыйльми хезмәткәре.

# Укучылар сүзе

Язучы Эдуард Касыймовның «Гомер ике килми» романын мин зур канәгатьләнү белән укып чыктым. Аның бу әсәреннән яшь авторның елдан-ел үсә барганлыгы күренеп тора. Шәхес культы чорында газап чиккән семьялар тормышын гади совет хатынкызы образы мисалында уңышлы гына тасвирлап биргән язучы. Яшь каләм иясе Эдуард Касыймов шундый темага роман язып дөрес эшләгән. Нинди генә авырлыклар алдында да көчләрен кызганмыйча, киләчәк буынга шат тормыш яулауда үз-үзләрен аямыйча көрәшүче Назим, олы җанлы Ольга Николаевна һ. б. образлар күңелдә җылы тәэсир калдыра. Җыеп кына әйткәндә, әсәр уңышлы эшләнгән. Яшь язучыга киләчәктә дә уңышлар теләп калучы меңләгән китап укучыларның берсе —

*Х. Шәймөхәммәтов.*
Минзәлә районы, Калморза авылы.

Без, Совет чик сакчылары, «Казан утлары» журналын бик яратып укыйбыз. Н. Фәттахның узган елны сезнең журналда басылган «Бала күңеле далада» дигән романы миңа аеруча ошады. Чик буенда постта торганда якын-тирәдә трактор тавышы ишетелсә, гел Һарун, Вәгыйз, Мансур һ. б. далада бодай чәчә кебек тоела. Ә үземне, коралымны күкрәгемә кысып, аларның тыныч тормышын саклыйм кебек хис итәм.

*Р. Вазиев.*

Җырларда макталган гүзәл Казан шәһәрендә булганым бар минем. Аның хезмәт сөючән, ягымлы халкын бүген дә сагынып яшим. Казан шәһәренең театрлары, музейлары, парклары, мәһабәт культура сарайлары әле дә күз алдымда тора. Кыскасы, шәһәрнең үзен дә, аның кешеләрен дә бик яраттым.

Анда булып кайтканнан соң, мин «Совет әдәбияты» журналын алдыра башладым. Журналның һәр санын түземсезлек белән көтеп алам, анда басылган материалларны яратып укыйм.


Быел журнал «Казан утлары» дигән исем белән чыга башлады. Яңа исем котлы булсын! «Казан утлары» көн саен матурлана баручы тормышыбызны тагын да тулырак, тагын да тирәнрәк чагылдырсын.

*Ә. Гайнанов.*
Башкортстан, Борай районы.

Күптән түгел яраткан журналыбыз «Казан утлары» дигән яңа исемдә чыга башлады. Без, күп санлы укучылар, яңа исемне шатланып каршы алдык. Казан — халкыбызның горурлыгы. Казан — борынгы культура шәһәре. Казан дөнягә, В. И. Ленин, Л. Н. Толстой, А. М. Горький, Г. Тукай, М. Җәлил искә төшә.

Журналыбызга яңа исем бирүчеләргә зур рәхмәт!

*Ә. Фәтхиев.*
Нефтекамск шәһәре.




*Нурихан Фәттах*

# ТАМАК ШЕШТЕ

Хикәя

Бер көнне иртән уянып китсәм, тамак шешкән. Әллә нишләп тавыш үзгәргән, баш та авырта, хәл дә юк. Үзе тагын төчкертә дә, йөткертә дә. Менә сиңа имгәк! Авырыйсым килеп кенә торадыр иде менә монда.

— Болай булгач, эшкә бармассың инде,— диде хатын, минем мөшкел хәлне күреп.

— Нинди бармаган ул! — дидем мин, борын суын тарткалап.— Минсез анда берни бармаячак.

— Сөйләнмә, хәзер үк поликлиникага кит,— диде хатын.— Күрмисеңмени, әнә ич грипп булган... ангина... Синең аркада монда бөтен өй эче белән чирләп ятасы юк.

Хатын шулай дигәч, мин килешергә мәҗбүр булдым. Чыннан да, грипп-фәлән булса, хәрап эшләр!

Ашадым-эчтем дә, җылырак киендем дә, ух-вах килеп, поликлиникага киттем. Яшь кенә, чибәр генә бер туташ чишендереп минем үпкәне, йөрәкне тыңлады, аннары «а!» дип кычкыртты, каккалады-суккалады да: «Сезгә катарр булган», — диде. Шуннан соң бу миңа алай итмәскә, болай итмәскә кушты, дару кәгазе язып бирде.

Мин туташка мең-мең рәхмәтләр әйтеп, кабинеттан чыгып киттем. Юл уңаенда аптекага кереп дару алдым. Алдым да, тәмам тынычланып, өйгә таба атладым.

Ләкин шул чакны мин уйга калдым: бу «катарр» белән өйдә күпме ятарга туры килер? — дидем. Бер көндә терелтә торган берәр дару юк микәнни? Шулай уйлана торгач, дустым Галәвине исемә төшердем. «Туктале, кереп чыгыйм булмаса», мәйтәм. Борылдым да Галәвиләргә китеп бардым.

— Нишләп тамагың карлыкты? — диде Галәви, исәнлек-саулык сорашкач.

— Менә шуның артыннан йөрим әле,— дидем мин, йөткеренгәләп.— Салкын тигән.

— Салкын тигән? Грипп түгелме? — диде Галәви, куркып, артына чигенеп.

— Юк, юк! — дидем. — Грипп түгел, ниндидер катарр, ди. Әле генә врачта булдым.

— Врачта булдың?! — диде Галәви, исе китеп.— Салкын тигән өчен врачка бардыңмы? Үземә генә килгән булсаң соң! Мин сиңа кырык төрле дәва тапкан булырыем.

— Әле дә соң түгел,— дидем мин.— Менә шуңа кердем дә инде сиңа. Аптекадан дару алганыем да, синең белән киңәшим дидем: эчәргәме, юкмы... Кайчан терелә сең әле аның белән... Никтер ышанмыйм мин ул даруларга.

Шулай сөйләнгәләп мин даруны Галәвигә күрсәтмәкче булдым, ләкин Галәви кулын гына селтәде.

— Ташла, эчмә! — диде.— Акыллы кеше эптик даруын эчәмени! Бер яктан дару булса, икенче яктан агу бит ул. Йөрәккә, бавырга төшә, нервыны ашый. Мин дә заманында күп йөрдем врачларга. Берсе бертөрле сөйли, икенчесе икенче төрле сөйли. Берсе бер дару язып бирә, икенчесе икенче дару. Халтурщиклар! Шарлатаннар! Мин хәзер аларга аяк та басмыйм. Гайрәтем чикте. Медицина, гомумән, бернигә тормый.

— Шулай шул,— дидем мин, килешеп.

Мин шулай дигәч, Галәви тагын алып-биреп медикларны сүгәргә тотынды.

— Иң ышанычлысы — халык медицинасы! — диде ул, кайнарланып.— Үлән, үлән тамыры, җимеш, чәчәк... Менә ул кайда чын медицина!

— Шулай шул,— дидем мин тагын да.— Өйрәт әле миңа да берәр нәрсә... тиз генә файдасы тия торганын... Үләм бит, малай... баш авырта, хәл юк.

— Ничек авырта? Кай җирең авырта? — диде Галәви.

Мин аңа сөйләп бирдем.

— Беләсеңме нәрсә,— диде Галәви, бераз уйлангандай итеп торгач,— сиңа, иң яхшысы, яңа суырткан бал кирәк. Яңа суырткан бал җитмеш төрле авыруга дәва!

— Кыш уртасында каян тапмак кирәк яңа суырткан балны?! — дидем мин, гаҗәпләнеп.

— Яңасы булмаса, утырганы да ярый,— диде Галәви.— Файдасы әзрәк булыр, шулай да ярый. Ярты кило балга бер литр кайнар су саласың да нгытып болгатасың...

— Ярты кило күбрәк булмасмы? — дидем мин.

— Булмас,— диде Галәви һәм, бу мәсьәләгә артык тукталып тормыйча, ялгап алып та китте: — Бал булмаса, алоэ яфрагын кайнатып эчәргә була. Анысын болай итәсең...

— Минем дә ишеткәнем бар ул алоэ турында,— дидем мин, аны бүлдереп.— Ләкин каян алырга соң шуны?

— Базарда тамыр-томыр сатучы карчыкларда булыр. Алар сиңа алоэны түгел, әҗәл даруын табып бирерләр! — диде Галәви.

— Мәшәкатьлерәк икән шул,— дидем мин.— Тагын юкмы?

— Анысы да булмаса, чи балан суы эчәргә була,— диде Галәви.

— Юк, юк, булмый! — дидем мин, кулымны селтәп.— Хатын көн дә чыга базарга балан эзләп, һич туры китерә алмый.

— Алайса, андыз тамыры кайнатып эчәргә кирәк,— диде Галәви.

— Анысы тагын нәрсә?

— Шундый үлән бар,— диде Галәви.— Бик сирәк очрый. Жен-шен кебегрәк. Безнең авылда элек бер карт булган, бөтен авыруларны шул андыз тамыры белән генә имләгән. Тамак шешкәч тә...

— Туктале, мин булмаса язып алыйм,— дидем мин.

Кесәмнән куен дәфтәре чыгардым да өстәл янына килеп утырдым. Галәви башта сөйләгәннәрен яңадан кабатлап чыкты. Мин язып бар-

дым. Ул көнне ул миңа тамак шешкәндә кулланыла торган барлык дәвалар турында, барлык им-томнар турында сөйләде. Нәрсә генә тәкъдим итмәде ул миңа! Мәтрүшкә, әчәлче, бөтнек ише үләннәр кайнатып эчү дисеңме, шешкән җиргә сарана күкәе, аксыргак тамыры тотып тору дисеңме, анадан тума килеш абага яфрагы ваннасында утыру дисеңме, миләш, аю камыры, чи бәрәңге кебек нәрсәләр ашау дисеңме...— берсе дә калмады! Аның әйтүенә караганда, аларның барысы да иң ышанычлы, иң тәэсирле дәва булырга тиеш иде.

Сөйли-сөйли ул арып бетте, хәлдән тайды. Ләкин тавышы әкренәя башладымы, чиләктән чүмеч белән су алып эчте дә дәртләнеп яңадан сөйләргә кереште.

Ниһаять, ул туктап калды, күзенә төшкән чәчләрен сыпырып ташлады да, көчкә тын алып:

— Менә шул...— диде.—Хәзергә бетте... бүтән белмим. Кайт та, мин әйткәнчә...

— Ярый, рәхмәт,— дидем мин, урынымнан кузгалып.

Саубуллаштым да, Галәви өйрәткән даруларның кайсын куллансам яхшырак булыр икән дип уйлана-уйлана, кайтып киттем.

Урам буйлап әкрен генә барадыр идем, бер заман кемнеңдер кычкырганын ишетеп, артыма борылып карадым. Ул да булса, ашыгыпкабаланып Галәви килә! «Тагын берәр яңа дару исенә төште микәнни?» дип уйладым мин. Туктадым да көтә башладым.

— Карале... туктале! — диде Галәви килеп җиткәч.— Каяле, күрсәт әле теге даруыңны?

Мин аңа аптекадан алган баягы даруны бирдем. Галәви, даруның исемен укыды да, «ә!» дип куйды.

— Ни, малай...— диде бераздан, тотлыгып.— Нишләптер минем дә тамак авырта башлады. Әптиккә кереп чыкмый булмас, ахрысы.

6 май, 1964 ел.
Казан.

# ТӘНКЫЙТЬЧЕ

## Хикәя

Мин бик тәүфыйклы кеше: эчмим, тартмыйм, хатын-кыз белән чуалмыйм. Аннан да бигрәк, мин беркайчан да беркем белән дә ачуланышмыйм. Аннары, мин бик сак кеше. Әйе, сак кеше. Югыйсә, безнең агайэне бик алама бит ул. Берәр ничек кыек басканыңны сагалап кына тора. Күрдеме, шундук тотып ашарга әзер. Шуңа күрә, һәрвакыт алдыңны-артыңны карап йөргәнең яхшы. Берничек тә бәйләнерлек булмасын. Кыскасы, син миңа тимә, мин сиңа тимим. Вәссәләм! Җаның тыныч, ярмаң — аш.

Тагын шул, миндә әле сизгерлек дигән нәрсә дә бар. Мин кешенең аяк атлавыннан ук беләм — дусмы ул, дошманмы сиңа... Кирәк икән, җиде кат җир астында елан күшәгәнен ишетәм мин! Җыеп кына әйткәндә, менә шундый әйбәт кеше инде мин.

Ләкин, шулай була торып та, кайбер агай-эне никтер мине яратып җиткерми. Чынлап, яратмыйлар. Күзгә карап та әйтәләр, карамыйча да әйтәләр: мыштым, диләр, ялагай, диләр, начальство алдында тәлинкә тота, диләр.

Алар, билгеле, көнләшкәнгә күрә шулай диләр. Чөнки бары мин генә диярлек мастерлардан Фәлән Фәләнеч белән яхшы мөнәсәбәттә.

Шулай булмыйча, начальство белән телгә-тешкә керергә башыма тай типкәнме әллә минем?! Юк, анысы инде булмас. Башкалар теләсә нишләсен, әмма ләкин мин үзем андый юлга басмам! Ә бездә башсыз халык житәрлек — кемнең кем булуына карамыйлар, селкеп салырга гына торалар.

Шулай бер жыелышта безнең агай-эне Фәлән Фәләнечкә каршы ябырылды. Бирделәр кирәген! Ярый әле мин яклап чыктым үзен, югыйсә, эшләре шәптән түгел иде безнең цех начальнигының.

Жыелыш беткәч, без ничектер моның белән бергә туры килдек: бер ишектән чыктык, әлгечтән киемнәребезне дә бергә алдык. Кайсыдыр безне күреп калган. Икенче көнне килсәм... мине... шундый тәртипле кешене гәжиткә төшергәннәр! Озын куллы итеп, Фәлән Фәләнеч алдында бишкә бөгелгән итеп төшергәннәр. Йөзем шундый ялагай, муеным нечкә, кулымда тәлинкә. Тәлинкәдә Фәлән Фәләнечнең эшләпәсе. Фәлән Фәләнеч юан корсаклы, борыны югары чөелгән. Миңа карамый да.

Кеше-ни ишетә күрмәсен... үзара гына әйткәндә, Фәлән Фәләнечне дөрес эшләгәннәр. Ул чыннан да шундый зур корсаклы, тупас, эре. Бары мине генә мыскыллаганнар. Беркайчан да минем Фәлән Фәләнечнең эшләпәсен тәлинкәгә салып та, салмыйча да тотканым юк. Шулай ук минем исемнән әйтелгән: «Эшләпәгезнең тузанын кактым, киярга була, Фәлән Фәләнеч!» — дигән сүзләр дә ялган.

Ачуымнан нишләргә дә белмәдем инде үзем дә! Шулай да түздем. «Ярар, күрсәтермен әле мин сезгә күрмәгәнегезне!» дип уйладым күңелемнән.

Хәзер мин үч алырга жай чыкканын гына көтеп йөри башладым. Озак көтәргә дә туры килмәде — бер заман жае да чыкты моның.

Ләкин шул чагында мин чирләп киттем, өч көн бүлетиндә яттым. Дүртенче көнне эшкә бардым. Барсам, тагын жыелыш жыйдылар. Докладчы сөйләп бетерер-бетермәс борын, мин беренче булып сүз сорадым да туп-туры трибунага менеп киттем. Менеп бастым да трибуна янына, тамак кырып, ачулы гына башлап киттем:

— Иптәшләр, ни өчен безнең цех артта бара? — дидем. — Чөнки, иптәшләр, безнең житәкчеләр начар, ягъни мәсәлән, цех начальнигы Фәлән Фәләнеч... Сез беләсез, иптәшләр, Фәлән Фәләнеч — дорфа кеше, эшчеләр белән рәтләп сөйләшми, кеше сүзенә колак салмый... өстәл сугып кына кычкыра...

Шундыйрак сүзләр белән теттем генә Фәлән Фәләнечне! Кинәнгәнче тәнкыйтьләдем! Бөтен зал мине тын да алмый тыңлап торды. Исләре китеп, авызларын ачып тыңлыйлар. Күрәсең, минем кыюлыкка хәйран калганнар. Уен эшмени, миңа кадәр әле иң усал телләрнең дә Фәлән Фәләнечкә шулкадәр каты бәрелгәннәре юк иде бугай.

Халыкны әйтәм, тыңлап-тыңлап утырдылар да кинәт исләренә килделәр, шаркылдап көләргә, шаулашырга тотындылар. Көләләр бөгелепсыгылып! И көләләр эчләрен тотып!

Мин инде аларның көлүенә игътибар итеп тормадым. Әйтәсе сүземне әйттем дә залга төштем, күкрәкне киереп, үземнең урынга таба атладым. Ә көлү тавышы һаман туктамый. Колак төбендә төрле сүзләр ишетелеп китә.

— Менә сиңа Мыштымбай! — диләр.

— Соңгарак калгансың шул: Фәлән Фәләнечне кичәгенәк эшеннән алдылар! — диләр.

Һы, әйттеләр яңалык! Аның алыначагы турында мин инде бер атна элек белгән идем.

*Зәки Нури*

## Зарланалар

*Сатирик хроника*

Районда кибетләр буйлап
Иртәләп-соңлап йөрдек.
Кемнәрдә нинди зар барын
Ишетеп-тыңлап йөрдек.

Бер кибеттә бер яртыны
Өчкә бүлеп салалар.
«Берәмләсәң,— выручка юк,
Болай күбрәк алалар!»

Балык саткан төшкә кердек,
Хәтта килки балык юк.
Зарландылар: «Андый белән
Вакланучы халык юк...»

Шикәргә конфет кушылган.
Бу нинди товар? — дибез.
«Ярамый» дип әйтүче юк,
Ә безгә «ярар» — нигез!»

Шүрлек тулы чеп-чи ипи.
Мөдир аңлатма ясый:
«Чөнки без саткан икмәкне
Чучкалар күбрәк ашый».

Аракы иң алга баскан,
Аскы урын — китапка.
«Китап алган—шешә алмый...»
Дип әйтелде бу хакта.

Сыра сатучы агайның
Ни әйтерен беләсез:
«Үзегез симерттегез дә
Хәзер миннән көләсез».

# Киресенчә теләкләр

Ялкауның эштә уңыштан
Башы әйләнсен иде.
Тагын эчмичә кайтты, дип,
Хатын бәйләнсен иде.

Приемга дип, бюрократлар
Чират көтсеннәр иде.
Юл төзүчеләр үзләре
«Сират» кичсеннәр иде.

Мәчеләр тычкан тотканда
Кыңгырау таксын иде.
Үзе сөйләгән оратор
Үзе кул чапсын иде.

Сөткә су кушкан савымчы
Судан май алсын иде.
Кайчакта директорлар да
Бүләксез калсын иде.

Калада йөрсәң иде дә
Буфетка керсәң иде —
Эчмә дигән докторларның
Эчмәвен күрсәң иде.

Кассирлар сдачаларны
Арттырып бирсен иде.
Кондукторлар елмаюы
Төшкә бер керсен иде.

Бүреләр куркырлык булып
Сарык та азсын иде.
Язганны каккан редактор
Үзе дә язсын иде.

Бакчада куаклар түгел,
Киртәләр аусын иде...
Теләкләр өчен безгә дә
Рәхмәтләр яусын иде!

●

# Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНДА

### МУСА ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА ФИЛЬМ

Татар халкының батыр улы Советлар Союзы Герое Муса Җәлил турында тулы метражлы нәфис фильм өчен материал туплау максаты белән күптән түгел «Ленфильм» киностудиясе директоры И. Киселев, беренче иҗади берләшмә директоры Б. Глинер, режиссер Г. Никулин, сценарий язучылар В. Григорьев, Э. Дубровский һәм С. Потепалов Казанда булдылар.

Татарстан язучылары союзында кунаклар республикабызның әдәбият, сәнгать һәм культура эшлеклеләре белән очрашып, үзләренең киләчәктәге эш планнары белән уртаклаштылар. Студия директоры И. Киселев очрашудагы чыгышында түбәндәгеләрне сөйләде:

— Булачак фильмның әһәмияте бик зур. Бу эшебезгә партиябез Үзәк Комитеты да, хөкүмәтебез дә зур игътибар юнәлтә. Без бөтен прогрессив кешелек дөньясына фашизмга каршы Көрәшче эталонын күрсәтүне үзебезгә максат итеп алдык. Бу мактаулы эшне тормышка ашыру өчен без үзебезнең бөтен көчебезне куячакбыз.

Муса Җәлилнең дуслары, замандашлары Г. Кашшаф, Ш. Маннур, М. Әмир, Ә. Исхак, М. Садри һ. б.лар фильм авторларына күп кенә конкрет киңәшләр бирделәр. Фильм авторлары Казанда Муса Җәлил тормышы һәм иҗаты белән бәйле урыннарда булдылар.

### ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Язучы Госман Бакиров һәм Татарстан язучылары союзы идарәсенең яшь язучылар белән эшләү комиссиясе председателе А. Гумеров август аенда Чаллы һәм Алабуга районнарына барып кайттылар. Алар район газеталары каршында оештырылган әдәби түгәрәк утырышларына катнаштылар, яшь һәм башлап язучыларның әсәрләре турында фикерләрен әйтеп чыгыш ясадылар.

●

Казанда яшәүче рус язучысы Г. Паушкин Васильево санаториясендә дәваланучылар белән очрашты, аларга үзенең яңа әсәрләрен укыды, иҗат планнары турында сөйләде.

Август аенда Биектау районының Киров исемендәге колхозында әдәби-музыкаль кичә булды. Колхозчылар алдында Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артистлары чыгыш ясадылар. Әдәби-музыкаль кичәгә шагыйрьләрдән М. Садри, Р. Әхмәтҗанов, М. Хөсәен катнашты. Алар тамашачыларга үз әсәрләрен укыдылар.

●

Язучы Нәби Дәүли август аенда Актаныш районында булып кайтты. Ул «Яшәү белән үлем арасында» исемле китабы буенча районның культура йортында үткәрелгән укучылар конференциясендә катнашты. Актаныш балалар китапханәсендә булып үткән әдәби кичәдә балаларны үзенең яңа әсәрләре белән таныштырды, Нур Баян исемендәге колхозда һәм Яңа Әлем авылында колхозчылар белән очрашты.

Илдар Юзиев белән Шәүкәт Галиев Биектау районының Мәмдәл авыл клубында «Правда» колхозы члennары, механизаторлар белән очрашып, аларга үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары турында сөйләделәр, әдәбият сөючеләрнең күп санлы сорауларына җаваплар бирделәр.

●

Габдрахман Әпсәләмов «Истра» теплоходында Астраханьга барып кайтты. Ул анда туристлар белән очрашулар үткәрде, әсәрләреннән өзекләр укыды, бүгенге әдәбият алдында торган бурычлар турында сөйләде. Туристлар һәм теплоход экипажы исеменнән язучы Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## КАЗАНДА ГАСТРОЛЬЛӘР

### ГАЛИЯ ИЗМАЙЛОВА КОНЦЕРТЛАРЫ

СССРның халык артисткасы, дәүләт премиясе лауреаты Галия Измайлова Казанда гастрольдә булды, башкалабыз тамашачыларын үзенең гүзәл сәнгате белән таныштырды.

Галия ханымны Советлар Союзында гына түгел, чит илләрдә дә яхшы беләләр. Ул Америкада, Англиядә, Франциядә, Иранда — барлыгы 20 дән артык илдә чыгышлар ясаган. Менә шуңа күрәдәдер, бәлки, аның репертуары гаять киң һәм бай. Ул тамашачыларны төрле халыкларның биюләре белән таныштырды. Корея, Памир, Индонезия, Мексика халыклары биюләре аның башкаруында зур сәнгать үрнәге булып торалар.

Галия Измайлова халык биюләрен башкару белән генә чикләнми. Ул классик балет биюләрен дә яратып башкара һәм шул ук вакытта балетмейстер да. Күптән түгел Галия Измайлова куйган «Болеро» балетына Үзбәкстан хезмәт ияләре генә түгел, Ленинград тамашачылары да зур бәя бирделәр.

### КАЗАНДА ВЕНГЕР ЭСТРАДАСЫ КОНЦЕРТЛАРЫ

Август аенда Казанга тугандаш Венгрия республикасы артистлары эстрада концертлары белән килделәр. Эстрада составында композитор Индаи җитәкчелегендәге оркестр, биш җырчы, оригиналь жанр остасы Томаш Хаки бар иде. Безнең өчен берникадәр сәеррәк булса да (күбрәк интим характердагы номерлар) венгер дусларның чыгышларын Казан тамашачылары яратып карадылар.

### КАЗАНДА МӘСКӘҮНЕҢ МЮЗИК-ХОЛЛ АРТИСТЛАРЫ

Мюзик-холл концертларының программасы киң, ул музыкадан, биюләрдән, күңелле мәзәкләрдән, интермедияләрдән һәм акробатик трюклардан тора. Шуңа күрә дә мюзик-холлның спектакльләрен карарга килгән кешеләр бер дә үкенмәделәр — баштан ахырга кадәр алар көлеп кенә утырдылар, концерттан күтәренке күңел белән киттеләр. Спектакльләрдә юмор да, җиңел моң да, хәзерге заман җырлары да, биюләр дә, жонглер номерлары да мул булды. Алар барысы да бер сюжет җебенә тезелгәннәр. Мюзик-холл спектакльләре сәхнәгә куючы А. Конниковның, балетмейстер Н. Холфинның, художник В. Кноблокның һәм артистлар коллективының зур уңышы. Бу спектакльләрдә тамашачылар белән артистлар арасындагы бәйләнеш бер генә минутка да өзелмәде.

### Ф. И. ШАЛЯПИН КЫЗЫ КАЗАНДА

Атаклы рус җырчысы Федор Иванович Шаляпинның безнең якташыбыз икәнлеген укучыларыбыз күптән беләләр. Күптән түгел Ф. И. Шаляпинның кызы Ирина Федоровна Казанга кунакка килде. Ул Куйбышев исемендәге химия заводының пионерлар лагеренда булды, М. Горький музеенда үзенең әтисе турында истәлекләр сөйләде. Аннары Федор Иванович укыган йортта, ул М. Горький белән очрашкан бинада һәм Шаляпин белән бәйле башка урыннарда булды.

Ирина Федоровна күп еллар буена Моссовет исемендәге театрда эшли. Хәзер ул пенсиядә һәм Федор Иванович Шаляпин турында истәлекләр китабы яза.

### ОПЕРА һӘМ БАЛЕТ ТЕАТРЫ ГАСТРОЛЬДӘ

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры Волгоград һәм Астрахань шәһәрләрендә гастрольдә булып кайтты. Казан артистлары ул шәһәрләрдә үзләренең иң яхшы спектакльләрен күрсәттеләр. «Алтынчәч», «Борис Годунов», «Риголетто», «Джоконда», «Севиль чәч кыручысы», «Пика дамасы» операларын, «Шүрәле», «Аккош күле», «Раймонда» балетларын, «Башмагым», «Тальян моңы» музыкаль комедияләрен тамашачылар яратып карадылар. Ф. Насретдинов, М. Пантюшин, В. Жарков, Н. Юлтыева, Г. Калашникова, А. Аббасов чыгышларына зур бәя бирделәр.

Казан артистлары, спектакльләр күрсәтүдән тыш, клубларда, культура сарайларында, предприятиеләрдә концертлар да бирделәр.

## Алдагы санда:

Ш. Маннур. **Муса.** Роман. Ахыры.

Г. Мөхәммәтшин. **Авылда бер...** Хикәя.

Г. Афзал, Н. Арсланов, Г. Латыйп, Р. Әхмәтҗанов, Г. Зәйнәшева, Р. Фәйзуллин шигырьләре.

И. Илялова. **Заман һәм театр.** Тәнкыйть мәкаләсе.

Җ. Фәйзрахманова. **Китап бәхете.**

●

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**


Производствога бирелде 10/VIII-1965 ел. Басарга кул куелды 14/IX-1965 ел. ПФ 08156. Кәгазь форматы 70×108$^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 20410 экз. Заказ № 1068.
Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1965 ел.

# ЮЛЛАР

Ә. Ерикәй сүзләре

А. Фаттах музыкасы.




Бизмәгәндәй яшәү бәхетеннән,
Юл йөрүдән мәнге бизмәм мин;
Юллар, юллар, инде ничә еллар
Аерыла алмыйм сездән мин.

Алларымда якты йолдыз төсле
Мавыктыргыч утлар яналар;
Юллар, юллар, борма-борма юллар
Шул утларга таба баралар.

Яшьлек хисен, тынгысызлык дәртен
Вакыт яңгырлары юмасын;
Юллар, юллар авыр булса булсын,
Тик соңгысы гына булмасын.

Тибрәндереп якты уйларымны
Җәйрәп ята даплы, киң илем;
Юллар, юллар алга таба дәшә,
Бармый калыр хәлем юк минем.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73367

*Ежемесячный литературно-художественный*
*и общественно-политический журнал*

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*(Огни Казани)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ